# Матѳей жазган арыу Евангеліе.

1-нче бюлем.

Зач.1.

1 Авраамъ Улы, Давидъ Улы Іисусъ Христоснын тӧб аталарын айтеӳ:

2 Авраамъ Исаакны тыудырган; Исаакъ Іаковны тыудырган; Іаковъ Іуда белян анын ага-энелярен тыудырган.

3 Іуда Ѳамарадан Фаресъ белян Зараны тыудырган; Фаресъ Эсромны тыудырган; Эсромъ Арамны тыудырган; Арамъ Аминадавны тыудырган.

4 Аминадавъ Наассонны тыудырган; Наассонъ Салмонны тыудырган.

5 Салмонъ Рахавадан Воозны тыудырган; Воозъ Руѳтян Овидны тыудырган; Овидъ Іессейне тыудырган.

6 Іессей Давидъ падшаны тыудырган, Давидъ падша элеке Урія катыны булган катынышнан Соломонны тыудырган.

7 Соломонъ Ровоамны тыудырган; Ровоамъ Авіяны тыудырган; Авія Асаны тыудырган.

8 Аса Іосафатны тыудырган; Іосафатъ Іорамны тыудырган; Іорамъ Озіяны тыудырган.

9 Озія Іоаѳамны тыудырган; Іоаѳамъ Ахазны тыудырган; Ахазъ Езекіяны тыудырган.

10 Езекія Манассіяны тыудырган; Манассія Амонны тыудырган; Амонъ Іосіяны тыудырган.

11 Вавилонга кючяр алдыннан, Іосія Іехонія белян анын ага-энелярен тыудырган.

12 Вавилонга кючкяч, Іехонія Салаѳіилне тыудырган; Салаѳіилъ Зоровавелне тыудырган.

13 Зоровавель Авіудны тыудырган; Авіудъ Еліакимны тыудырган; Еліакимъ Азорны тыудырган.

14 Азоръ Садокны тыудырган; Садокъ Ахимны тыудырган; Ахимъ Еліудны тыудырган.

15 Еліудъ Елеазарны тыудырган; Елеазаръ Матѳанны тыудырган; Матѳанъ Іаковны тыудырган.

16 Іаковъ Марія ире Іосифны тыудырган; Маріядан Христосъ диб айтелгян Іисусь тыуган.

17 Шулай Авраамнан Давидка чаклы ун дюрт быуын; Давидтан Вавилонга кючкенче тагы ун дюрт быуын; Вавилонга кючкяннян ары Христоска чаклы тагы ун дюрт быуын.

Зач.2.

18 Іисусъ Христоснын тыуыуы былай булган: Анын анасы Маріяны Іосифка жяряшкяч, алар бергя кушылмаган кӧйӧ, Святый Тыннан булыб Маріянын буйында бары беленгян.

19 Анын ире Іосифъ изге кеше икян; ул Маріяны оятлы итмейем диб, аны жяшертен айырыб жибярмякче булган.

20 Тик ул шулай диб уйлагач, Ходай пяриштясе аңар тӧшӧндя кюренеб äйткян: эй Давидъ улы Іосифъ! син катыныӊ Маріяны кабыл алыб, ӱзеңдя тотарга курыкма, анын буйындагы Святый Тыннан шул;

21 Ул Ул тыудырыр, син Аны Іисусъ диб атарсын; Ул Ӱз калкын жазыкларыннан коткарыр, дигян.

22 Бу бар да Ходайнын пагамбяр арткылы äйткян сюзе жиреня килер ӧчӧн булды, пагамбяр äйтя:

23 Мына кыз буйга узыб Ул тыудырыр, Анын исемен Еммануилъ диб атарлар, Еммануилъ дигяне : Алла безнен белян дигян сюз, диб.

24 Іосифъ жокодан торгач, Ходай пяриштясе кушканча кылган: катынын кабыл алыб ӱзендя тоткан.

25 Алай да аңар жакыннашмаган. Шуннан ары Марія элек Улын тыудырган; Іосифъ Аны Іисусъ диб атаган.

2-нче бюлем.

Зач. 3.

1 Иродъ падша багытында Іудея Виѳлеемендя Іисусъ тыугач, жондозчылар кояш чыгышыннан Іерусалимга килеб äйткянняр:

2 Іудеянен жаңа тыуган Падшасы кайда? без кояш чыгышында Анын жондозон кюргянгя кюря, Аңар башырырга килдек, дигянняр.

3 Мыны эшетеб, Иродъ та, анын белян бӧтӧн Іерусалимъ дя жӧдяб киткянняр.

4 Иродъ бар баш священниклярне, калык укымышларын жыйыб, алардан: Христосъ кайда тыуасы? диб сораган.

5 Алар аңар äйткянняр: Іудея Виѳлеемендя тыуасы, пагамбяр арткылы былай жазылган шул:

6 Син дя Виѳлеемъ, Іуда жире, Іуданын оло калаларыннан ич тя ким тӧгӧл: синнян башлык чыгар шул, Ул Минем калкым Израилне кӧтӧб жӧртӧр, дигян.

7 Шуннан суӊ Иродъ жондозчыларны жяшертен чакырыб алыб, алардан жондоз кюренгян багытны элпяляб сораган.

8 Аннары аларны Виѳлеемгя жибяргян чагында аларга äйткян: барыгыз, Бала турысында айырмачык белегез, Аны табкач, миңа да хабяр итегез, мин дя барыб Аңар башырыр ыйым, дигян.

9 Алар падшаны тыңнаб киткянняр; кояш чыгышында кюренгян жондоз шундук алар алдыннан бара башлаган; барыб житкяч, Бала торган урын өстөндя туктаган.

10 Жондозны кюреб, алар бик сөйөнгянняр.

11 Өйгя кергяч, анасы Марія белян Баланы кюреб, Аңар жыгылыб башырганнар; сауытларын ачыб, алтын, ладанъ, смирна алыб, Аңар бюляк итеб биргянняр.

12 Төшлярендя Иродка кайтмаска хабяр алыб, бютян жул белян ўз жакларына кайтыб киткянняр.

Зач. 4.

13 Алар киткяч, Ходай пяриштясе Іосифка төшөндя кюренеб айткян: тор, Баланы да, анасын да алыб, Египеткя кач, мин сиңа айткенче шунда тор, Иродъ Баланы ўтерер өчөн эзлямякче була шул, дигян.

14 Ул төння тороб, Баланы да, Анын анасын да алыб, Египеткя киткян.

15 Иродъ ўлгенче шунда торган; шулай итеб, Ходайнын пагамбяр арткылы: Египеттян Улымны чакырыб алдым, дигян сюзе жиреня килгян.

16 Жондозчылар мыскылга калдырганны кюргяч, Иродъ бик ачыуы килеб, Виѳлеемдагы, анын буган тиря жюнендяге бар балаларны, жондозчылардан сораб айырмачык белгян багытка чамалаб, ике жяштягелярен, аннан кечелярен дя ўтерергя жибяргян.

17 Шул чакта Іеремія пагамбяр арткылы айтелгян сюз жиреня килгян; ул айтя:

18 Рама каласында бик тилмереб, ўкереб жылаган ауаз эшетелгян: Рахиль балалары өчөн жылаб, алар жукка кюря, тыйыласы килмягян, диб.

19 Иродъ ўлгяч, Египеття Ходай пяриштясе Іосифка төшөндя кюренеб,

20 Тор, Баланы да, анасын да алыб, Израиль жиреня кайт, Бала жанын эзляўчеляр инде ўлделяр шул, дигян.

21 Ул тороб, Баланы да, Анын анасын да алыб, Израиль жиреня кайткан.

22 Іудеядя Архелай ўз атасы Иродъ урнында падшалык иткянне эшетеб, ул анда барырга курыккан; төшөндя хабяр алыб, Галилея тирясеня киткян.

23 Анда баргач, Назаретъ дигян калага урыннашкан; шунын белян пагамбярляр арткылы: Ул Назорей диб аталыр дигян сюз жиреня килгян.

3-нчӧ бюлем.

Зач. 5.

1 Бердя бер кӧннярдя чумылдырыучы Іоаннъ Іудеянын буш кырына килеб, сӧйляб жӧргян:

2 Тяўбя итегез, инде кюк падшалыгы жакыннашты шул, дигян.

3 Исаія пагамбярнен: Ходайга жул ӓзерлягез, Аӈар туры сукмаклар жасагыз диб, буш кырда кычкырыучынын ауазы, диб ӓйткяне шул ўзе булган.

4 Іоаннын ўзенен ӧстӧндяге кейеме дӧя жононнан, билендяге эзяре тиредян булган; ашамныгы сикерткя белян кыр балы булган.

5 Шул чагында Іерусалимнян,бӧтӧн Іудеядян, Іорданнын буган тиряляреннян чыгыб, аӈар килгянняр;

6 Жазыкларын ӓйтеб, аннан Іорданъ сыуында чумылдырылганнар.

7 Іоаннъ кюб фарисейляр, саддукейляр аӈар чумылырга килгянне кюреб, аларга ӓйткян: эй жылан тыумалары! буласы кыйыннан качарга сезгя кем ӓйтте?

8 Тяўбягя тейешле жимеш булдырыгыз;

9 Безнен атабыз Авраамъ диб кюӈелегездя уйламагыз; мин сезгя ӓйтямен: шушы ташлардан Авраамга балалар булдырырга Алланын кыуатыннан киля, дим.

10 Балта инде агач тӧбӧндя жата: арыу жимеш китермей торган агачнын ӓр-кайсын кисяляр дя утка ташлыйлар.

11 Мин сезне, тяўбягя китерер ӧчӧн, сыуга чумылдырам, ӓммя минем артымнан Килеўче миннян кыуатлы; мин Анын аягына кея торган нястясен кулыма тотоб (салгызырга) да тормоймын; Ул сезне Святый Тын белян, ут белян чумылдырыр.

12 Анын кӧряге кулында, Ул ындырын ӓрчер, бодайын клятеня жыяр, кибяген сюнмяс утка жандырыр, дигян.

Зач. 6.

13 Шул чакта Іисусъ Галилеядан Іорданъ жанына Іоаннан чумылдырылырга килгян.

14 Ӓммя Іоаннъ Аны туктатыб ӓйткян: мин Синнян чумылдырылырга тейеш, Син Ўзеӈ миӈа килясен, дигян.

15 Іисусъ аӈар жауаб биреб ӓйткян: туктатма ӓле, безгя шулай итеб ӓр-бер дӧрӧслӧкне кыларга тейеш, дигян; аннары Іоаннъ Аны туктатмаган.

16 Іисусъ чумылгач, тизюк сыудан чыккан; шул сяттюк Аӈар кюкляр ачылган; (Іоаннъ) Анын ӧстӧня Алла Тыны кюгярчен ряўешле булыб ингянне кюргян.

17 Шул чагында кюктян ауаз килгян: Шушы Минем сӧйӧкле Улым, Анда Минем ризалыгым, диб.

4-нче бюлем.

Зач. 7.

1 Шуннан суң Тын, шайтанга сынатыр ӧчӧн, Іисусны буш кырга алыб барган.

2 Анда (Іисусъ) кырык кӧн, кырык тӧн ураза тоткан, калдыгында ачыккан.

3 Сынаучы Анын катына килеб айткян: ӓгяр Син Алла Улы булсаң, айт, бу ташлар икмяк булсыннар, дигян.

4 Ул жауаб биреб айткян: кеше икмяк белян гня тора алмас, ӓммя Алла ауызыннан чыккан ӓр-бер сюз белян (торор), диб жазылган, дигян.

5 Аннары шайтан Аны арыу калага алыб барган; анда Аны чиркяў тюбясенен кырыйына бастырыб,

6 Аңар айткян; ӓгяр Син Алла Улы булсаң, тюбян сикер; жазылган ич: Сине Ӱз пяриштяляреня саклатыр, Сине алар кулларына кютяреб барырлар, аягың ташка сӧртӧнмяс, диб.

7 Іисусъ аңар айткян: тагы жазылган ич: Алла Ходайыңны сынама, диб.

8 Жяня тагы шайтан Аны бик бейек тау ӧстӧня алыб барган, (шуннан) дӧньядяге бар падшалыкларны, аларнын эямен кюрсятеб,

9 Аңар айткян: ӓгяр миңа жыгылыб башырсаң, шушыларны барысын да Сиңа бирем, дигян.

10 Шунда Іисусь аңар айткян: кит миннян шайтан, жазылган ич: Ходай Аллаңа гна башыр, бер Аңар гна кызмят ит, диб.

11 Аннары шайтан Анын жаныннан киткян; шундук пяриштяляр килеб Аңар кызмят иткянняр.

Зач. 8.

12 Іисусъ Іоаннын (ӧтӧрмянгя) жабылганын эшеткяч, Галилеяга киткян.

13 Аннары Назаретны ташлаб, Завулонъ белян Нефѳалимъ тиряляреня, дингез жарындагы Капернаумга барыб урыннашкан.

14 Шулай Исаія пагамбяр арткылы айтелеў жиреня килгян, ул айткян:

15 Завулонъ жире, Нефѳалимъ жире, дингез жулында, Іорданъ буйындагы жалган деннеляр торган Галилея,

16 Карангыда утырыучы калык зур жактыны кюргян, ӱлем карангысы торган жакта утырыучыларга жакты жакгырган, дигян.

17 Шул чактан Іисусъ сӧйляб жӧрӧй башлаган: тяўбя итегез, кюк падшалыгы жакыннашты инде, диб.

Зач. 9.

18 Галилея дингезе жаныннан ўткян чагында (Іисусъ) ике ага-энене Петръ дигян Симонны, анын энесе Андрейне кюргян; алар балыкчылар икян, дингезгя ау салалар икян.

19 Ул аларга йткян: Минем артымнан барыгыз, Мин сезне кешелярне тотоучы итярмен, дигян.

20 Алар шундук ауларын калдырыб, Анын артыннан киткянняр.

21 Аннан китеб бара торгач, Ул тагы ике ага-энене, Зеведей Іаковын, анын энесе Іоанны кюргян; алар аталары Зеведей белян кимядя ауларын тӧзятяляр икян; Ул аларны да чакырган.

22 Алар шундук аталарын да кимяне дя калдырыб, Анын артыннан киткянняр.

23 Іисусъ синагогаларда ӧйрятеб, Алла падшалыгынын изге хабярен сӧйляб, кешеляр арасындагы тӧрлӧ чирне, какшаулыкны тӧзятеб, бӧтӧн Галилеяны жӧрӧб бетергян.

24 Бӧтӧн Сирія жирендя Анын турысында эшетеб, Аҥар бар чирлелярне, тӧрлӧ ауырыуларны, ўз чирлелярне, женнелярне, жаҥа ай белян азаблана торганнарны, сансызларны китергянняр, Ул аларны тӧзяткян.

Зач.10.

25 Анын артыннан Галилеядан, Ун кала (дигян жирдян), Іерусалимнян, Іудеядян, Іорданнын ары жагыннан да кюб калык жӧргян.

5-нче бюлем.

1 Іисусъ калыкларны кюреб, тау ӧстӧня менеб утыргач, Анын жанына ӧйрянеўчеляре килгянняр.

2 Ул аннары ауызын ачыб, аларны былай диб ӧйрятя башлаган:

3 Жыуаш кюҥелляляр бахетле: кюк падшалыгы аларныкы шул.

4 Жылаучылар бахетле : алар сӧйӧнӧч табарлар шул.

5 Сабырлыклылар бахетле: аларга жир теяр шул.

6 Дӧрӧслӧккя ачыгыб, сыусаб тороучылар бахетле: алар тукланырлар шул.

7 Изгелекляляр бахетле: алар жарлыкаулы булырлар шул.

8 Таза кюҥелляляр бахетле: алар Алланы кюрерляр шул.

9 Татыуландырыучылар бахетле: алар Алла уллары диб аталырлар шул.

10 Дӧрӧслӧк ӧчӧн кыуылыучылар бахетле: кюк падшалыгы аларныкы шул.

11 Ӓгяр Минем какымда сезнен ӧстян жалганнаб, тӧрлӧ усал сюз айтсяляр, сезне курласалар, сезне кыусалар, сез бахетле.

12 Сӧйӧнӧгӧз, кыуаныгыз: сезгя кюктя теясе сауаб бик оло шул; сездян элеке булган пагамбярлярне дя шулай кыуганнар.

13 Сез жир тозо; тоз ўз кыуатын жугалтса, ней белян тозло итярсен? ул аннары бер нястягя дя жараусыз булыр, ул тик тышка чыгарыб, кеше аяк астына ташларга гна жарар.

Зач. 11.

14 Сез дӧнья жактысы. Тау тюбясендяге кала кюренмей тора алмас.

15 Эшямне дя жандыргач, сауыт астына угыртмыйлар, ӓммя эшямдялгя (утырталар), ул аннары ӧйдягелярнен барысына да жактыртыб тора.

16 Сезнен жактыгыз да кешеляр алдында шулай жактырсын: алар сезнен арыу эшлярегезне кюреб, кюктяге Атагызны даннасыннар ыйы.

17 Мин законны, пагамбярляр (сюзлярен) бозарга килгян диб уйламагыз, бозарга килмядем, ӓммя тутырырга килдем.

18 Чыннаб айтямен сезгя: кюк белян жир ўзгяргенче законнын бер сюзе дя, бер сызыгы да ўзгярмяс, ӓммя барысы да жиреня килер.

19 Кем дя кем шушы кечкеня гня бойорокларнын берсен ўзе бозоб, кешелярне да шулай ӧйрятся, ул кюк падшалыгында иҥ кечегя саналыр; ӓммя кем дя кем (аларны) ўзе кылыб, (бютяннярне дя) ӧйрятся, ул кюк падшалыгында олога саналыр.

Зач. 12.

20 Сезгя айтямен: ӓгяр сезнен дӧрӧслӧгӧгӧз князячелярнекеннян, фарисейлярнекеннян артык булмаса, сез кюк падшалыгына керя алмассыз.

21 Сез эшеткянсез боронголарга айткянне: ўтермя, кем ўтерся, хокӧмгя тейешле була, дигянне.

22 Ӓммя Мин сезгя айтямен: ўз туганына жукка ўпкя тотоучы ӓр-кем хокӧмгя тейешле; кем ўз туганына: эй жюнсез диб айтся, ул оло хокӧмгя тейешле; кем: эй тиле диб айтся, ул тамук утына тейешле.

23 Син бюлягенҥне алтарга алыб баргач, анда туганынҥнын синҥа ўпкясе бары исенҥя тӧшся,

24 Бюлягенҥне алтарь алдында калдыр да, барыб элеке туганынҥ белян татыуланыш, аннары кайтыб бюлягенҥне китер.

25 Даучынҥ белян жулда чагындук тизеряк татыуланыш, жугыйса даучынҥ сине тюрягя бирмясен, тюря сине кызмятчесеня биреб, ӧтӧрмянгя жабтырыр.

26 Чыннаб айтямен синҥа: калдык тейененҥне биреб бетермейче, аннан чыга алмассын.

Зач. 13.

27 Сез эшеткянсез боронголарга айткянне: уйнашлык итмя, дигянне.

28 Äммя Мин сезгя айтямен: катын-кызга азгын нявес белян караучы äр-кем ӱз кюҥелендя анын белян уйнашлык итеб бетергян була.

29 Äгяр уҥ кюзеҥ сине кызыктырса, син аны ӱзеҥнян сыуырыб алыб ташла: бöтöн тянеҥ тамук утына ташланасы булгынчы, саннарыҥнын берсе гня бетеӱе синеҥ öчöн жакшырак ич.

30 Äгяр сине уҥ кулыҥ кызыктырса, син аны ӱзеҥнян кисеб ташла: бöтöн тянеҥ тамук утына ташланасы булгынчы, саннарыҥнын берсе гня бетеӱе синеҥ öчöн жакшырак ич.

31 Тагы äйтелгян: кем катынын айырса, аҥар айырыу жазыуын биреб жибярсен диб.

32 Äммя Мин сезгя äйтямен: кем ӱз катынын уйнашлык айыбы булмаган кöйö айырыб жибярся, ул аны уйнашлыкка сала; кем айырыб жибяргян катынны алса, ул да уйнашлык итя.

Зач. 14.

33 Тагы эшеткянсез боронголарга äйткянне: иткян антыҥны бозма, Ходайга адарынганыҥны кыл, дигянне.

34 Äммя Мин сезгя äйтямен: ич тя карганма; кюк белян дя: ул Алла престолы шул;

35 Жир белян дя: ул Анын аяк асты шул; Іерусалимъ белян дя: ул оло Падшанын каласы шул.

36 Ӱз башыҥ белян дя карганма: син шул бер гня чячеҥне дя ак та кара да итя алмассын.

37 Сезнен сюзегез: эйе, эйе, жя жук, жук дейеӱ гня булсын; аннан артыгы жаманнан.

38 Сез эшеткянсез: кюзгя карышы кюз, тешкя карышы теш, дигянне.

39 Äммя Мин сезгя äйтямен: усалга карышы килмя. Беряӱ синеҥ уҥ жаҥагыҥа сукса, аҥар икенчесен дя бороб тот.

40 Беряӱ синеҥ белян даулашыб, кюлмягеҥне аласы ится, син аҥар öст кейемеҥне дя бир.

41 Беряӱ сине ӱзе белян бер чакырым барырга ирексезляся, анын белян икене бар.

Зач. 15.

42 Синнян сораганга бир, синнян äжяткя аласы килгяннян боролоб китмя.

43 Сез эшеткянсез: жакынынгны сӧй, дошманынгны кюрялма, дигянне.

44 Ӓммя Мин сезгя ӓйтямен: дошманнарыгызны сӧйӧгӧз, сезне каргаучыларга арыулык телягез, сезне кюрялмый торганнарга жакшылык кылыгыз, сезне кыйырсытыучылар ӧчӧн, сезне кыуыучылар ӧчӧн теляк итегез, диб.

45 (Шулай итсягез), сез кюктяге Атагызнын уллары булырсыз: Ул шу кояшын усалларга да, арыуларга да жактырта; жангырын гаделляргя дя, гадел тӧгӧлляргя дя жаудыра.

46 Ӓгяр сез ӱзегезне сӧйгяннярне гня сӧйсягез, сезгя нейдей сауаб булыр? мытарлар да шулай кылалар тӧгӧл ме?

47 Сез дустларыгыз белян гня исянняшсягез, ней артык кыласыз? Жалган деннеляр дя шулай кылынышалар тӧгӧл ме?

48 Кюктяге Атагыз арыулыкка ничек тулы, сез дя шулай тулы булыгыз.

6-нчы бюлем.

Зач. 16.

1 Сак булыгыз, сезне кеше кюрсен диб, садакагызны кеше алдында бирмягез: алай итсягез, сезгя кюктяге Атагыздан сауаб булмас.

2 Шунгар кюря син дя садака биргян чагында, кюз алдында гна кылыныучылар кюк ӱз алдынгнан жангыртма, алар ӱзлярен кешеляр мактасыннар диб, синагогаларда, урамнарда шулай кылыналар. Чыннаб ӓйтямен сезгя; алар инде ӱзлярeня теясене алалар.

3 Ӓммя син садака биргяндя унг кулынг ней кылганны сул кулынг белмясен.

4 Синенг садака биреӱенг жяшерен булсын; жяшерендяген кюреӱче Атанг синга ачыкта кайтарыр.

5 Син теляк иткян чагында да кюз алдында гна кылыныучылар кюк булма: алар кешеляр кюрсенняр диб, синагогаларда, урам чатларында туктаб келяӱ итеӱне сӧяляр. Чыннаб ӓйтямен сезгя: алар инде ӱзлярeня теясене алалар.

6 Ӓммя син теляк итяр чагында бюлмянгя кер дя, ишегенгне жабыб, жяшерендяге Атанга инял, жяшерендяген кюреӱче Атанг синга ачыкта кайтарыр.

7 Теляк иткяндя, жалган деннеляр кюк, артыгын ӓйтмягез, алар кюб сюз ӓйтеӱ арткылы эшетелербез диб уйлыйлар шул.

8 Аларга ошаулы булмагыз: (кюктяге) Атагыз сезгя ней киряген сез сорагынчук белядер шул.

9 Сез былай диб телягез: эй кюктяге Атабыз, данны булыб торсон исемеҥ Синеҥ.

10 Килсен падшалыгыҥ Синеҥ; жирдя дя кюктягечя булсын иркеҥ Синеҥ.

11 Бӧгӧн кӧннӧк икмягебезне бир безгя.

12 Бурычларыбызны кичер, без дя безгя бурычлы булганнарга кичергян кюк.

13 Безне алданырга ирек жибярмя; жаманнан коткар безне. Падшалык, кыуат, ололок гумергя Синеке шул. Аминь.

Зач. 17.

14 Сез кешеляргя жазыкларын кичерсягез, кюктяге Атагыз сезгя дя кичерер.

15 Ӓммя сез кешеляргя жазыкларын кичермясягез, кюктяге Атагыз сезнен жазыкларыгызны да кичермяс.

16 Сез ураза тоткан чагында да кюз алдында гна кылыныучылар кюк моҥайыб жӧрмягез; алар шу кешеляргя ураза тоткан булыб кюренер ӧчӧн гня, чырайларын карангыландырыб жӧрӧйляр. Чыннаб айтямен сезгя: алар инде ўзляреня теясене алалар.

17 Син ураза тоткан чагында башыҥны майла; битеҥне жыу;

18 Кешеляр алдында ураза тоткан булыб кюренмя, тик жяшерендяге Атаҥа гна кюрен; жяшерендяген кюреўче Атаҥ синҥа ачыкта кайтарыр.

19 Жир ӧстӧндя ўзегезгя мал жыймагыз, мында кӧя дя (тея), тутыгыб та бетя, бурлар да казыб кереб урлыйлар.

20 Ӓммя ўзегезгя малны кюктя жыйыгыз, анда кӧя дя (теймей), тутыкмый да, бурлар да казыб кереб урламыйлар.

21 Малыгыз кайда булса, кюҥелегез дя шунда булыр шул.

Зач. 18.

22 Тян жактырткычы кюз; ӓгяр синеҥ кюзеҥ таза булса, бӧтӧн тянеҥ дя жакты булыр.

23 Ӓгяр кюзеҥ начар булса, бӧтӧн тянеҥ дя карангы булыр. Ӓгяр эчеҥдяге жактыҥ карангы булса, синдя карангылык ней катле булыр?

24 Беряў дя ике байга кызмят итя алмас; жя берсен жаратыр, икенчесен жаратмас; жя берсеня кюҥелдян жӧрӧр, икенчесеня кюҥелсез гня жӧрӧр; сез дя Аллага да, байлыкка да кызмят итя алмассыз.

25 Шуҥар кюря сезгя айтямен: ней ашарбыз, ней эчярбез диб жаныгыз ӧчӧн коймягез, тянегез ӧчӧн дя ней киярбез диб (коймягез); жан ашамныктан, тян кейемнян оло тӧгӧл ме?

26 Ауа кошларына карагыз: алар чячмейляр дя, урмыйлар да, амбарга да жыймыйлар, алай да кюктяге Атагыз аларны туйдыра; сез алардан кюб кадерле тӧгӧл ме?

27 Кем сезнен арадан кӧйӧнӧб, ӳз буйын бер гня терсяк буйы арттыра алыр?

28 Кейем ӧчӧн дя ник кӧясез? Кырдагы чячяклярга карагыз, алар ничек ӳсяляр? эшлямейляр дя, эрлямейляр дя.

29 Мин сезгя айтямен: Соломонъ бик данныклы булса да, аларнын берсе чаклы да кейеня алмаган.

30 Ӓгяр дя бӧгӧн бар, иртягя пичкя ташларлык кыр ӳлямен Алла шундый кейендергяч, эй аз ышаныучылар, сезне бигрятктя жакшырак (кейендермяс) меней?

Зач. 19.

31 Шулай, сез ней ашарбыз, ней эчярбез, ней кеярбез диб кӧйӧнмягез.

32 Быларнын барын да жалган деннеляр эзлейляр шул; ул нястяляр барысы да сезгя киряк икянне кюктяге Атагыз белядер.

33 Иӈ элеке Алла падшалыгын, Анын дӧрӧслӧгӧн эзлягез, аннары ул нястяляр бар да сезгя ӧстяб бирелер.

34 Шулай, сез иртяге кӧн ӧчӧн кӧйӧнмягез, иртяге кӧн ӳзе ӧчӧн ӳзе кӧйӧнӧр. Ӓр-бер кӧнгя ӳзе ӧчӧн ӳз кӧйӧгӧ житяр.

7-нче бюлем.

Зач. 20.

1 Ӳзегезне тикшермясенняр дисягез, сез дя тикшермягез.

2 Кешене ничек тикшереӳ белян тикшерсягез, сезне дя (шулай) тикшерерляр шул; кешегя ничек ӳлчяӳ белян ӳлчясягез, сезгя дя шулай ӳлчярляр.

3 Ник туганыӈ кюзендяге ботакка карыйсын, ӓммя ӳз кюзеӈдяге бюряняне сизмейсен?

4 Жя ӳз кюзеӈдя бюряня булгач, туганыӈа ничек айтерсен: кая, мин синеӈ кюзеӈдяге ботакны алыйым? диб.

5 Эй кюз алдында гна кылыныучы! элеке ӳз кюзеӈдяге бюряняне ал, аннары туганыӈнын кюзендяге ботакны алырга кюрерсен.

6 Арыуны этлярга бирмягез, энжегезне дунгызлар алдына ташламагыз, алар аны аяклары белян табтамасыннар, боролоб ӳзегезне ӧзгяляб бетермясенняр.

Зач.

7 Сорагыз, бирелер сезгя; эзлягез, табарсыз; кагыгыз, ачарлар сезгя:

8 Ӓр-бер сораучы аладыр шул, эзляӳче табадыр, кагыб тороучыга да ачалар.

9 Жя сезнен арада улы икмяк сораса, аңар таш биреўче кеше бар мы?

10 Жя балык сораса, аңар жылан бирер меней?

11 Шулай, сез ўзегез жаман булыб та, балаларыгызга жакшыны биря белгяч, кюктяге Атагыз Ўзеннян сораучыларга жакшыны бигряк тя бирер.

Зач. 21.

12 Ăр-бер турыда кешеляр сезгя ней кылганны телясягез, сез дя аларга шулай кылыгыз: законъ да, пагамбярляр дя шулай (кушалар) шул.

13 Тар кабкадан керегез: киң кабка, иркен жул жукка чыгарырга алыб баралар шул:, кюбесе шулардан барадыр.

14 Тар кабка, кысан жул терелеккя алыб баралар; аларны ăзляр гня очраталар.

Зач. 22.

15 Жалган пагамбярлярдян сакланыгыз; алар сезнен катыгызга тышларыннан сарыктый (жыуаш) булыб киляляр, ăммя ўзляре эчлярендя талаучы бюреляр кюк.

16 Сез аларны жимешляреннян белерсез; чянечкеле агачтан жӧзӧм жыялар мы? жя тигяняк сабыннан смоква жыялар мы?

17 Шулай, ăр-бер жакшы агач жакшы жимеш китеря, ăммя начар агач начар жимеш китеря.

18 Жакшы агач начар жимеш китермяс, ăммя начар агач жакшы жимеш китермяс.

19 Жакшы жимеш китермей торган ăр-бер агачны кисеб утка ташлыйлар.

20 Шулай, сез аларны жимешляреннян белерсез.

Зач. 23.

21 Мине: Ходай, Ходай, диб ăйтеўче бар да кюк падшалыгына кермяс, тик кюктяге Атамнын иркен кылыучы гна (керер).

22 Шул кӧннӧ кюбесе Миңа ăйтерляр: эй Ходай, эй Ходай, без Синең исемең белян пагамбярлек иттек тӧгӧл ме? женнярне дя Синең исемең белян чыгардык тӧгӧл ме? Синең исемең белян кюб кодрятляр кылдык тӧгӧл ме? дирерляр.

23 Шул чагында аларга ăйтерем: Мин сезне бер чакта да белмядем, эй законсызлык кылыучылар, Миннян китегез, дирем.

Зач. 24.

24 Минем шушы сюзляремне тынҥнаб, аларны кылыучынын ӓр-
берсен, ӧйӧн таш ӧстӧня торгозган акыллы кешегя ошатырмын.

25 Жангыр жауыб, инҥешляр ташыб, жилляр жилляб (барысы да)
шул ӧйгя бярелгянняр, шунда да ул, нигезен таш ӧстӧня корганныктан,
аумаган.

26 Ӓммя Минем шушы сюзляремне эшетеб, аларны кылмаган ӓр-
кем, ӧйӧн ком ӧстӧня торгозган исябсез кешегя ошар.

27 Жангыр жауыб, инҥешляр ташыб, жилляр жилляб, (барысы да)
шул ӧйгя бярелгянняр; ул ӧй шундук ауыб, бӧтӧнняй жимерелеб
беткян.

28 Іисусъ шушы сюзлярне ӓйтеб бетергяч, Анын ӧйрятеӳеня
калыкнын исе киткян:

29 Ул шу аларны кодряте барын тойдорыб ӧйряткян, ӓммя
княгячеляр белян фарисейляр кюк тӧгӧл.

8-нче бюлем.

1 Іисусъ таудан тӧшкяч, Анын артыннан кюб калык барган.

2 Шунда тяне кутырлаган бер кеше Анын жанына килеб, Анҥар
башырыб ӓйткян: эй Ходай! телясянҥ, Син мине тазарта алыр ыйынҥ,
дигян.

3 Іисусъ кулын сузыб, анҥар тейенеб ӓйткян: телеймен, тазарын,
дигян: шул сяттюк ул кутырыннан тазарган.

4 Іисусъ анҥар ӓйткян: анҥ бул, беряӳгя дя ӓйтмя; тик барыб ӳзенҥне
священниккя кюрсятеб, Моисей законында кушканча, аларга
таныклыкка бюляк китер, дигян.

Зач. 25.

5 Іисусъ Капернаумга кергяч, Анын катына бер сотникъ килеб,

6 Анҥар ӳтенгян: Эй Ходай! ӧйдя кызмятчем сансызланыб жата,
каты азаблана, дигян.

7 Іисусъ анҥар ӓйткян: Мин барыб, аны тӧзятермен, дигян.

8 Сотникь Анҥар жауаб биреб ӓйткян: эй Ходай! Син минем ӧйӧмя
керергя мин тейешле тӧгӧл, Син тик сюз гня ӓйт, шул сяттюк
кызмятчем сауыгыр, дигян;

9 Мин шу ӳзем кеше кул астындагы кеше булсам да, Ӳз кулымда
салдатлар тотам; берсеня: бар, дисям, бара; икенчесеня: кил, дисям,
киля; кызмятчемя: мыны кыл, дисям, ул кыладыр, дигян.

10 Іисусъ мыны эшеткяч, исе китеб, артыннан килеӳчеляргя ӓйткян:
чыннаб ӓйтямен сезгя: Израилдя дя бу катле ышаныуны табмадым,
дигян.

11 Сезгя айтямен: кюбесе кояш чыгышыннан, кояш байышыннан килеб, Авраамъ белян, Исаакъ белян, Іаковъ белян бергя кюк падшалыгында урыннашырлар.

12 Äммя бу падшалыкнын уллары тыштагы карангылыкка кыуыб чыгарылырлар, анда жылаб, теш шыкырдатыу булыр, дигян.

13 Іисусъ аннары сотникка äйткян: бар, ышанганынҷа синҕа булсын, дигян; анын кызмятчесе шул сяттюк сауыккан.

Зач. 26.

14 Іисусъ Петръ öйöня килгяч, анын катынынын анасын тир кастасы белян жатканын кюргян.

15 Іисусъ анын кулына тейенеўе белян тир кастасы беткян; шундук тороб, ул Анҕар кызмят иткян.

16 Кич булгач, Іисусъ жанына кюб женнянгян кешелярне китергянняр; Ул сюзе белян женнярне кыуыб чыгарган; чирлелярне барысын да тöзяткян.

17 Шулай Исаія пагамбяр арткылы äйтелеў жиреня килгян; ул äйткян: äлсезлегебезне Ул Ўз öстöня алыб, чирляребезне кютярде, дигян.

18 Іисусъ Ўз äйлянясендя калык кюбне кюреб, (öйрянеўчеляреня) икенче жакка чыгарга кушкан.

19 Шунда бер укымыш кеше Анҕар килеб äйткян: эй Öйрятеўче! Син кая гна барсаҥ да, мин артыҥнан барым, дигян.

20 Іисусъ анҕар äйткян: тöлкöлярнен öнняре бар, ауа кошларынын да оялары бар, äммя Äдям Улынын баш салыб жатыр урны да жук, дигян.

21 Тагы öйрянеўчеляренен берсе Анҕар äйткян: эй Ходай! минҕа элеке, кайтыб атамны кюмяргя роксят бирче, дигян.

22 Іисусъ анҕар äйткян: Минем артымнан бар, ўлекляреп кюмяргя ўлектейлляргя калдыр, дигян.

Зач. 27.

23 Іисусъ кимягя кергяч, Анын артыннан öйрянеўчеляре дя кереб, Анын белян барганнар.

24 Шул чакта дингез öстöндя бик каты дауыл чыгыб, тулкыннар кимяне баса башлаганнар, äммя Ул жоклаган икян.

25 Öйрянеўчеляре килеб, Аны уятыб äйткянняр: эй Ходай, бетябез, безне сакла, дигянняр.

26 Ул аларга äйткян: эй аз ышаныучылар, сез ник алай куркыучан? дигян. Аннары Ул тороб, жилне дя, дингезне дя тыйыуы белян, тыб-тыныч булган.

27 Кешеляр исляре китеб айтешкянняр: бу кем, жил дя, дингез дя Аны тыңныйлар? дигянняр.

Зач. 28.

28 Іисусъ (дингезнен) икенче жагындагы Гергесинъ жиреня баргач, Аны ӱлек куя торган урыннардан чыккан ике женнянгян кеше очратканнар; алар бик усал икян, шунныктан ул жулдан беряӱ дя ӱтеб жӧрӧй алмаган.

29 Алар кинят кычкырганнар: эй Алла Улы Іисусъ, Синең бездя ней эшең бар? Син мында безне багыт житмяс борон азабландырырга килгянең, дигянняр.

30 Алардан жыраграк зур табын дунгыз кӧтяляр икян.

31 Женняр Аңар ӱтенгянняр: Син безне кыуыб чыгарсаң, безгя дунгыз кӧтӧӱеня барырга кушсана, дигянняр.

32 Ул аларга айткян: барыгыз, дигян; алар чыгыб, дунгыз кӧтӧӱеня киткянняр; шундук бӧтӧн дунгыз кӧтӧӱе текя жардан дингезгя атылыб, сыуга батыб беткян.

33 Ӓммя кӧтӧӱчеляр жӧгӧрӧб калага кайтканнар да, ней булганны барын да белдергянняр, женнеляргя ней булганны да (айткянняр).

34 Аннары бӧтӧн кала Іисусъ карышысына чыккан; Аны кюргяч, безнен тирядян китсяня диб, Аңар ӱтенгянняр.

9-нчы бюлем.

Зач. 29.

1 Ул аннары кимягя кереб, (дингезне) кичеб, кире Ӱз каласына кайткан.

2 Шунда Аңар бер сансызны жаткан урны белян кютяреб китергянняр; Іисусъ аларнын ышаныуын кюреб, сансызга айткян: улым, курыкма! сиңа жазыкларың кичереля, дигян.

3 Шунда князячелярнен кайсылары ӱз кюңелляренда: Ул Алланы курлый, дигянняр.

4 Іисусъ аларнын уйлаганнарын белеб айткян: сез кюңелегездя ник жаманны уйлыйсыз?

5 Ней асатрак айтергя: сиңа жазыкларың кичереля диб ме? ӓлля тор да, жӧрӧ диб ме?

6 Ӓммя Ӓдям Улынын жир ӧстӧндя жазыклар кичерергя кыуаты барын сез белсен диб, (айтямен дигян дя сансызга айткян): тор да, урныңны алыб, ӧйӧңя кайт, дигян.

7 Ул торган да, (урнын алыб) ӧйӧня киткян.

8 Калык мыны кюргяч, исе китеб, кешеляргя шундый кыуат биргян Алланы даннаган.

Зач. 30.

9 Іисусъ аннан китеб барышлый сатлык мал акчасын жыя торган тöштя утырган Матѳей атлы кешене кюреб, аңар äйткян: Минем артымнан бар, дигян; ул тороб, Анын артыннан киткян.

10 Іисусъ бер ӧйдя утырган чакта, кюб мытарлар белян жазыклылар килеб, Анын белян, öйрянеўчеляре белян бергя утырганнар.

11 Шуны кюреб, фарисейляр Анын öйрянеўчеляреня äйткянняр: сезнен Öйрятеўчегез ник алай мытарлар белян, жазыклылар белян бергя ашый, эчя? дигянняр.

12 Іисусь мыны эшетеб, аларга äйткян: сауларга лекарь киряк тöгöл, äммя чирлеляргя (киряк).

13 Барыгыз, Мин изгелек телеймен, äммя корман тöгöл, дигяннен ней икяненя öйрянегез. Мин жазыклыларны тяўбягя öндяргя килдем шул, äммя гаделлярне тöгöл, дигян.

Зач. 31.

14 Шул чакта Іоаннъ öйрянеўчеляре Іисуска килеб äйткянняр: без дя, фарисейляр дя кюб ураза тотабыз, äммя Синең öйрянеўчеляреӊ ней öчöн ураза тотмойлар? дигянняр.

15 Іисусъ аларга äйткян: туйдагы кодаларга, кеяў алар белян бергя чагында, кайгырыб торорга мöңким ме? алардан кеяў алыныр кöнняр килеб житкяч, алар шунда ураза тота башларлар.

16 Беряў дя тузган кейемгя агартмаган киндердян жамау салмый: жаңа жамау тузган кейемне айырыр да, жыртыгы элекегедян дя чагырак булыр шул.

17 Жаңа аракыны да иске турсыкка салмыйлар: салсаң, турсык жарылыр да, аракысы тюгелер, турсыгы да жарамаска чыгар; äммя жаңа аракыны жаңа турсыкка тутыралар, аннары алар икесе дя бöтöн кöйö торалар, дигян.

Зач. 32.

18 Ул аларга мыны сöйлягян чагында, Анын жанына бер башлык килеб, Аңар башырыб äйткян: минем кызым инде ўлгяндер дя, Син барыб анын öстöня кулыӊ салсана, ул аннары терелер эйе, дигян.

19 Іисусъ тороб, öйрянеўчеляре белян анын артыннан барган.

20 Шул чакта ун ике жыл кан агыуы белян азабланган бер катын Анын артыннан жакыннашыб, кейеменен кырыйына тейенгян.

21 Ул кюңелендя: Анын кейеменя гня тейенсям дя сауыгырмын, диб äйткян икян.

22 Іисусъ боролоб караган да, аны кюреб äйткян: кызым, курыкма! сине ышаныуыӊ коткарды, дигян; катын шул сяттюк сауыккан.

23 Іисусъ башлык öйöня кергяч, быргычыларны, калык болганганны кюреб,

24 Аларга әйткән: мыннан чыгыгыз, кыз ўлмягәння баса, жоклой ич, дигян; алар Аннан кӧлгяннәр.

25 Ул калыкны чыгаргач, кереб кызнын кулыннан тотоу белян кыз торган.

26 Бу эш турысында хабяр шундагы бар жиргя жяйелгян.

Зач. 33.

27 Іисусъ аннан китеб барганда, Анын артыннан ике сукыр кеше: эй Давидъ Улы, (Іисусъ), безне жарлыка, диб кычкырыб барганнар.

28 Ул бер ӧйгя кергяч, Анын жанына сукырлар да килгяннәр. Іисусъ аларга әйткән: бу эшне булдырырыма ышанасыз мы? дигян. Алар Аӊар әйткәннәр: эйе шул, Ходай, (ышанабыз), дигяннәр.

29 Шуннан суӊ кюзляреня тейенеб, Ул аларга әйткән: ышаныуыгыз буйынча сезгя булсын, дигян.

30 Шундук аларнын кюзляре ачылган. Іисусъ аларга кисятеб әйткән: карагыз, мыны беряў дя белмясен, дигян.

31 Ӓммя алар чыгыб, шундагы бар жиргя Аны даныктырганнар.

32 Алар чыгыб килгян чакта, Аӊар бер женнянгян телсез кешене китергяннәр.

33 Женен чыгаргач, телсез сӧйляшя башлаган. Калык исе китеб әйткән: мындый эш Израилдя бер чакта да булганы жук ыйы, дигяннәр.

34 Ӓммя фарисейляр әйткәннәр: Ул женнярне женняр башлыгынын кӧчӧ белян чыгара, дигяннәр.

35 Іисусъ бар калаларда, ауылларда, андагы синагогаларда ӧйрятеб, Алла падшалыгынын изге хабярен сӧйляб, кешеляр арасындагы ӓр-бер чирне, какшаулыкны тӧзятеб жӧргян.

Зач. 34.

36 Іисусъ жыйын калыкны кюреб, кӧтӧўчесез сарыклар кюк таралышыб жӧдяб жӧрӧйляр диб, аларны кызганган.

37 Шул чакта Ул ӧйрянеўчеляреня әйткән: урасы ашлык кюб, ӓммя эшчеляр ӓз, дигян.

38 Шуӊар кюря ашлык Эясеня ўтенегез, Ул урагына эшчеляр жибярсен, дигян.

10-нчы бюлем.

1 Іисусъ ун ике ӧйрянеўчелярен чакырыб алыб, аларга женнярне чыгарырга, ӓр-тӧрлӧ чирне, какшаулыкны тӧзятергя кыуат биргян.

2 Ун ике Апостолларнын атлары блай: элекегесе Петръ дигян Симонъ, анын энесе Андрей; Зеведей улы Іаковъ, анын энесе Іоаннъ;

3 Филиппъ, Варѳоломей; Ѳома, мытарь Матѳей, Алѳей улы Іаковъ, Ѳаддей дигян Леввей;

4 Кананитъ (дигян) Симонъ, Искаріотъ Іудасы, шушысы Іисусны тотоб биргян.

5 Шушы ун икене жибяргян чакта Іисусъ аларга бойороб айткян: жалган деннеляр жулына бармагыз, Самарія каласына да кермягез,

6 Äммя бигряк Израиль жортонын жугалган сарыкларына барыгыз.

7 Кюк падшалыгы жакыннашты диб сöйляб жöрöгöз.

8 Чирлелярне тöзятегез, кутырлы тяннелярне тазартыгыз, ÿлгяннярне терелтегез, женнярне кыуалаб чыгарыгыз; буш алдыгыз, буш бирегез, дигян.

Зач. 35.

9 Эзярегезгя ÿзегез белян алтын, кöмöш, бакыр алмагыз.

10 Жулга кабчык та, икешяр кейем дя, башмак та, таяк та (алмагыз): эшляÿчегя (тормошына) киряклене бирергя тейеш ич.

11 Нейдей калага, жя ауылга керсягез дя, анда кем жарардый икянне сораб белегез дя, киткенче шунда торогоз.

12 Öйгя кергяндя: бу öйгя тынычлык булсын диб айтеб, öйдягеляр белян исянняшегез.

13 Äгяр ул öй тейешле булса, (телягян) тынычлыгыгыз аҥар килер, äгяр ул тейешсез булса, (телягян) тынычлыгыгыз ÿзегезгя кайтыр.

14 Äгяр кем дя кем сезне кабыл алмаса, сюзляregезне дя тыҥнамаса, сез шул öйдян, жя каладан чыгышлый, аякларыгыздагы тупракны селкеб тöшöрöгöз.

15 Чыннаб айтямен сезгя: сорау кöнöндя Содомъ белян Гоморра жиреня ул калага караганда жиҥелеряк булыр, дигян.

Зач. 36.

16 Мына Мин сезне сарыкларны бюреляр арасына жибяргяндей жибярямен: шуҥар кюря сез жылан кюк хайляле булыгыз, кюгярчен кюк таза кюҥелле булыгыз.

17 Кешелярдян сакланыгыз: алар шул сезне хокöмгя бирерляр, синагогаларында сезне кыйнарлар.

18 Минем сяятлей сезне тюрялярга, падшаларга житякляб итярляр, алар алдында, жалган деннеляр алдында (Минем турда) таныклык итяр öчöн.

19 Сезне тотоб биргян чакта, ничек айтербез диб кöйöнмягез: шул сагаття айтясе сюз сезгя бирелер.

20 Айтеÿчеляр сез булмассыз, äммя Атагызнын Тыны сезнен эчегездя айтеб торор.

21 Агасы энесен, атасы улын тотоб ÿлемгя бирер, балалары ата-аналарына карышы тороб, аларны ÿтерерляр.

22 Минем исемем өчөн сезне бар да кюрялмаслар, алайда калдыкка чаклы тюзгяне котолор, дигян.

Зач. 37.

23 Сезне бер каладан кыусалар, сез икенчегя китегез. Чыннаб айтямен сезгя: сез Израиль калаларын жөрөб бетеря алмассыз, әммя Әдям Улы килер.

24 Өйрянеўче өйрятеўчедян оло төгөл, кызмятче дя эясеннян оло төгөл.

25 Өйрянеўчегя өйрятеўчесе кюк булса, кызмятчегя эясе кюк булса, житяр.Өйнен эясен веельзевулъ диб атагач, анын өйөндягелярен бигеряк тя шулай атарлар төгөл ме?

26 Шуҥар кюря сез алардан курыкмагыз: жяшергян нястянен ич-берсенен кюренмей калганы жук, жяшерендягенен беленмей калганы да жук шул.

27 Мин сезгя карангыда айткянне сез жактыда айтегез, колагыгызга гна эшеттергянне сез өй тюбясеня менеб сөйлягез.

28 Тянне ўтереўчелярдян, әммя жанны ўтеря алмый торганнардан курыкмагыз; бигеряк жанны да, тянне дя тамукта харяб итяргя кыуаты бардан куркыгыз.

29 Ике чыбчык бер гня ассарійг тора төгөл ме? Алайда аларнын берсе дя Атагызнын (ирке) булмаса, жиргя жыгылмас.

30 Әммя сезнен башыгыздагы чячегез дя барысы да санаулы.

31 Шуҥар кюря сез курыкмагыз: сез кюб чыбчыклардан кадерлеряк, дигян.

Зач. 38.

32 Кем дя кем Мине кешеляр алдында айтеб белдерся, Мин дя аны кюктяге Атам алдында айтеб белдерем.

33 Әммя кем дя кем Мине кешеляр алдында таҥса, Мин дя аны кюктяге Атам алдында таҥарым.

34 Мине жиргя тынычлык китерергя килгян диб уйламагыз, Мин тынычлык китерергя килмядем, әммя кылыч (китерергя килдем).

35 Мин шу кешене атасыннан, кызын анасыннан, киленен бейеменнян айырырга килдем.

36 Кешенен дошманнары ўз өйөндягеляре, дигян.

Зач. 39.

37 Ўз атасын, жя анасын Миннян артык сөйгян кеше, Миҥа жараулы төгөл; ўз улын, жя кызын Миннян артык сөйгян кеше дя Миҥа жараулы төгөл.

38 Ўз качын алыб, Минем артымнан бармаган кеше дя Миҥа жараулы төгөл.

39 Жанын саклаган кеше аны жуяр, äммя жанын Минем öчöн жуйган кеше аны табар.

40 Сезне кабыл алган кеше Мине кабыл ала, äммя Мине кабыл алган кеше Мине Жибяреўчене кабыл ала.

41 Пагамбярне пагамбярлеге какына кабыл алган кеше, пагамбяргя теярдей сауабны алыр; гаделне гаделлеге какына кабыл алган кеше дя гаделгя теярдей сауабны алыр.

42 Шушы кечкенялярнен берсеня öйрянеўчелеге какына бер гня сауыт салкын сыу эчерткян кеше дя, чыннаб äйтямен сезгя: сауабын алмый калмас, дигян.

11-нче бюлем.

1 Іисусъ ун ике öйрянеўчесеня бойороб бетергяч, аннан аларнын калаларында öйрятергя, сöйляргя барган.

Зач. 40.

2 Іоаннъ öтöрмяндя чагында, Христосъ кылган эшлярне эшеткяч, ике öйрянеўчесен жибяреб,

3 Ангар äйттергян: Килясе дигян Син ме, äлля бютянне кöтöйöк ме? диб.

4 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: кайтыгыз да, ней кюргянегезне, ней эшеткянегезне Іоаннга äйтегез:

5 Сукырлар кюряляр, аксаклар (тöзöк) жöрöйляр, кутырлы тяннеляр тазаралар, саңраулар эшетяляр, ўлгянняр тереляляр, жарлылар изге хабяр сöйлöйляр, диб.

6 Äммя Минем турда шиклянмягян кеше бахетле, дигян.

7 Алар киткяч, Іисусъ калыкка Іоаннъ турысында äйтя башлаган: сез буш кырга ней кюрергя бардыгыз? жилдян тирбянгян камышны мы?

8 Суң ней кюрергя бардыгыз? Жомошак кейем кейгян кешене ме? Жомошак кейем кейеўчеляр падша жортонда торалар ич.

9 Ней кюрергя бардыгыз суң? Пагамбярне ме? эйе, сезгя äйтямен: пагамбярдян дя олоно.

10 Мына Мин Синең алдыңнан Ўз пяриштямне жибярямен, ул Синең алдыңнан жулыңны äзерляб куяр диб жазылган ўзе шушы шул.

11 Чыннаб äйтямен сезгя: катыннардан тыуганнар арасында чумылдырыучы Іоаннан оло булмады, äммя кюк падшалыгындагыларнын иң кечесе аннан оло.

12 Чумылдырыучы Іоаннъ кöнняреннян бирле äлегя чаклы кюк падшалыгын алырга бик тырышалар; тырышыучылар аны алалар.

13 Бар пагамбярляр дя, законъ да буласыны Іоаннга чаклы гна äйттеляр.

14 Тагы, кабыл аласы итсягез, ул килясе дигян Илія ўзе.

15 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 41.

16 Бу тыуманы кемгя ошатыйым суҥ? ул урамнарда утыра торган балаларга ошаулы; алар ўз иптяшляреня боролоб,

17 Äйтяляр: без сезгя сыбызгы уйнадык, сез бейемядегез; без сезгя жыларлык жырыулар жырладык, сез жыламадыгыз, дейляр.

18 Іоаннъ килде, ашамый да эчмей дя, анда жен бар, дейляр.

19 Äдям Улы килде, ашый да эчя дя, Аны äйтяляр: мына ашауны, эчеўне жарата торган кеше, мытарларнын, жазыклы кешелярнен дусы, дейляр. Белемнекне ўз оланнары дöрöсляделяр, дигян.

Зач.42.

20 Шуннан суҥ Іисусъ Ўзенен бик кюб кодрятлярен кюрсяткян калаларны, тяўбягя килмягянняре öчöн, äрлей башлаган.

21 Айгай сиҥа, Хоразинъ! айгай сиҥа, Виѳсаида! äгяр сездя булган кодрятляр Тиръ белян Сидонда булган булсалар, алар инде кюбтян алама кейем кейеб, (башларына) кöл сибеб, тяўбя итярляр эйе шул.

22 Тагынук сезгя äйтямен: Тиръ белян Сидонга сорау кöнöндя сезгя кюря жиҥелеряк булыр.

23 Син дя эй кюккя чаклы кютярелгян Капернаумъ, тамукка чаклы тöшöрöлöрсен; äгяр синдя булган кодрятляр Содомда булган булсалар, ул бöгöнгя чаклы торор ыйы.

24 Тагынук сезгя äйтямен: сорау кöнöндя Содомъ жиреня сезгя кюря жиҥелеряк булыр, дигян.

25 Шул чакта Іисусъ сöйляўеннян туктамыйчы äйткян: эй Äтей, эй кюкнен, жирнен Ходайы! Син мыны белемнелярдян, акыллылардан жяшереб, балаларга кюрсяткянеҥ öчöн Сине данныймын.

26 Эйе, Äтей! Синеҥ иркеҥ шулай булды шул, дигян.

Зач. 43.

27 Миҥа Атамнан äр-ней бирелде; Улны Атадан бютян беряў дя белмей, Атаны да тик Улы гна беля, тагы Улы кемгя белдерясе кился, шул гна.

28 Эй читеннектя тороучылар, ауырлык кюреўчеляр, барыгыз да Миҥа килегез, Мин сезне тынычландырым.

29 Минем жöгöмне кютярегез, Минням öйрянегез: Мин сабырлыклы шул, жыуаш кюҥелле; шуннан жаныгызга тынычлык табарсыз.

30 Минем жöгöм арыу, Минем кютярямем жиҥел шул, дигян.

12-нче бюлем.

Зач. 44.

1 Шул чакта Іисусь суббота кӧннӧ ашлык басыуыннан ӱтеб барган; ӧйрянеӱчеляре карыннары ачкач, ашлык башларын ӧзӧб-ӧзӧб ашый башлаганнар.

2 Фарисейляр мыны кюреб, Аҥар айткянняр: мына Синеҥ ӧйрянеӱчелярең суббота кӧннӧ кыларга тейеш тӧгӧлне кылалар, дигянняр.

3 Äммя Ул аларга айткян: Давидъ ӱзе дя, анын белян булган кешеляр дя ачыккач, ул ней кылганны укымадыгыз мы ӓлля?

4 Ничек ул Алла ӧйӧня кереб, ӱзеня дя, анын белян булганнарга да ашарга тейеш тӧгӧл, тик священникляргя гня ашарга тейешле китереб куйылган икмяклярне ашаганны.

5 Тагы сез суббота кӧннярдя чиркяӱдя священникляр субботаны бозсалар да, айыблары жукны законда укымадыгыз мы ӓлля?

6 Мин сезгя айтямен: мында чиркяӱдян дя Оло бар.

7 Äгяр сез: Мин изгелек телеймен, ӓммя корман тӧгӧл, дигяннен ней икянен белсягез, айыбсызларны айыбламас ыйыгыз.

8 Äдям Улы субботага да башлык шул, дигян.

Зач. 45.

9 Шуннан китеб Ул аларнын синагогаларына кергян.

10 Анда кулы короган бер кеше булган. Іисусны айыблар ӧчӧн, Аннан сораганнар: суббота кӧннӧ (чирлелярне) тӧзятергя мӧҥким ме? дигянняр.

11 Ул аларга айткян: кем сезнен арада бердян бер сарыгы булыб, ул суббота кӧннӧ базга тӧшся,аны аннан чыгарыб алмас?

12 Кеше сарыктан кюб артык тӧгӧл ме? Алай булгач, суббота кӧннӧ изгелек кыларга мӧҥким, дигян.

13 Аннары Ул шул кешегя айткян: кулыҥны суз, дигян; ул сузган; сузгачук анын кулы сауыгыб, икенчесе кюк булган.

Зач.46.

14 Фарисейляр барыб, Іисусны ничек итеб бетерергя киҥяш иткянняр, ӓммя Ул аны белеб, аннан киткян.

Зач.

15 Анын артыннан бик кюб калык барган, Ул аларнын (чирлелярен) барысын да тӧзяткян.

16 Аларга Ӱз турысында беряӱгя дя айтергя кушмаган.

17 Шулай итеб, Исаія пагамбяр арткылы айтелеӱ жиреня килгян; ул айтя:

18 Мына Минем сайлаб алган Мяндям, жаным жараткан сӧйӧклӧм; Мин Аҥар Ӱз Тынымны салырым, Ул кешеляргя дӧрӧслӧк белдерер.

19 Ул карышы сюз äйтмяс, кычкырмас, Анын тауышын урамнарда беряӱ дя эшетмяс.

20 Дӧрӧслӧкнӧ ӧскя чыгаргынчы, Ул имгянгян камышны да сындырмас, пыскыб торган житенне дя сюндермяс.

21 Калыклар Анын исеменя ӧмӧт тотарлар, дигян.

22 Шул чакта Анын жанына бер женнянгян, сукыр, телсез кешене китергянняр; Ул аны тӧзяткян; шундук сукыр, телсез кеше сӧйляшя дя, кюря дя башлаган.

23 Бар калык исе китеб äйткян: Давидъ улы Христосъ шушы тӧгӧл микян? диб.

24 Фарисейляр мыны эшетеб, äйткянняр: Ул женнярне женняр башлыгы веельзевулъ кӧчӧ белян кыуыб чыгара, дигянняр.

25 Äммя Іисусъ аларнын уйларын белеб, аларга äйткян: äр-бер падшалык ӱзе ӱз алдына айырылышса, буш калыр; äр-бер каланын да, äр-бер жортнын да ӱзе ӱз алдына айырылышканы тора алмас.

26 Äгяр шайтан шайтанны кыуыб чыгарса, ул ӱзе ӱзендя айырылган була; алай булгач, анын падшалыгы ничек тора алыр суӊ?

27 Äгяр Мин женнярне веельзевулъ кӧчӧ белян кыуыб чыгарам икян, сезнен улларыгыз кем кӧчӧ белян кыуыб чыгаралар суӊ? Шул сяятлей алар сезгя хокӧм итярляр.

28 Äгяр Мин женнярне Алла Тыны белян кыуыб чыгарам икян, инде айса сезгя Алла падшалыгы килеб житкян.

29 Жя кем кӧчлӧ кешенен ӧйӧня кереб, элеке кӧчлӧнӧн ӱзен бяйлямяся, анын нястялярен ничек талый алыр? шул чакта гна анын ӧйӧн талый алыр ич, дигян.

Зач. 47.

30 Минем белян тӧгӧлӧ, Миӊа карышы; Минем белан бергя жыймаганы, тарата.

31 Шуӊар кюря сезгя äйтямен: äр-бер жазык та, курлау да кешеляргя кичерелер, äммя (Святый) Тынны курлау кешеляргя кичерелмяс.

32 Äгяр кем Äдям Улына (курлык) сюз äйтся, аӊар кичерелер, äммя кем Святый Тынны (курлаб) äйтся, аӊар бу дӧньядя дя, буласы дӧньядя дя кичерелмяс.

33 Агачын жакшыга куйсагыз, жимешен дя жакшыга куйыгыз; жя агачын начарга куйсагыз, жимешен дя начарга куйыгыз: агач жимешеннян беленя шул.

34 Эй жылан тыумалары! сез ӱзегез усал булгач, арыуны ничек сӧйлярсез? Ауыз кюӊел тулылыктан сӧйляшя шул.

35 Жакшы кеше жакшы сауытыннан жакшыны чыгара, äммя жаман кеше жаман сауытыннан жаманны чыгара.

36 Сезгя äйтямен: кешеляр бушка äйткян äр-бер сюзляре öчöндя сорау кöнöндя жауаб бирерляр.

37 Ӯз сюзеӊнян дöрöскя чыгарсын, ӯз сюзеӊнянӯк айыбланырсын шул, дигян.

Зач. 48.

38 Шул чакта княгячеляр белян фарисейлярнен кайсылары äйткянняр: эй Öйрятеӯче, без Синнян бер тöрлö билге кюрясебез киля, дигянняр.

39 Äммя Ул аларга жауаб биреб äйткян: усал, азгын тыума билге эзлей, тик аӊар Іона пагамбяр билгесеннян бютян билге бирелмяс:

40 Іона китъ эчендя öч кöн, öч тöн торган кюк, Äдям Улы да жир эчендя öч кöн, öч тöн торор.

41 Ниневія кешеляре бу тыума белян сораудa тороб, аны айыблaрлар, алар шу Іона (пагамбяр) сöйляӯеннян тяӯбягя килделяр, äммя мында Іонадан да Оло бар.

42 Тöшлöк жагындагы катын падша, бу тыума белян сораудa тороб, аны айыблар; ул шу Соломонъ белемнеген эшетергя жир читляреннянӯк килде, äммя мында Соломоннан да Оло бар.

43 Жен кеше эченнян чыккач, сыусыз жирлярдян ӯзеня тыныч урын эзляб жöрöй, тик таба алмый.

44 Аннары äйтя: кая кабат ташлаб чыккан öйöмя кайтыйым, дей; кайткач аны буш кöйö, себергян кöйö, матурлаган кöйö очрата.

45 Ул аннары барыб, ӯзе белян бергя тагы ӯзеннян дя жаманырак бютян жиде женне эяртеб киля дя аӊар кереб торалар; ул кешегя сунгысы элекегесеннян дя кыйынырак була. Бу жаман тыумага да шулай булыр, дигян.

Зач. 49.

46 Ул калык белян сöйляшеб торган чакта, анасы да, агалары да Анын белян сöйляшяселяре килеб, тышта торалар икян.

47 Шунда беряӯ Аӊар äйткян: мына анаӊ да, агаларыӊ да, Синеӊ белян сöйляшяселяре килеб, тышта торалар дигян.

48 Äммя Ул мыны äйтеӯчегя жауаб биргян: кем Минем анам? кем Минем агаларым? дигян.

49 Аннары öйрянеӯчеляреня таба кулын сузыб äйткян: мына Минем анам, мына Минем агаларым, диб.

50 Кем дя кем Минем кюктяге Атамнын иркен кылса, шул Миӊа ага-эне, тута-сеӊел, ана да, дигян.

13-нчö бюлем.

1 Шул көннө Іисусъ өйдян чыгыб, дингез жарына барыб утырган.

2 Анын жанына кюб калык жыйылган, шунныктан Ул кимягя кереб утырган; калык бар да жар читендя торган.

3 Ул аларны кюб мясалляр айтеб былай өйряткян:

Зач. 50.

4 Мына чячеўче чячяргя чыккан. Чячкян чагында кайсы бөртөкляре жул кырыйына төшкянняр; кошлар килеб, аларны чюбляб бетергянняр.

5 Кайсылары ташлык жиргя төшкянняр, анда балчык аз гна булган, балчык сай булганныктан алар тизюк тишелеб чыкканнар.

6 Кояш чыккач, алар шиңеб беткянняр дя, тамырлана алмаганга кюря, короганнар.

7 Кайсылары тигяняклеккя төшкянняр; тигяняк ўсеб житкяч, аларны басыб бетергян.

8 Кайсылары жакшы жиргя төшкянняр дя, жимеш китергянняр: кайсысы жөз бөртөк, кайсысы алтмыш бөртөк, кайсысы утыз бөртөк.

9 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 51.

10 Анын жанына өйрянеўчеляре килеб, Аңар айткянняр: ник Син аларга мясалляр белян сөйлөйсен? дигянняр.

11 Ул аларга жауаб биреб айткян: сезгя кюк падшалыгынын жяшереннярен белергя бирелгян шул, әммя аларга бирелмягян.

12 Барга бирелер, арттырылыр да, әммя жуктан ней бары да алыныр.

13 Алар караб та кюрмейляр, тыңнаб та эшетмейляр, аңнамыйлар да, шунныктан аларга мясял белян айтямен.

14 Исаія пагамбярнен алдан айтеўе аларга туры киля, ул айткян: эшетеўен эшетерсез, әммя аңнамассыз; карауын карарсыз, тик кюрмяссез.

15 Бу кешелярнен кюңелляре катыланган; алар колаклары белян дя көчкя эшетяляр, кюзлярен дя жомганнар, кюзляре белян кюрмяс өчөн, колаклары белян тыңнамас өчөн, кюңелляре белян аңнамас өчөн, Миңа кайтмас өчөн, әммя Мин аларны төзятер эйем, дигян.

16 Әммя сезнен кюзлярегез, кюреб торганнарына кюря, колакларыгыз да, эшетеб торганнарына кюря, бахетле.

17 Чыннаб айтямен сезгя: кюб пагамбярляр, кюб гадел (кешеляр) сез кюря торганны кюряселяре килде, алайда кюрмяделяр; сез эшеткянне эшетяселяре килде, тик эшетмяделяр.

18 Сез инде чячеўче турысында айткян мясялнен (аңын) тыңнагыз.

19 Падшалык турысында йтелгян сюзне эшетеб, аны аңнамаган ӓр-бер кешегя шайтан килеб, анын кюңеленя чячкянне алыб китя: мына жул кырыйына чячелгяне шул.

20 Ташлык жиргя чячелгяне бу була: беряў сюзне эшеткяч, аны тизюк сӧйӧнӧч белян кабыл ала.

21 Тик жяйелгян тамыры жукка кюря, ныклыгы да булмаганга кюря, аңар эшеткян сюзе ӧчӧн кайгы, жя кысаннык кюрергя туры кился, шундук шикляня башлый.

22 Тигяняклеккя чячелгяне бу була: беряў сюзне эшетеўен эшетя, тик бу гумернен сагышлары, байлыкка алданыулык (эшеткян) сюзен басыб бетеря, аннары ул сюз жимеш китермей.

23 Ӓммя жакшы жиргя чячелгяне бу була: беряў сюзне эшетеб, аны аңнаб ала да, жимеш китеря; кайсысы жӧзярне, кайсысы алтмышарны, кайсысы утызарны (китеря) дигян.

Зач. 52.

24 Ул аларга тагы бютян мясял айткян: кюк падшалыгы басыуына арыу орлок чячкян кешегя ошой.

25 Кешеляр жоклаган чагында, анын дошманы килеб, бодай арасына бакралар чячеб киткян.

26 Бодай ўсеб, баш чыгара башлагач, бакралар да кюренгянняр.

27 Кызмятчеляр эяляреня килеб айткянняр: эй кужа! син басыуыңа жакшы орлок кна чячкян эйең тӧгӧл ме? анда бакралар каян булган суң? дигянняр.

28 Ул аларга айткян: мыны дошман кеше кылган, дигян; кызмятчеляре тагы аңар айткянняр: телясяң, без барыб аларны утар ыйык? дигянняр.

29 Ӓммя ул (аларга) айткян: жук, сез бакраларны утаган чакта, алар белян бергя бодайны да жолкорсыз.

30 Урыр багыт житкенче икесен дя бергя ўсяргя калдырыгыз; урган чакта мин уракчыларга айтерем: элеке бакраларны, утка жагарга диб, жыйыб кӧлтялягез, аннары бодайны келятемя жыйыб куйыгыз, дирем.

Зач. 53.

31 Ул аларга жяня бютян мясял айткян: кюк падшалыгы бер кеше алыб барыб, басыуына чячкян горчица орлогона ошой:

32 Ул бар орлоклардан да ыуак орлок булса да, ўсеб житкяч, бар ўлямнярдян дя узыб, агач була, ботакларына ауа кошлары очоб килеб, кунакларлык була, дигян.

33 Жяня тагы аларга бютян мясял айткян: кюк падшалыгы ӓчеткеч апарага ошой: аны бер катын алган да, ӧч ӱлчяӱ онга катыштырыб, бары бергя ӓчеб житкенче, ӓчергя куйган.

34 Быларны Іисусъ калыкка барын да мясял белян сӧйлягян, ӓммя мясялсез аларга ич нястя дя сӧйлямягян.

35 Шулай итеб, пагамбяр арткылы ӓйтелгян сюз жиреня килгян; ул ӓйткян: ауызымны мясялляр китереб сӧйляргя ачармын, дӧнья жаралганнан бирле жяшерен торганнарны ӓйтермен, дигян.

36 Аннары Іисусъ калыкны жибяреб, бер ӧйгя кергян.

Зач. 54.

Ӧйрянеӱчеляре Іисусъ жанына килеб ӓйткянняр: басыудагы бакралар турысында ӓйткян мясялне безгя аңнатчы, дигянняр.

37 Ул аларга жауаб биреб ӓйткян: жакшы орлок чячеӱчесе Ӓдям Улы;

38 Басыу дигяне-дӧнья, жакшы орлок дигяне-падшалык уллары, ӓммя бакралар дигяне-жаманнык уллары;

39 Бакралар чячкян дошман дигяне-шайтан, урыр багыт дигяне-дӧнья бетеӱе, уракчылары-Пяриштяляр.

40 Бакраларны жыйыб, утка ничек жандыралар, шулай булыр шул бу дӧнья беткян чагында да.

41 Ӓдям Улы Ӱз Пяриштялярен жибярер, алар Анын падшалыгындагы бар алдаучыларны, законсызлык кылыучыларны жыярлар да,

42 Аларны утлы пичкя ыргытырлар, анда жылау, теш шыкырдатыу булыр.

43 Шул чакта гаделляр ӱз Аталарынын падшалыгында кояш кюк жалтраб торорлар. Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 55.

44 Жяня тагы кюк падшалыгы басыуга кюмгян малга ошойдыр: аны бер кеше табыб, беряӱгя дя ӓйтмейче, аңар сӧйӧнӧб кайта да, бар нястясен сатыб, шул басыуны аладыр.

45 Кюк падшалыгы тагы жакшы энжеляр эзляӱче купискя ошой:

46 Ул бик кыйбатлы бер энжене табкач, кайтыб, бар нястясен саткан да шул энжене алган.

47 Жяня тагы кюк падшалыгы дингезгя салган, тӧрлӧ балыклар кергян ауга ошой;

48 Ул тулгач, аны жар кырыйына тартыб чыгарганнар; аннары утырыб, жакшыларын сайлаб, сауытка тутырганнар, ӓммя начарларын читкя ташлаганнар.

49 Дӧнья беткян чагында да шулай булыр: Пяриштяляр чыгыб, усалларны гаделлярдян айырыб алырлар да,

50 Аларны утлы пичкя ыргытырлар; анда жылау, теш шыкырдатыу булыр, дигян.

51 Аннары Іисусъ аларга айткян: сез быларны барын да аӈнадыгыз мы? дигян. Алар Аӈар: эйе, Ходай, (аӈнадык), дигянняр.

52 Ул аларга тагы айткян: шуӈар кюря кюк падшалыгына ӧйрянгян ăр-бер укымыш кеше, ӱз сауытыннан жаӈаны да, искене дя ала торган жорт-эясе кешегя ошой, дигян.

Зач. 56.

53 Іисусъ шушы мясяллярне айтеб бетергяч, аннан киткян.

54 Ул аннары ӱскян жиреня барыб, алар синагогасында аларны ӧйряткян; алар: Анын бу катле белемнеге дя, кыуаты да каян икян диб, исляре китеб айткянняр:

55 Ул балта остасынын улы тӧгӧл меней суӈ? Марія диб Анын анасын атыйлар тӧгӧл ме? Іаковъ та, Іосій дя, Симонъ да, Іуда да Анын агалары ич.

56 Туталары да безнен арадала баса, Анын бу (белемнеге, бу кыуаты) бар да кайдан суӈ? дигянняр.

57 Шулай итеб, Анын турысында шик тотканнар. Ăммя Іисусь аларга айткян: пагамбяр ӱскян жирендяге чаклы, ӧйӧндяге чаклы бер жирдя дя кадерсез булмый, дигян.

58 Ышанмаганнарына кюря анда кодрятлярне кюб кылмаган.

14-нче бюлем.

Зач. 57.

1 Шул багытта (падшалыкнын) дюртенче ӧлӧшӧн биляб тороучы Иродъ, Іисусъ турысында сӧйляшкянне эшетеб,

2 Колларына айткян: бу чумылдырыучы Іоанндыр, ул ӱлгяненнян терелеб торгандыр, шуӈар кюря кодрятляр кыладыр, дигян.

3 Иродъ ӱз агасы Филиппь катыны Иродіада какында, Іоанны тотоб, бяйлятеб ӧтӧрмянгя жабтырган икян:

4 Іоаннъ Иродка: сиӈа аны катын итеб торорга жарамый диб онгай айткялягян шул.

5 Ул аны ӱтермякче дя булган, тик калыктан курыккан: калык аны пагамбяргя санаган шул.

6 Иродъ ӱзе тыуган кӧннӧ бяйрям иткян чагында, Иродіада кызы кунаклар алдында бейеб, Ироднын кюӈелен булдырган.

7 Шунын ӧчӧн Иродъ аӈар ней гня сораса да бирмякче булыб карганган.

8 Кыз, анасы ӧйряткян буйынча, айткян: минга мында чумылдырыучы Іоаннын башын табак белян бир, дигян.

9 Падша кайгыга тӧшкян; алайда карганганы буйынча, бергя утырыучылар алдында оятка калмас ӧчӧн, аңар бирергя кушкан.

10 Аннары жибяреб, ӧтӧрмяндя Іоаннын башын кистергян.

11 Анын башын табак белян китереб, кызга биргянняр, ул аны анасына итеб биргян.

12 Іоаннын ӧйрянеўчеляре килеб, анын тянен алыб кюмгяч, Іисуска барыб белдергянняр.

13 Іисусъ мыны эшеткяч, аннан жангызы гна кайыкка утырыб, буш кырга кичкян; калык Ул киткянне эшетеб, калалардан чыгыб, Анын артыннан жяяўляб барган.

Зач. 58.

14 (Кайыктан) чыккач, Іисусъ кюб калыкны кюргян; Ул аларны кызганыб, аларнын чирлелярен тӧзяткян.

15 Кич булгач, ӧйрянеўчеляре Аңар килеб айткянняр: мында буш кыр, казер инде кич була; Син калыкны жибяр, алар ауылларга барыб, ўзляреня ашамнык алсыннар, дигянняр.

16 Äммя Іисусъ аларга айткян: алар китмясенняр, аларга ашарга сез бирегез, дигян.

17 Алар Аңар айткянняр: безнен мында биш икмяк белян ике балык кна, дигянняр.

18 Ул айткян: аларны Минга мында китерегез, дигян.

19 Аннары калыкка ўлям ӧстӧня утырырга кушкан. Биш икмяк белян ике балыкны алыб, кюккя таба караб бахиллягян, аннары икмяклярне сындырыб ӧйрянеўчеляреня биргян, ӧйрянеўчеляре калыкка (ӧляшкянняр).

20 Барысы да ашаб туйганнар; калган сыныкларны ун ике карнаша тулук жыйганнар.

21 Ашаучылар катын-кыздан, балалардан башкасы биш мең кешеляб булганнар.

Зач.59.

22 Шул сяттюк Іисусъ, калыкны жибяреб бетергенче, ӧйрянеўчеляреня кимягя утырыб, Ўзеннян алдан икенче жакка чыгыб китяргя кушкан.

23 Калыкны жибяреб бетергяч, Ул аулакта теляк итяргя тау ӧстӧня менгян; кич тя Ул анда жангызы гна булган.

24 Жил карышы булганныктан, дингез уртасында кимяне тулкыннар бяря башлаган.

25 Тӧннӧн дюртенче бюлемендя Іисусъ ӧйрянеӱчеляре жанына дингез ӧстӧннян жяяӱляб барган.

26 Ӧйрянеӱчеляре Анын дингез ӧстӧннян жяяӱляб килгянен кюреб, жӧдяшеб айткянняр: бу кеше шяӱляседер диб, куркыуларыннан кычкыра башлаганнар.

27 Іисусъ шул сяттюк алар белян сӧйляшя башлаб, айткян: нык торогоз; бу Мин, курыкмагыз, дигян.

28 Петръ Аӈар жауаб биреб айткян: эй Ходай, Син булсаӈ, миӈа Ӱз катыӈа сыу ӧстӧннян жяяӱляб барырга бойорсана, дигян

29 Іисусъ айткян: кил, дигян; шул сяттюк Петръ кимядян чыгыб, Іисуска таба сыу ӧстӧннян жяяӱляб бара башлаган.

30 Тик кыуатлы жилне кюреб курыккан да, бата башлагач: эй Ходай, мине коткар диб кычкырган.

31 Шул сяттюк Іисусъ кулын сузыб, аны тотоб айткян: эй аз ышаныучы! син ник шиклянденӈ? дигян.

32 Алар кимягя кергяч, жил басылган.

33 Кимядягеляр Іисусъ жанына килеб, Аӈар башырыб айткянняр: чыннаб Син Алла Улы, дигянняр.

34 Аннары аннан кичеб, Геннисаретъ жиреня килгянняр.

Зач. 60.

35 Ул жирнен кешеляре Іисусны белеб, бар тиряляреня дя хабяр жибяргянняр; аннары Аӈар бар чирлелярне китергянняр.

36 Алар Аӈар кейеменен читеня гня тейенейек диб ӱтенгянняр; тейенгянняре сауыкканнар.

15-нче бюлем.

1 Шул чакта Іисусъ жанына Іерусалимдяге княгячеляр белян фарисейляр килеб айткянняр:

2 Синеӈ ӧйрянеӱчелярен ней ӧчӧн картлар кушканны тотмойлар, кулларын жыумыйчы икмяк ашыйлар? дигянняр.

3 Ул аларга жауаб биреб айткян: ней ӧчӧн сез дя картларыгыз кушканны кылар ӧчӧн, Алла бойорогоннан жазасыз?

4 Алла бойороб айткян ич: атаӈны, анаӈны санна, тагы: атасына, анасына жаман айтеӱче ӱтерелсен, дигян.

5 Ӓммя сез айтясез: кем атасына, жя анасына: мин сиӈа бирясене (Аллага) адарындым дигяч,

6 Ул атасын, жя анасын саннамаса да жарый, дейсез. Шулай итеб, сез картларыгыз кушканны кылыб, Алла бойорогон чиття калдырасыз.

7 Эй кюз алдында гна кылыныучылар! Исаія пагамбяр сезнен турда дӧрӧс айткян:

8 Бу кешеляр ауызлары белян Минга жакыннашалар, телляре белян Мине кадерлейляр; тик кюнгелляре Миннян жырак тора;

9 Кеше уйлаб чыгарган бойорокларга, кеше өйряткянгя өйрятеб, алар Мине пайдасыз санныйлар, дигян.

10 Аннары чакырыб, калыкка айткян: тыннагыз да ангнаб алыгыз!

11 Кешене ауызга кергян нястя шакшыландырмый, әммя ауыздан чыкканы кешене шакшыландыра, дигян.

Зач. 61.

12 Шул чакта Анын жанына өйрянеўчеляре килеб, Ангар айткянняр: бу сюзлярне эшеткяч, фарисейляр жөдягянне белясен ме? дигянняр.

13 Ул аларга жауаб биреб айткян: Минем кюктяге Атам утыртмаган әр-бер агач тамыры белян кубарылыр.

14 Аларга теймягез: алар сукырларны житякляб жөртөўче сукырлар; әгяр сукыр сукырны житякляб барса, икесе дя чокорга жыгылырлар, дигян.

15 Петръ Ангар жауаб биреб айткян: бу мясялне безгя ангнатчы, дигян.

16 Iсусъ айткян: әле сез дя ангнамыйсыз меней?

17 Әлля сез ауызга кергяне барысы да карынга төшкянне, аннары тышка чыкканны әле дя ангыша алмыйсыз?

18 Әммя ауыздан чыкканы кюнгелдян чыга; анысы кешене шакшыландыра.

19 Усал уйлар, кеше ўтереў, азгыннык итеў, уйнашлык, урлау, жалган таныклык итеў,курлау, (барысы да) кюнгелдян чыга шул.

20 Шушылар кешене шакшыландыралар, әммя кул жыумыйчы ашау кешене шакшыландырмый, дигян.

Зач. 62.

21 Аннан чыккач, Iсусъ Тиръ белян Сидонъ жагына киткян.

22 Шунда бер Хананея катыны шул жирдян чыгыб, Ангар: эй Давидъ Улы Ходай! мине жарлыка, минем кызым женнянеб каты азаблана диб кычкырган.

23 Iсусь ангар бер сюз дя айтмягян. Өйрянеўчеляре Анын жанына килеб, Ангар ўтенгянняр: аны жибяр, ул безнен арттан кычкырыб киля, дигянняр.

24 Әммя Ул аларга жауаб биреб айткян: Мин Израиль жортонын жугалган сарыкларына гна жибяреллем, дигян.

25 Катын килеб, Ангар башырыб айткян: эй Ходай! минга булыша кюр, дигян.

26 Ул жауаб биреб айткян: икмякне балалардан алыб, этляргя ташлауы жакшы тӧгӧл, дигян.

27 Катын айткян: анысы дӧрӧс, эй Ходай, алайда этляр дя эяляренен ӧстяленнян тӧшкян ыуалчыкларны ашыйлар ич, дигян.

28 Шуннан суң Іисусъ аңар жауаб биреб айткян: эй катын! синең ышаныуың бик зур, сиңа телягяненчя булсын, дигян. Шул сяттюк анын кызы сауыккан.

Зач. 63.

29 Шуннан китеб, Іисусъ Галилея дингезе жанына барыб, тау ӧстӧня менеб утырган.

30 Шунда Анын жанына кюб калык килгян; алар ӱзляре белян бергя аксакларны, сукырларны, телсезлярне, гареблярне, тагы бютян тӧрлӧ кюб (чирлелярне) алыб килеб, аларны Іисусъ аягы жанына салганнар; Ул аларны тӧзяткян.

31 Телсезлярнен сӧйляшеӱен, гареблярнен тӧзялгянен, сукырларнын кюреӱен, аксакларнын жӧрӧӱен кюреб, калык исе киткян, Израиль Алласын даннаган.

Зач. 64.

32 Іисусъ ӧйрянеӱчелярен чакырыб алыб, аларга айткян: Мин бу калыкны кызганамын, алар Минем катымда инде ӧч кӧннян бирле торалар, ашар нястяляре дя жук; äммя аларны, жулда халляре бетмясен диб, ач кӧйӧ жибярясем килмей, дигян.

33 Ӧйрянеӱчеляре Аңар айткянняр: бу катле калыкны туйдырырлык икмяк буш кырда без каян алыйык? дигянняр.

34 Іисусь аларга айткян: сезнен ничя икмягегез бар? дигян. Алар: жидяӱ, тагы бер-аз ыуак балык бар, дигянняр.

35 Аннары Іисусъ калыкка жиргя утырырга кушкан.

36 Ӱзе жиде икмяк белян балыкларны алыб, (Аллага) тау иткян дя, сындырыб ӧйрянеӱчеляреня биргян, ӧйрянеӱчеляре калыкка (ӧляшкянняр).

37 Барысы да ашаб туйганнар, калган сыныкларны жиде карнаша тулук жыйганнар.

38 Ашаучылары катын-кызлар белян балалардан башкасы дюрт мең кеше булган.

39 Аннары калыкны жибяргяч, (Іисусъ) кимягя кереб утырган да, Магдала тиряляреня барган.

16-нчы бюлем.

Зач. 65.

1 Фарисейляр белян саддукейляр Іисусъ жанына килеб, Аны сынаб, безгя кюктян билге кюрсятче, дигянняр.

2 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: кичтян сез, кюк кызарыб торганга кюря, иртягя аяз булыр, дейсез,

3 Иртя белян: кюк кызгылт-карангы булыб торганны кюреб, бӧгӧн жангыр жауар, дейсез. Эй кюз алдында гна кылыныучылар! сез кюкнен тӧсӧн айыра белясез, ӓммя багыт билгелярен аӈыша алмыйсыз меней?

4 Усал, азгын тыума билге эзлей, тик аӈар Іона пагамбяр билгесеннян бютян билге бирелмяс, дигян. Аннары аларны калдырыб, аннан киткян.

5 Ӧйрянеӱчеляре ары жакка кичеб чыкканда икмяк алырга онотканнар.

Зач. 66.

6 Іисусъ аларга айткян: карагыз, фарисейляр белян саддукейляр ӓчеткеченнян сакланыгыз, дигян.

7 Алар ӱз кюӈеллярендя уйлаганнар: без икмяк алмаганны айтеӱедер диб.

8 Іисусъ мыны белеб, аларга айткян: эй аз ышаныучылар, ник сез икмяк алмадык диб ӱз кюӈелегездя уйлыйсыз?

9 Ӓле дя аӈнамыйсыз меней, биш икмяк биш меӈ (кешегя) житкянне, аннары ӱзегез ничя карнаша жыйыб алганыгыз исегездя тӧгӧл меней?

10 Тагы жиде икмяк дюрт меӈ (кешегя) житкянне, аннары ничя карнаша жыйыб алганыгызны (оноттогоз меней)?

11 Мин сезгя: фарисейляр белян саддукейляр ӓчеткеченнян сакланыгыз диб, икмяк турысында айтмягянемне сез ничек аӈнамыйсыз? дигян.

12 Шунда алар Анын икмяк ӓчеткеченнян сакланырга айтмягянен, ӓммя фарисейляр белян саддукейляр ӧйряткяннян (сакланырга кушканын) аӈнаганнар.

Зач. 67.

13 Іисусь Филиппъ Кесаріясе тирясеня баргач, ӧйрянеӱчеляреннян сораган: Мин Ӓдям Улын кешеляр кем диб айтяляр? дигян.

14 Алар айткянняр: кайсылары чумылдырыучы Іоаннъ дейляр, кайсылары Илія дейляр, ӓммя кайсылары Іеремія дейляр, жя пагамбярлярнен берседер диб айтяляр, дигянняр.

15 Ул аларга айткян: сез ӱзегез Мине кем диб белясез? дигян.

16 Петръ (дигян) Симонъ жауаб биреб айткян: Син Христосъ, Син тере Алланын Улы, дигян.

17 Аннары Іисусъ аӈар жауаб биреб айткян: эй Іона улы Симонъ, син бахетле; синӈа мыны тян белян кан белдермяделяр, ӓммя Минем кюктяге Атам белдерде шул, дигян.

18 Мин дя синга айтямен: син Петръ, Мин шушы таш өстөня жыйынымны корормын, аны тамук кабкасы да жингя алмас.

19 Синга кюк падшалыгынын ачкычларын бирем: син жирдя нейне бяйлясяң, ул кюктя дя бяйляўле булыр, әммя жирдя нейне чишсяң, ул кюктя дя чишеўле булыр, дигян.

Зач. 68.

20 Шул чакта Іисусъ өйрянеўчеляреня Ўзенен Іисусъ Христосъ икянен беряўгя дя айтергя кушмаган.

21 Шул багыттан Іисусъ Ўзенен Іерусалимгя барыб, анда калык башлыкларыннан, архіерейлярдян, княгячелярдян кюб азабланасын, ўтерелясен, өчөнчө көнөндя терелеб торасын өйрянеўчеляреня айырмачык айтя башлаган.

22 Петръ Аны читкяряк алыб китеб, кире кагыб Аңар айтя башлаган: Ходай сакласын, Синга бу эш булмасын, дигян.

23 Әммя Ул боролоб Петрга айткян: кит Миннян шайтан, син Мине алдандырасын: син шу Аллага жараганны уйламыйсын, әммя кешегя жараганны (уйлыйсын), дигян.

Зач. 69.

24 Шуннан суң Іисусъ өйрянеўчеляреня айткян: Минем артымнан барасы килгян кеше, ўз иркен кылыуны ташласын да, качын алыб, Минем артымнан барсын.

25 Жанын сакласы килгян кеше, аны жуяр шул, әммя жанын Минем өчөн жуйган кеше, аны табар.

26 Кеше бөтөн дөньяне жыйыб алса да, әммя ўз жанына зыян китерся, аңар ней пайда булыр? Жя кеше ўз жанын ней биреб жола алыр?

27 Әдям Улы Ўз Атасынын ололыгында пяриштяляре белян бергя килер, килгяч әр-кемгя эшляреня караб кайтарыр.

28 Чыннаб айтямен сезгя: мында тороучыларнын кайсылары, Ўз падщалыгында килеўче Әдям Улын кюрмейче ўлмясляр, дигян.

17-нче бюлем.

Зач. 70.

1 Аннары алты көн ўткяч, Іисусъ Петрны, Іаковны, анын энесе Іоанны алыб китеб, аларны гна алыб бейек тау өстөня менгян.

2 Ул анда алар алдында ўзгяргян: жөзө кояш кюк жактырган, кейемняре жакты кюк агарган.

3 Шунда аларга Моисей белян Илія кюренеб, Іисусъ белян сөйляшеб торганнар.

4 Шул чакта Петръ Іисуска айткян: эй Ходай! безгя мында торорга жакшы; телясяҥ, без мында öч чатыр корор ыйык: берсен Сиҥа, берсен Моисейгя, берсен Иліягя, дигян.

5 Ул айткян чагындук, кинят аларны жакты болот каблаган, шундук болоттан: Шушы Минем сöйöклö Улым, Анда Минем ризалыгым, Аны тыҥнагыз диб ауаз булган.

6 Öйрянеўчеляре мыны эшетеб, жöз тюбян жыгылыб киткянняр, алар бик курыкканнар шул.

7 Іисусъ жакын килеб, аларга тейенеб айткян: торогоз, курыкмагыз, дигян.

8 Алар кюзлярен кютяреб карагач, Іисустан бютянне беряўне дя кюрмягянняр.

9 Тау öстöннян тöшкян чакта, Іисусъ аларга кисятеб айткян: Äдям Улы ўлгян жиреннян терелеб торгончы, бу кюргянегезне беряўгя дя айтмягез, дигян.

Зач.71.

10 Шул чакта öйрянеўчеляре Аннан сораганнар: бу ничек книгячеляр элеке Илія килясе дейляр?

11 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: эйе, Илія элеке килеб, барын да рятляргя тейеш.

12 Äммя Мин сезгя айтямен: Илія инде килде, тик аны танымадылар, äммя аҥар ўзляре телягянчя кылдылар; Äдям Улы да шулай алардан азаб кюрер, дигян.

13 Шунда öйрянеўчеляре Ул аларга чумылдырыучы Іоаннъ турысында айткянне аҥнаганнар.

Зач. 72.

14 Алар калык катына килгяч, бер кеше Іисусъ жанына килеб, Аҥар тезлянеб башырыб,

15 Äйткян: эй Ходай! улымны жарлыка, ул шу жаҥа ай сайын женнянеб, каты азаблана; онгай жя утка, жя сыуга жыгыла.

16 Мин аны Синеҥ öйрянеўчеляреҥя китергян эйем, тик алар аны тöзятя алмадылар, дигян.

17 Іисусъ жауаб биреб айткян: эй ышаныусыз, азгын тыума! кайчанга чаклы сезнен белян торойом? кайчанга чаклы сезгя чыдыйым? аны мында Миҥа китерегез, дигян.

18 Китергяч Іисусъ аны тыйган; шундук жен анын эченнян чыккан, жегет шул сяттюк сауыккан.

19 Аннары öйрянеўчеляре Іисуска аулакта килеб айткянняр: без нейлектян аны чыгара алмадык? дигянняр.

20 Іисусъ аларга айткян: ышанмаганыгызга кюря, дигян; чыннаб айтямен сезгя: ӓгяр сезнен ышаныуыгыз горчица бӧртӧгӧ кюк кня булса да, сез шушы тауга: мыннан тегендя кюч дисягез, ул кючяр; сез булдыра алмаслык ич нястя дя булмас.

21 Бу (жен) заты тик теляк белян гня, ураза тотоу арткылы гна кыуыб чыгарыла дигян.

22 Алар Галилеядя чагында Іисусъ аларга айткян: Ӓдям Улы кешеляр кулына тотоб бирелер;

23 Аны ӱтererляр, Ул ӧчӧнчӧ кӧнӧндя терелеб торор, дигян. Шуннан суӈ алар бик кайгырганнар.

Зач. 73.

24 Алар Капернаумга килгяч, Петръ жанына дидрахма жыйыучылар килеб айткянняр: сезнен Ӧйрятеӱчегез дидрахма бирмяс ме? дигянняр.

25 Ул айткян: эйе, (бирер), дигян. Петръ ӧйгя кергяч, Іисусъ ул айткенче аӈар айткян: сиӈа ничек тея, Симонъ? жирдяге падшалар сатлык мал акчасын, жя имананы кемнян алалар: ӱз улларыннан мы? ӓлля жатлардан мы? дигян.

26 Петрь Аӈар айткян: жатлардан, дигян. Іисусъ аӈар айткян: айса ӱз уллары жарлыкаулы;

27 Алайда аларны жӧдяӱгя калдырмас ӧчӧн, син дингез жанына барыб кармак сал да иӈ элеке эляккян балыкны ал, анын ауызын ачкач, анда бер статиръ табарсын; аны алыб, Минем ӧчӧн дя, ӱзеӈ ӧчӧн дя аларга бир, дигян.

18-нче бюлем.

Зач. 74.

1 Шул чакта ӧйрянеӱчеляре Іисуска килеб айткянняр: кюк падшалыгында кем олорак? дигянняр.

2 Іисусъ бер баланы чакырыб алыб, аны аларнын уртасына торгозоб,

3 Айткян: чыннаб айтямен сезгя: ӓгяр сез ӱзегезне ӱзгяртеб, балалар кюк булмасагыз, кюктяге падшалыкка керя алмассыз.

4 Шулай, кем ӱзен ӱзе шушы бала кюк кечеляндерся, ул кюк падшалыгында олорак.

5 Тагы шушындый баланы Минем исемемя кабыл алыучы, Мине кабыл ала.

6 Ӓммя кем шушы Миӈа ышаныучы кечкенялярнен берсен алдандырса, ул кешегя муйнына тегермян ташы асыб, аны дингез тугайына батырсалар, жиӈелеряк булыр ыйы.

7 Алданыулар дӧньягя кыйын, алданыулар булырга тейеш шул, алайда алдандырыучы кешегя читен булыр.

8 Ӓгяр сине кулың, жя аягың алдандырса, син аларны ӱзеңнян кисеб ташла: ике кулың белян, ике аягың белян мянге утка ташланасы булгынчы, сыңар куллы, сыңар аяклы кӧйӧ терелеккя кереӱе сиңа жакшырак ич.

9 Ӓгяр сине кюзең кызыктырса, син аны ӱзеңнян сыуырыб алыб ташла: ике кюзең белян тамук утына ташланасы булгынчы, сыңар кюз белян терелеккя кереӱе сиңа жакшырак ич, дигян.

Зач. 75.

10 Карагыз, бу кечкенялярнен берсен дя ким кюрмягез; сезгя айтямен шул: аларнын пяриштяляре кюклярдя кюктяге Атамнын жӧзӧн жалан кюреб торалар диб.

11 Ӓдям Улы жугалганны эзляб табарга, аны сакларга килде щул.

12 Сезгя ничек тея? ӓгяр беряӱнен жӧз сарыгы булыб, аларнын берсе адашса, ул туксан тугызын таулар арасында калдырыб, адашканын эзлей бармас меней?

13 Ӓгяр дя аны табса, чыннаб айтямен сезгя: ул аңар адашмаган туксан тугыз сарыкларына сӧйӧнгяннян артыгырак сӧйӧнӧр.

14 Шулай, кюктяге Атагыз бу кечкенялярнен берсен дя жугалтасы килмей.

15 Ӓгяр туганың сиңа карышы жазыкланса, син ӱзең гня барыб, аны аулакта оялт; ӓгяр ул сине тыңнаса, туганыңны табыуың шул.

16 Ӓгяр ул сине тыңнамаса, син ӱзең белян бергя тагы бер кеше, жя ике кеше алыб бар; ике, жя ӧч таныкчынын айткяне белян ӓр-бер сюз беркелсен.

17 Ӓгяр аларны да тыңнамаса, жыйынга айт; ӓгяр жыйынны да тыңнамаса, ул аннары синең ӧчӧн жалган денне кеше кюк, мытарь кюк булсын, дигян.

Зач. 76.

18 Чыннаб айтямен сезгя: сез жир ӧстӧндя нейне бяйлясягез, ул кюктя дя бяйляӱле булыр; сез жир ӧстӧндя нейне чишсягез, ул кюктя дя чишеӱле булыр.

19 Тагы да чыннаб айтямен сезгя: ӓгяр жирдя сезнен арадан икяӱ бер киңяш белян бер-бер нястя сорасы булсалар, ней гня сорасалар да кюктяге Атамнан аларга бирелер.

20 Кайда булса да Минем исемемя икяӱ, жя ӧчяӱ бергя жыйылсалар, анда алар уртасында Мин шул, дигян.

21 Шул чакта Петръ Аңар жакын килеб айткян: эй Ходай! миңа карышы жазыклы булган туганыма ничя табкыр кичерейем? жидегя чаклы мы? дигян.

22 Іисусъ аңар айткян: жидегя чаклы димейем сиңа, ӓммя жиде табкыр житмешкя чаклы (кич), дигян.

Зач. 77.

23 Шунныктан кюк падшалыгы ӳз колларыннан исяб аласы булган падшага ошой.

24 Ул исябляшя башлагач, анын жанына аңар ун меҥ талантъ бирясе бар кешене китергянняр.

25 Анын тюляр нястясе булмагач, падша анын ӳзен дя, катынын да, балаларын да, тагы ней нястясе бар, барын да сатыб, тюляргя кушкан.

26 Шунда ул кол аңар жыгылыб башырыб айткян: эй падша! миңа тюзя кюрсяня, мин сиңа барын да тюлярем, дигян.

27 Падша ул колны кызганыб, аңар бурычын кичереб, аны жибяргян.

28 Бу кол (падша катыннан) чыккач, ӳзеня жӧз динарій бирясе бар бер иптяшен табкан; аны тоткан да: миңа бирясеҥне бир диб, аны быуа башлаган.

29 Шунда иптяше анын аягы астына жыгылыб, миңа тюзя кюрсяня, мин сиңа барын да бирем диб, аңар ӳтенгян.

30 Тик ул тыңнамаган, ӓммя барыб, бурычын тюляб бетергенче (тотарга) аны ӧтӧрмянгя жабтырган.

31 Иптяшляре бу эшне кюреб, мыңар бик рянжегянняр дя падшаларына барыб,ней булганны барысын да айткянняр.

32 Шуннан суҥ падшасы аны чакыртыб, аңар айткян: эй жаман кол! Син миңа жалынгач, мин сиңа бар бурычыңны кичердем;

33 Мин сине жарлыкаган кюк, сиңа да иптяшеҥне жарлыкарга тейеш эйе тӧгӧл ме? дигян.

34 Падшасы аңар ачыуы килеб, бурычын тюляб бетергенче тотарга аны азаблаучылар кулына биргян.

35 Сезнен дя ӓр-кайсыгыз ӳз туганына жангышларын чын кюҥелдян кичермяся, кюктяге Атам сезгя дя (шул падша) кюк кылар.

19-нчы бюлем.

1 Шушы сюзлярне айтеб бетергяч, Іисусъ Галилеядян чыгыб, Іорданнын ары жагы белян Іудея тиряляреня килгян.

2 Анын артыннан кюб калык барган, Ул аларнын (чирлелярен) тӧзяткян.

Зач. 78.

3 Анын жанына фарисейляр килеб, Аны сынаб, Аҥар айткянняр: äр-бер айыбы öчöн дя кешегя ӱз катынын айырырга мöҥким ме? дигянняр.

4 Ул аларга жауаб биреб айткян: Булдырыучы баштук аларны ирле катынны итеб булдырганны сез укымадыгыз меней?

5 Тагы айткян: шуҥар кюря кеше ӱз атасын, анасын калдырыр да катынына кушылыр, аннары икесе дя бер тян булырлар, дигян.

6 Шунныктан алар инде икяӱ тöгöл, äммя бер тян. Алай булгач, Алла кушылдырганны кеше айырмасын, дигян.

7 Алар Аҥар айткянняр: ник суҥ Моисей (катынга) айырыу жазыуын биреб, аны айырыб жибярергя бойорган? дигянняр.

8 Ул аларга айткян: кюҥелегез катыга кюря Моисей сезгя катыныгызны айырыб жибярергя ирек иткян; äммя башта алай тöгöл эйе.

9 Äммя Мин сезгя айтямен; кем ӱз катынын уйнашлык айыбы булмаган кöйö айырыб, бютян катын алса, ул уйнашлык итя; айырыб жибяргян катынны алыучы да уйнашлык итя, дигян.

10 Öйрянеӱчеляре Аҥар айткянняр: кеше ӱз катынына шулай булырга тейеш булгач, айса öйлянмей тороу жакшырак, дигянняр.

11 Ул аларга айткян: мыны барысы да сыйыштыра алмас, тик кемгя бирелгян, шул гна (сыйыштырыр).

12 Катынга жакыннашырга жараусыз тöрлö кешеляр бар: кайсылары ана эченнян шулай тыуганнар; кайсыларын кеше шулай иткян; кайсылары кюк падшалыгы öчöн ӱзлярен ӱзляре шулай иткянняр. (Бу сюзне) сыйдыра алырлыгы сыйдырсын, дигян.

13 Шул чакта Аҥар балаларны китергянняр, Ул алар öстöня кулын салыб, теляк итсен диб, äммя öйрянеӱчеляре аларны туктатыб торганнар.

14 Іисусъ аларга айткян: балаларны ирек жибярегез, аларга Миҥа килергя кумачау итмягез, кюк падшалыгы шундыйларныкы шул, дигян.

15 Ул аннары алар öстöня кулын салыб, аннан киткян.

Зач. 79.

16 Мына беряӱ килеб, Аҥар айткян: эй изге öйрятеӱче! мянге тормошны алыйым дисям, мин ней жакшылык кылыйым? дигян.

17 Ул аҥар айткян: ник син Мине изге диб айтясен? беряӱ дя изге тöгöл, тик бер Алла гна (изге). Мянге тормошка керясеҥ кился, бойорокларны кыл, дигян.

18 Ул Аҥар: ничеклярне? дигян. Іисусъ айткян: ӱтермя, уйнашлык итмя, урлама, жалган таныклык итмя;

19 Атаӈны, анаӈны санна, жакыныӈны ӳзеӈне сӧйгян кюк сӧй, дигян.

20 Бу жегет Аӈар айткян: мин быларнын барын да жяштянюк тоттом, тагы миӈа ней житмей? дигян.

21 Іисусъ аӈар айткян: ӓгяр бӧтӧнняй (арыулыкка) тулы буласын кился, кайтыб малыӈны сат та жарлыларга ӧляш, синеӈ малыӈ кюктя булыр, аннары килеб, Минем артымнан жӧр, дигян.

22 Мыны эшеткяч, жегет (Анын жанынннан) кайгырыб киткян: анын малы кюб икян.

23 Іисусъ ӧйрянеӳчеляреня айткян: чыннаб айтямен сезгя: бай кешегя кюк падшалыгына кереӳе читен, дигян.

24 Тагы да айтямен сезгя: бай кешегя кюк падшалыгына кереӳдян дӧягя иня кюзеннян ӳтеӳе асатрак, дигян.

25 Ӧйрянеӳчеляр мыны эшетеб, бик исляре китеб айткянняр: алай булгач, кем котола алыр суӈ? дигянняр.

26 Іисусъ аларга караб айткян: кешеляргя бу мӧӈким тӧгӧл, ӓммя Аллага бар да мӧӈким, дигян.

27 Шунда Петрь жауаб биреб, Аӈар айткян: мына без барысын да калдырыб, Сиӈа эярдек, суӈ инде безгя ней булыр? дигян.

28 Іисусъ аларга айткян: чыннаб айтямен сезгя: сез Миӈа эяргянняр, тагы-булыуда, Ӓдям Улы Ӳз ололыгынын престолына утыргач, сез дя ун ике престолга утырыб, Израилнен ун ике рыуына хокӧм итярсез.

29 Ӧйлярен, жя ага-энелярен, жя тута-сеӈнелярен, жя атасын, жя анасын, жя катынын, жя балаларын, жя жирен-сыуын Минем исемем ӧчӧн кем гня калдырса да жӧз табкыр артык алыр, мянге тормошка урыннашыр.

30 Алдагылар кюбесе артта булырлар, ӓммя арттагылар алда булырлар, дигян.

## 20-нче бюлем.

Зач. 80.

1 Кюк падшалыгы жорт эясе кешегя ошой: ул бик иртюк ӳзенен жӧзӧм бакчасында (эшляргя) эшчеляр жалларга чыккан.

2 Эшчеляр белян кӧнӧня бер динарійгя килешеб, аларны ӳзенен жӧзӧм бакчасына жибяргян.

3 Ӧчӧнчӧ сагаття чыгыб, урамда эшсез тороучыларны кюргян.

4 Ул аларга да айткян: сез дя минем жӧзӧм бакчама барыб эшлягез, мин сезгя теярен бирем, дигян; алар барганнар.

5 Тагы алтынчы сагаття дя, тугызынчы сагаття дя чыгыб, шулай кылган.

6 Калдыгында ун беренче сагаття чыгыб, ул тагы эшсез тороучы бютяннярне очратыб, аларга айткян: сез мында ник кӧн буйы эшсез торасыз? дигян.

7 Алар аӈар: безне беряӳ дя жалламады, дигянняр. Ул аларга айткян: сез дя минем жӧзӧм бакчама барыб эшлягез, ӳзегезгя теярен алырсыз, дигян.

8 Кич булгач, бакча эясе ӳз жортон караучыга айткян: эшчелярне чакырыб китер дя аларга эш акы бир, сунгыларыннан башлаб, элекегеляре белян бетер, дигян.

9 Ун беренче сагаття килгянняре беряр динарій алганнар.

10 Иӈ алдан килгянняре без артыгырак алырбыз диб уйлаганнар, тик алар да беряр гня динарій алганнар.

11 Алгач, жорт эясеня зарлана башлаб,

12 Айткянняр: бу сунгылар бер гня сагат эшляделяр, ӓммя син аларны без кӧн буйы кызыуга чыдаб эшлягянняр белян тиӈ иттеӈ, дигянняр.

13 Ул аларнын берсеня сюз кайтарыб айткян: эй дус! мин сине читлямейем, син минем белян бер динарійгя килештеӈ тӧгӧл ме?

14 Ӳзеӈнекен ал да кит; мин бу сунгыга да сиӈа биргян чаклы бирясем киля.

15 Ӓлля минем ӳз нястямя телягянемне кыларга иркем жук? Минем жакшылыгыма кюзеӈнен кӧнчӧлӧгӧ киля меней? дигян.

16 Шулай, арттагылар алда булырлар, алдагылар артта булырлар; чакырылганнар кюб, ӓммя сайланганнар аз шул, дигян.

Зач. 81.

17 Іисусъ Іерусалимгя менеб барган чакта, жулда ун ике ӧйрянеӳчесен аулакка алыб китеб, аларга айткян:

18 Мына без Іерусалимгя менеб барабыз, анда Ӓдям Улы архіерейляр, княгячеляр кулына тотоб бирелер, алар Аны ӳтерергя хокӧм итярляр;

19 Аны жалган деннелярге мыскылларга, кыйнарга, кадакларга тотоб бирерляр; Ул ӧчӧнчӧ кӧнӧндя терелеб торор, дигян.

20 Шул чакта Зеведей улларынын анасы ӳз уллары белян Іисусь жанына килеб, Аннан башырыб бер нястя сораган.

21 Іисусъ аӈар: син ней телейсен? дигян. Ул Аӈар айткян: минем ике улыма падшалыгыӈда берсеня уӈ жагыӈа, икенчесеня сул жагыӈа утырырга айтче, дигян.

22 Іисусъ сюз кайтарыб айткян: ней сораганыгызны ӳзегез белмейсез. Мин эчясе сауыттагын эчя алырсыз мы? Мин чумыла торган

чумылыу белян чумыла алырсыз мы? дигян. Алар Аӈар: алырбыз, дигянняр.

23 Аннары Ул аларга айткян: Минем сауытымдагын эчярсез, Мин чумыла торган чумылыу белян дя чумылырсыз, тик Ӱземнен уӈ жагыма, сул жагыма утыртыу Минем иркемдя тӧгӧл, ӓммя Атам кемгя ӓзерлягян, шул (утырыр), дигян.

24 Мыны эшетеб, унысы ике ага-энене ошатмаганнар.

25 Іисусъ аларны чакырыб алыб айткян: калык тюряляре калыкларга тюрялек иткянне, ололары аларны кул астларында тотканны сез белясез.

26 Сезнен арагызда алай булмасын, ӓммя сезнен арада кем олорак буласы кился, ул сезгя кызмятче булсын.

27 Кем сезнен арада баш буласы кился, ул сезгя кол булсын.

28 Шулай, Ӓдям Улы да Ӱзеня кызмят иттерер ӧчӧн килмяде, ӓммя Ӱзе кызмят итяр ӧчӧн, кюб (кешелярне) жолар ӧчӧн Ӱз жанын бирергя (килде), дигян.

Зач. 82.

29 Алар Іерихоннан чыккан чакта, Анын артыннан кюб калык барган.

30 Шунда жул буйында утырыучы ике сукыр кеше Іисусъ узыб барганны эшетеб, кычкырганнар: эй Давидъ Улы Ходай, безне жарлыка диб.

31 Калык аларга кычкырырга кушмаган, ӓммя алар: эй Давидъ Улы Ходай, безне жарлыка диб бигеряк тя нык кычкыра башлаганнар.

32 Іисусъ туктаб, аларны чакырыб алыб айткян: Мин сезгя ней кылсын диб телейсез? дигян.

33 Алар Аӈар: эй Ходай! кюзляребез ачылсын ыйы диб (телейбез), дигянняр.

34 Іисусъ аларны кызганыб, кюзляреня тейенгян; шул сяттюк аларнын кюзляре кюря башлаган; шуннан ары алар Аӈар эяреб киткянняр.

## 21-нче бюлем.

Зач. 83.

1 Іерусалимгя жакыннашарак, Елеонь тауына, Виѳсфагія атлы ауылга килеб житкяч, Іисусъ ике ӧйрянеӱчесен жибяреб,

2 Аларга айткян: шушы алдыгыздагы ауылга барыгыз, баргачтук анда бяйляб куйган ишякне колоны белян очратырсыз, чишеб (аларны) Миӈа алыб килегез.

3 Ӓгяр беряӱ сезгя бер-бер сюз айтся, алар Ходайга киряк дигез, ул шул сяттюк аларны биреб жибярер, дигян.

4 Бу барда пагамбяр арткылы айтелеў жиреня килер ӧчӧн булган, ул айткян:

5 Сионъ кызына айтегез: мына синеҥ падшаҥ, жигеля торган ишякнен колонона атланыб, синеҥ жанына жыуашлык белян киля диб.

6 Ӧйрянеўчеляр барыб, Іисусь кушканча кылганнар.

7 Ишякне колоны белян алыб килеб, алар ӧстӧня ўзляренен кейемнярен салганнар, Іисусъ кейемняр ӧстӧня атланган.

8 Кюб калык ўз кейемнярен жул ӧстӧня жяйеб барганнар, кайсылары агачлардан жапраклы чыбыклар кисеб алыб, жулга тюшяб барганнар.

9 Калыкнын алдан барыучылары да, арттан барыучылары да: Осанна Давидъ Улына! Ходай исеменя килеўче даннаулы, эй жугарыдагы Осанна! диб кычкырыб барганнар.

10 Ул Іерусалимгя кергяч, бӧтӧн кала кузгалган, бер берсеннян: Бу кем? диб сорашканнар.

11 Калык айткян: Бу Іисусъ, Галилеядяге Назареттан (чыккан) пагамбяр, дигянняр.

Зач.

12 Іисусъ Алла чиркяўеня кергяч, чиркяўдя сатыу итеўчелярне, алыучыларны барысында кыуыб чыгарган; акча алыштырыучыларнын ӧстяллярен, кюгярчен сатыучыларнын скямьялярен аударыб бетергян.

13 Аннары аларга айткян: жазылган ич: Минем ӧйӧм теляк ӧйӧ диб аталыр, ӓммя сез аны талаучылар оясы кюк иткянегез диб, дигян.

14 Шул чакта чиркяўдя Анын жанына сукырлар, аксаклар килгянняр. Ул аларны тӧзяткян.

15 Архіерейляр, князячеляр, Ул кылган кодрятлярне кюреб, тагы: Осанна Давидъ Улына! диб чиркяўдя кычкырыучы балаларны кюреб, ачыулары килеб,

16 Аҥар айткянняр: алар ней айткянне эшетясеҥ ме? дигянняр. Іисусъ аларга айткян: эйе, сез ӓлля: жяш балаларнын, имчяк имя торганнарнын ауызыннан Син Ўзеҥне мактаттыҥ, дигянне бер чактада укымадыгыз мы? дигян.

17 Аннары аларны калдырыб, каладан чыгыб, Виѳаніягя киткян, тӧннӧ шунда ўткяргян.

Зач. 84.

18 Иртя белян калага кайткан чакта ашасы килгян.

19 Жул буйында бер смоква агачын кюреб, анын жанына барган; анда жапракларыннан бютян нястя табмагач, аҥар айткян: синдя мыннан блай гумергя жимеш булмасын, дигян. Смоква агачы шундук короган.

20 Ӧйрянеӱчеляр мыны кюреб, исляре китеб айткянняр: бу смоква агачы ничек кинят короды? дигянняр.

21 Iисусъ аларга жауаб биреб айткян: чыннаб айтямен сезгя: ӓгяр сез шиклянмейче ышансагыз, смоква агачына кылганны гна кылмассыз, ӓммя шушы тауга: кютярелеб, дингезгя атыл дисягез, (ул да) булыр.

22 Телягегездя ышаныб ней гня сорасагыз да, барын да алырсыз, дигян.

Зач. 85.

23 Аннары чиркяӱгя килеб ӧйряткян чагында, Анын жанына архiерейляр, калык башлыклары килеб айткянняр: Син мыны кем бойороуы белян кыласын? мындый кыуатны Синҕа кем бирде? дигянняр.

24 Iисусъ аларга жауаб биреб айткян: Мин дя сездян бер сюз соройом, сез Минҕа шунҕар (жауаб) айтсягез, Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны айтермен.

25 Iоаннъ чумылдырырга (бойорок) кайдан алды? кюктян ме, ӓлля кешелярдян ме? дигян. Алар ӱз аралый уйлаганнар: ӓгяр кюктян дисяк, Ул безгя: ник сунҕ анҕар ышанмадыгыз, дирер.

26 Ӓгяр кешелярдян дисяк, калыктан куркабыз, Iоанны бар да пагамбяргя саныйлар шул диб.

27 Аннары жауаб биреб, Iисуска айткянняр: белмейбез, дигянняр. Ул да аларга айткян: Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны айтмям, дигян.

Зач. 86.

28 Сезгя ничек тея? Бер кешенен ике улы булган; ул элекесеня килеб айткян: улым! бар, бӧгӧн минем жӧзӧм бакчамда эшляче, дигян.

29 Улы жауаб биреб айткян: бармам, дигян; ӱкенеб, сунҕыннан барган.

30 Икенчесеня килеб, анҕар да шулай айткян; анысы жауаб биреб: эй ӓтей, барым, дигян, тик бармаган.

31 Икесенен кайсысы атасы кушканны кылган? дигян.Алар Анҕар: элекегесе, дигянняр. Iисусь аларга айткян: чыннаб айтямен сезгя: мытарлар, азгын торган катын-кызлар Алла падшалыгына сездян алдан керяляр.

32 Iоаннъ сезгя дӧрӧслӧк жулы белян килде, сез анҕар ышанмадыгыз, мытарлар, азгын торган катын-кызлар анҕар ышандылар, ӓммя сез мыны кюргячтя тяӱбягя килмядегез, анҕар ышанмадыгыз шул, дигян.

Зач. 87.

33 Икенче мясял тынгнаб алыгыз: бер жорт эясе булган; ул жөзөм агачлары утыртыб, äйлянясен койма белян äйляндергян; эчендя (жөзөм сыуын) агызгыч жасаган, башня торгозган, аннары бакчаны бакчачыларга табшырыб, киткян.

34 Жимешен жыяр багыт житкяч, ул ӱз кызмятчелярен бакчачылардан жимешен алырга жибяргян.

35 Бакчачылар анын кызмятчеляреня жабышыб, кайсын кыйнаганнар, кайсын ӱтергянняр, кайсысын таш белян атыб ӱтергянняр.

36 Ул тагы элекегелярдян дя кюберяк ӱнгя кызмятчеляр жибяргян; аларга да шулай кылганнар.

37 Улымнан оялырлар диб, калдыгында ул аларга ӱз улын жибяргян.

38 Äммя бакчачылар анын улын кюреб, бер берсеня äйткянняр: бу атасы урнына каласы, äйдягез ӱтерейек аны, аннары аңар каласы малны ӱзебезгя алырбыз, дигянняр.

39 Аны тотканнар да бакчадан чыгарыб ӱтергянняр.

40 Бакчанын эясе килгяч, бу бакчачыларга инде ней кылар? дигян.

41 Алар Аңар äйткянняр: бу усалларны азаблаб харяб итяр, бакчасын багытында аңар жимешен бирерлек бютян бакчачыларга табшырыр, дигянняр.

42 Іисусъ аларга äйткян: сез äлля: öй салыучылар жараусыз кюреб ташлаган таш почмак астына нигез булган, Ходайдан булган бу, безнен кюз алдыбызда ис китярлек дигянне жазыуда бер чакта да укымадыгыз мы? дигян.

Зач. 88.

43 Шунныктан сезгя äйтямен: Алла падшалыгы сездян алыныр да жимешен китерерлек калыкка бирелер.

44 Бу таш öстöня жыгылган кеше уатылыр, äммя кем öстöня бу таш тöшся, аны сытар, дигян.

45 Архіерейляр белян фарисейляр Анын мясялляреn эшеткяч, Ул алар турысында äйткянне аңнаганнар.

46 Аннары алар Аны тотоб алмакчы булганнар, тик калык Аны пагамбяргя санаганга кюря, калыктан курыкканнар.

## 22-нче бюлем.

Зач. 89.

1 Іисусъ тагы мясялляр китереб, аларга äйткян:

2 Кюк падшалыгы улын öйляндергяндя туй жасаган падша кешегя ошой:

3 Туйга öндялгяннярне чакырырга ул ӱзенен колларын жибяргян; öндялгяннярнен киляселяре килмягян.

4 Ул аннары жаңадан бютян колларын былай айтеб жибяргян: чакырылганнарга: мына инде ашым äзер, симерткян бызауларымны, тагы бютян тöрлö жяннекляремне дя суйдырдым, барда äзер инде, туйга барыгыз диб айтегез, дигян.

5 Äммя чакырылганнар саннамыйчы кайсысы басыуына, кайсысы сатыуына киткян;

6 Кайсылары анын колларын тотоб, аларны кадерсез итеб ӱтергянняр дя.

7 Падшанын мыны эшеткяч, ачыуы килгян; ӱз командасын жибяреб, шул ӱтереӱчелярнен ӱзлярен ӱтерттергян, калаларын да жандырткан.

8 Аннары ӱз колларына äйткян: туй ашы инде äзер, тик чакырылганнар тейешле булмадылар.

9 Сез инде жул чатларына барыгыз, анда кемне гня очратсагыз да, барысын да туйга чакырыгыз, дигян.

10 Ул коллар жулларга чыгыб, туры килгянне барысын да: жакшыларын да, жаманнарын да жыйганнар; туй (öйö) кунаклар белян тулган.

11 Падша кунакларны кюрергя кергяч, анда туй кейемен киймягян кешене кюреб,

12 Аңар äйткян: эй дус! син мында туй кейемен киймягян кöйö ничек керясе иттең? дигян; ул дяшмягян.

13 Шунда падша ӱз колларына äйткян: мынын кулларын, аякларын бяйлягез дя, алыб аны тыштагы карангылыкка чыгарыб ташлагыз; анда жылау, теш шыкырдатыу булыр, дигян.

14 Чакырылганнар кюб, äммя сайланганнар аз шул, дигян.

Зач. 90.

15 Шул чакта фарисейляр китеб, ничек булса да Іисусны сюзеннян эляктерейек диб киңяш иткянняр дя,

16 Анын жанына ӱз öйрянеӱчеляре белян иродныкыларны былай диб äйтергя жибяргянняр: эй Öйрятеӱче! без Синең туры кеше икяненне белябез, Син Алла жулына дöрöс öйрятясен, беряӱгя дя (жумалаб) жараулы булыйым диб, кешесеня караб (кылмыйсын) шул.

17 Äйтче безгя, Сиңа ничек тея? Кесаргя имана бирергя тейеш ме, äлля жук мы? дигянняр.

18 Іисусъ аларнын жаман уйларын белеб äйткян: эй жумачылар! ник сез Мине сыныйсыз?

19 Иманага биря торган тянкяне Миңа кюрсятегез äле, дигян. Алар Аңар динарій китереб биргянняр.

20 Ул аларга äйткян: мында кем тöсö, кем исеме жазылган? дигян.

21 Алар Аңар: Кесарнеке, дигянняр. Шунда Ул аларга äйткян: алай булгач, Кесарнекен Кесаргя, äммя Алланыкын Аллага бирегез, дигян.

22 Мыны эшеткяч, алар исляре китеб, Анын жаныннан киткянняр.

Зач. 91.

23 Шул кöннö Анын жанына терелеб тороу булмас диб äйтеўче саддукейляр килеб, Аннан сораганнар:

24 Эй Öйрятеўче! Моисей äйткян: äгяр кем балалары булмый ўлся, анын катынын энесе алыб, агасына нясел булдырсын, дигян.

25 Мына безнен жиде ага-эне бар ыйы; элекегесе öйлянгяч ўлде, балалары калмады, анын катынын энесе алды.

26 Шулай икенчесе дя, öчöнчöсö дя, жидесе дя (аны алыб öйлянделяр дя ўлделяр).

27 Барысыннан суң катын да ўлде.

28 Терелеб торгач, ул жидесенен кайсына катын булыр суң? ул аларнын барысынында катыны булган ыйы, дигянняр.

29 Іисусь аларга жауаб биреб äйткян: Алла жазыуын, Алла кыуатын белмягяннектян жангышасыз сез.

30 Терелеб торгач, öйлянмейляр дя, кеяўгя дя китмейляр, äммя кюктя Алла пяриштяляре торган кюк торалар.

31 Äммя ўлгянняр терелеўе турысында сезгя Алла äйткянне:

32 Мин Авраамъ Алласы, Исаакъ Алласы, Іаковъ Алласы, дигянне сез укымадыгыз меней? Алла ўлгянняр Алласы тöгöл, äммя тереляр Алласы, дигян.

33 Калык мыны эшеткяч, Анын öйряткяненя исляре киткян.

Зач. 92.

34 Іисусъ саддукейлярне курлыкка калдырганны эшеткяч, фарисейляр бергя жыйылганнар.

35 Шунда аларнын берсе, законга öйрятеўчесе Аны сынаб сораган:

36 Эй Öйрятеўче, законда иң оло бойорок кайсы? дигян.

37 Іисусъ аңар äйткян: Алла Ходайыңны бар кюңелең белян, бар жаның белян, бар уйың белян сöй.

38 Шушы баш бойорок, иң оло бойорок.

39 Икенчесе дя шуңар ошаулы: жакыныңны ўзеңне сöйгян кюк сöй.

40 Бöтöн законнын да, пагамбярлярнен дя öйряткяне шушы ике бойорокта тора, дигян.

41 Фарисейляр жыйылгач, Іисусъ алардан сораган:

42 Христосъ турысында сез ней уйлыйсыз? Ул кем Улы? дигян. Алар Аҥар: Давидь улы, дигянняр.

43 Ул аларга йиткян: ничек суҥ Давидъ Тын тойдорган буйынча Аны Ходай дей? ул йитя:

44 Ходай минем Ходайыма йиткян: Мин дошманнарыҥны аягыҥ астына салгынчы, Минем уҥ жагымда утыр, дей.

45 Давидъ Аны Ходай диб йиткяч, Ул ничек суҥ анын улы була? дигян.

46 Аҥар карышы беряӱ дя, бер сюз дя йитя алмаган; шул кённян суҥ Аннан ич кем (сынаб) сорарга кыймаган.

23-нчӧ бюлем.

Зач. 93.

1 Шул чакта Іисусъ калыкка да, ӧйрянеӱчеляреня дя былай диб йитя башлаган:

2 Моисей урнына князячеляр белян фарисейляр утырганнар.

3 Алар сезгя кыларга кушканны барын да тотогоз да, кылыгыз да, тик алар кылынганча кылынмагыз: алар ӱзляре йиткянне ӱзляре кылмыйлар шул.

4 Алар, кютяреб жӧрӧй алмаслык, ауыр кютярям бяйляб, кешеляр жилкясеня салалар, ӓммя ӱзляре аны бармаклары белян дя кузгатасылары килмей.

5 Алар бар эшлярен кешеляр кюрсенняр диб кня кылалар; (мангайларына, кулларына) бяйляӱечляр киҥ итеб бяйлейляр, кейем кырыйларына зур чуклар тагалар.

6 Тагы ашка жыйылган жирдя тюргя утырыуны, синагогаларда алда утырыуны сӧяляр.

7 Урамнарда кеше башырганны, ӱзлярен: ӧйрятеӱче, ӧйрятеӱче диб кублаганны жарataлар.

8 Ӓммя сез ӱзегезне ӧйрятеӱче дигянне телямягез: сезнен Ӧйрятеӱчегез бер Христосъ кна шул, ӓммя сез барыгыз да бер туганнар кюк.

9 Жир ӧстӧндя беряӱне дя ата диб йитмягез: сезнен Атагыз беряӱ гня шул, Ул кюктя.

10 Ӱзегезне ӱгетляӱче дигянне дя телямягез: сезнен Ӱгетляӱчегез бер Христосъ кна шул.

11 Сезнен арада ологоз,сезгя кызмятче булсын.

12 Кем ӱзен ӱзе кютярся, ул кечегя калыр, ӓммя кем ӱзен ӱзе кечеляндерся, ул ололаныр, дигян.

Зач. 94.

13 Айгай сезгя князячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез кешеляргя кюк падшалыгын жабыб торасыз: ўзегез дя кермейсез, керясе килгяннярне дя кертмейсез.

14 Айгай сезгя князячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез тол катыннарнын жортларын ашаб бетерясез шул; кюренер ӧчӧн гня озаклаб теляк итясез: шунын ӧчӧн сез артыгырак айыбланырсыз.

15 Айгай сезгя князячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез беряўне-беряўне ўз денегезгя ауыштырыр ӧчӧн, дингезлярне, коро жирне жӧрӧб бетерясез; ауыштыргач, аны ўзегездян ике ӧлӧш жаманырак тамук улы итясез.

16 Айгай сезгя сукыр жӧртӧўчеляр! сез ӓйтясез: кем чиркяўне алыб ант ится, кылмаса да жарый, ӓммя кем чиркяў алтынын алыб ант ится, кыларга тейеш, дейсез.

17 Эй акылсызлар, сукырлар! ней олорак: алтын мы, ӓлля алтынны арыуландыра торган чиркяў ме?

18 Тагы (ӓйтясез): кем корман урны белян ант ится, кылмаса да жарый, ӓммя кем анын ӧстӧндяге корман белян ант ится, кыларга тейеш дейсез.

19 Эй акылсызлар, сукырлар! ней олорак: корман мы, ӓлля корманны арыуландыра торган урын мы?

20 Корман урны белян ант итеўче, урны белян дя, анын ӧстӧндя ней бар, барысы белян дя ант итя.

21 Чиркяў белян ант итеўче, анын ўзе белян дя, эчендя Тороучы белян дя ант итя.

22 Кюк белян ант итеўче, Алла престолы белян дя, анын ӧстӧндя Утырыучы белян дя ант итя.

Зач. 95.

23 Айгай сезгя, князячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез бӧтнӧктян, анистан, тминнан унынчы ӧлӧшӧн бирясез, ӓммя закондагынын иӈ ололарын: турылыкны, изгелекне, ышаныуны калдырганыгыз; быларны да кыларга киряк, тегелярен дя калдырырга кирякмяс.

24 Эй сукыр жӧртӧўчеляр! сез черкейне сӧзясез, ӓммя дӧяне жотасыз.

25 Айгай сезгя, князячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез табак-сауытларыгызнын тышларын тазартасыз, ӓммя эчляре талаб алган нястя белян, дӧрӧссӧзлӧк белян тулы.

26 Эй сукыр фарисей! элеке табак-сауытыӈнын эчен тазарт, аннары аларнын тышы да таза булыр.

27 Айгай сезгя, княгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез тышларын буяган гробларга ошаулы: алар тышларыннан матур кюреняляр, äммя эчляре ӱлек сӧяге белян, äр-тӧрлӧ шакшылык белян тулы.

28 Шулай сез дя тышыгыздан кешеляргя гадел кюк кюренясез, äммя эчегез жумалау белян, законсызлык белян тулы, дигян.

Зач. 96.

29 Айгай сезгя, княгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез пагамбярляргя каберляр торгозасыз, гаделлярнен памятникларын матурлыйсыз.

30 Сез äйтясез: äгяр без аталарыбыз кӧннярендя торган булсак, пагамбярлярнен каннарын тюгяргя аларга катышмаган булыр ыйык, дейсез.

31 Шулай итеб ӱзегезне ӱзегез пагамбярлярне ӱтереӱчелярнен уллары икянегезне кюрсятясез.

32 Сез дя инде аталарыгызнын ӱлчяӱен тутырыгыз.

33 Эй жыланнар, эй ехидна тыумалары! сезне тамукка тӧшӧртясе хокӧмнян ничек качарсыз?

34 Мына Мин сезгя пагамбярлярне, белемне кешелярне, укымышларны жибярям; сез аларнын кайсыларын ӱтерерсез, качка кадакларсыз, äммя кайсыларын синагогаларыгызда кыйнарсыз, каладан калага кыуарсыз.

35 Жир ӧстӧндя гаделлярнен (айыбсыз) тюгелгян каны, гадел Авель каныннан башлаб, корман урны белян келяӱ ӧйӧ арасында сез ӱтергян Варахiя улы Захарiянын канына чаклы, барысыда сезгя тӧшсӧн.

36 Чыннаб äйтямен сезгя: бу барда шушы тыумага килер.

37 Эй пагамбярлярне ӱтереб бетереӱче, сиңа жибярелгяннярне таш белян атыб ӱтереӱче Iерусалимъ, Iерусалимъ! тауык ӱз чебешлярен канаты астына жыйган кюк, Мин синең балаларыңны ничя табкыр Ӱз катыма жыясым килгян эйе, äммя сез телямядегез.

38 Мына инде бу жортогоз сезгя буш кала.

39 Сезгя äйтямен: Ходай исеменя Килеӱче даннаулы диб äйткенче, сез Мине мыннан былай кюрмяссез, дигян.

24-нче бюлем.

Зач. 97.

1 Iисусъ чиркяӱдян чыгыб, китеб барганда, ӧйрянеӱчеляре Аңар чиркяӱ каралдыларын кюрсятмякче булыб,

2 Анын жанына килгянняр. Iисусъ аларга äйткян: быларнын барысында кюрясез ме? чыннаб äйтямен сезгя: мында таш ӧстӧндя таш та калмас, барысында жимереб бетерерляр, дигян.

Зач. 98.

3 Ул Елеонъ тауы öстöндя утырганда, öйрянеўчеляре Анын жанына килеб, аулакта сораганнар: äйтче безгя, ул кайчан булыр, тагы килеўеңнен, дöнья бетеўенен билгесе ничек булыр? дигянняр.

4 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: сак булыгыз, беряў-беряў сезне жангыштырмасын.

5 Кюбесе Минем исемем белян, мин Христосъ диб килерляр шул, кюбесен жангыштырырлар да.

6 Тагы сугышлар булганны, сугыш хабярлярен эшетерсез; карагыз, курыкмагыз, былар барысыда булырга тейеш шул, алайда ул äле бетеў тöгöл.

7 Калык калыкка, падшалык падшалыкка жабышыр, ачлыклар, ўлятляр булырлар, урны урны белян жир титряр.

8 Былар барысыда азабларнын башланыуы гна.

9 Шул чакта сезне тотоб азабка бирерляр, сезне ўтерерляр, Минем исемем öчöн сезне бар калыклар да кюрялмаслар.

10 Шул чагында кюбесе алданырлар, бер берсен тотоб бирерлер, бер берсен кюрялмаслар.

11 Кюб жалган пагамбярляр чыгарлар, кюбесен жангыштырырлар.

12 Законсызланыу кюбяйгяннектян кюбесендя сöйöўлек бетяр, дигян.

Зач. 99.

13 Калдыкка чаклы тюзгяне котолор.

14 Алла падшалыгынын шушы Евангеліесе бар калыкларгада таныклыкка, бöтöн дöньягя жяйелер, шуннан суң бетеў булыр.

15 Даніилъ пагамбяр äйткянчя, арыу урында жирянгеч нястяляр торганны кюрерсез; укыган кеше аңнасын.

16 Шул чакта Іудеядягеляр тауларга качсыннар.

17 Öй тюбясендя булганы, öйöмнян бер-бер нястя алыб китейем диб, тöшмясен.

18 Басыуда булганы, кейемняремне алыб китейем диб, кире кайтмасын.

19 Ул кöннярдя ауырлы катыннарга, имчяк имезеўчеляргя читен булыр.

20 Качарыгызга кыш, жя суббота кöн туры килмясен эйе диб телягез.

21 Ул чакта бик зур кайгы булыр, анын кюк кайгы дöнья булдырылганнан башлаб, äлегя чаклы да булганы жук, булмас та.

22 Äгяр шул кöнняр кыскармасалар, бер тян дя котолмас ыйы, тик сайланганнар какына ул кöнняр кыскарыр.

23 Шул чакта беряӳ сезгя: мына мында Христосъ, жя ана тегендя дейся, ышанмагыз.

24 Жалган христослар, жалган пагамбярляр чыгарлар; мӧнким булса сайланганнарны да жангыштырыр ӧчӧн, зур кодрятляр, билгеляр кюрсяткян булырлар.

25 Мына Мин сезгя алданук äйттем.

26 Шулай, сезгя: мына Ул буш кырда дейсяляр, чыкмагыз; мына Ул аулак бюлмялярдя дейсяляр, ышанмагыз, дигян.

Зач. 100.

27 Жяшен ничек кояш чыгышыннан чыгыб, кояш байышына чаклы жяшняб кюреня, Äдям Улынын килеӳе дя шулай булыр.

28 Ӱлякся жаткан тӧшкя бӧркӧтляр жыйылыр.

29 Шул кайгылы кӧннярдян суӊ, кинят кояш карангыланыр, ай ӳз жактысын жактыртмас, жондозлар кюктян койолорлар; кюктяге чиреӳляр кузгалышырлар.

30 Шул чагында кюктя Äдям Улынын билгесе кюренер, аннары жирдяге няселляр барысыда жылаша башларлар; кюк болотлары ӧстӧндя кодрят белян, оло дан белян килеӳче Äдям Улын кюрерляр.

31 Ул Ӳз пяриштялярен зур тауышлы быргылар белян жибярер; алар дӧньянен дюрт жагыннан, кюкнен бер кырыйыннан башлаб, икенче кырыйына чаклы Анын сайлаганнарын жыярлар.

32 Смоква агачыннан ошаш алыгыз: анын ботаклары жомошаб, жапрак жара башлагач, жяй жакын икянне белясез.

33 Шунын кюк быларнын барысында кюргяч, инде жакын, ишек тӧбӧндя диб белегез.

Зач. 101.

34 Чыннаб äйтямен сезгя: шушы тыума беткенче былар барысыда булыр.

35 Кюк белян жир бетярляр, äммя Минем сюзлярем торор.

Зач. 102.

36 Ул кӧннӧ, ул сагатне беряӳ дя белмей, кюктяге пяриштяляр дя (белмейляр), тик бер Атам гна беля.

37 Ной кӧннярендя ничек булган, Äдям Улы килгян чагында да шулай булыр:

38 Жирне сыу басар кӧнняр алдыннан Ной кимягя керер кӧнгя чаклы, кешеляр ашаганнар, эчкянняр, ӧйлянгянняр, кеяӳгя киткянняр;

39 Сыу килеб барысын да басыб бетергенче, бер дя белмягянняр, Äдям Улы килгян чагында да шулай булыр.

40 Шул чакта икяӳ басыуда булсалар, берсе алыныр, икенчесе калдырылыр.

41 Ике катын (кул) тегермяне тартсалар, берсе алыныр, икенчесе калдырылыр.

Зач. 103.

42 Алай булгач, сез уяу торогоз, Ходайыгыз кайсы сагаття килясен белмейсез шул.

43 Сез мыны белясез: ӓгяр жорт эясе бурнын тӧння кайсы багытта килясен белся, ул уяу торор ыйы, ӱз жортона казыб керергя ирек бирмяс эйе.

44 Шуҥар кюря сез дя ӓзер булыгыз, Ӓдям Улы сез уйламаган сагаттюк килер шул.

45 Кызмятчеляреня багытында ашамнык бирсен диб, эяляре аларга башлык итеб куйган, акыллы, гадел кол кюк кем?

46 Ул кол, эясе килгян чакта, аҥар шулай кылыб, туры кился, бахетле.

47 Чыннаб ӓйтямен сезгя: ул аны бар малына баш итеб куяр.

48 Ӓгяр ул кол усал булыб, кюҥелендя эям тиз килмяс ӓле диб,

49 Ӱз иптяшлярен кыйнарга тотонса, эчкечеляр белян ашый, эчя башласа,

50 Ул колнын эясе, кол кӧтмягян кӧннӧ, ул уйламаган сагаття килер дя,

51 Аны уртара чабыб ӧзяр, аннары аны алдаучыларга теясе азабка ташлар; анда жылау, теш шыкырдатыу булыр, дигян.

25-нче бюлем.

Зач. 104.

1 Ул чакта кюк падшалыгы, жактырткьгчлар алыб, кеяӱгя карышы чыккан ун кызга ошаулы булыр.

2 Аларнын бишесе акыллы, бишесе уйсыз булганнар.

3 Уйсызлары жактырткычларын алыб, ӱзляре белян май алмаганнар.

4 Ӓммя акыллылары жактырткычларын да, сауытлар белян май да алганнар.

5 Кеяӱ озаклагач, барысыда жокомсраганнар да жоклаганнар.

6 Тӧн уртасында: мына кеяӱ киля, аҥар карышы чыгыгыз дигян тауыш эшетелгян:

7 Шунда ул кызлар барысыда тороб, жактырткычларын тӧзяткянняр.

8 Уйсызлары акыллыларына ӓйткянняр: безгя май бирчегез, безнен жактырткычларыбыз сюня, дигянняр.

9 Äммя акыллылары аларга жауаб биргянняр: безнен дя, сезнен дя житмяс булмасын, алай иткенче сез ÿзегезгя сатыучылардан барыб алыгыз, дигянняр.

10 Алар сатыб алырга киткяч, кеяÿ килгян; äзерляре анын белян бергя туйга кергянняр, алар кереÿ белян ишекне биклягянняр.

11 Суңыннан теге кызлар килеб äйткянняр: эй Ходай, эй Ходай, безгя ачсана, дигянняр.

12 Äммя Ул жауаб биргян: чыннаб äйтямен сезгя, мин сезне белмеймен, дигян.

13 Алай булгач, инде уяу торогоз: Äдям Улынын килясе кöнöн, сагатен белмейсез шул, дигян.

Зач. 105.

14 Бер кеше чит жиргя киткян чакта, колларын чакырыб алыб, аларга малын биреб калдырган.

15 Берсеня биш талантъ биргян, икенчесеня икене, öчöнчöсеня берне; äр кайсына кöчöня караб биргян дя, ÿзе тизюк киткян.

16 Биш талантъ алганы китеб, аларны эшкя тотоб, тагы биш талантъ табыш табкан.

17 Ике талантъ алганы да шулай тагы ике талантъ табыш табкан.

18 Äммя бер талантъ алганы киткян дя, аны жиргя кюмеб куйган, шулай итеб эясенен кöмöшöн жяшергян.

19 Байтак багыттан суң, шул колларнын эяляре кайтыб, алардан исяб сорой башлаган.

20 Биш талантъ алганы тагы биш талантъ китереб, жакын килеб äйткян: эй кужа! син миңа биш талантъ бирдең, мына мин алар белян тагы биш талантъ табтым, дигян.

21 Эясе аңар äйткян: жакшы, ышангышлы, арыу колом! äздя дöрöс булдың, сине кюбкя баш итеб куярым; инде мин эяң белян бергя сöйöн, дигян.

22 Ике талантъ алганы да шулай жакын килеб äйткян: эй кужа! син миңа ике талантъ бирдең, мына мин алар белян тагы ике талантъ табтым, дигян.

23 Эясе аңар äйткян: жакшы, ышангышлы, арыу колом! äздя дöрöс булдың, сине кюбкя баш итеб куярым; инде мин эяң белян бергя сöйöн, дигян.

24 Бер талантъ алганы да жакын килеб äйткян; эй кужа! мин синең каты кеше икяненңне, чячмягян жирдян урганыңны, тюкмягян жирдян жыйганыңны белеб,

25 Курыктым да, китеб талантыңны жиргя кюмдем; мя синга ÿзеңнекен, дигян.

26 Эясе аҥар жауаб биреб äйткян: эй жалкау, жаман кол! син чячмягян жирдян урганымны, тюкмягян жирдян жыйганымны белгяч,

27 Айса кöмöшöмне акча белян сатыу итеўчеляргя биреў киряк эйе; мин кайткач, аны табышы белян алыр ыйым.

28 Инде талантны аннан алыгыз да, ун талантлыга бирегез.

29 Барга äр-берсеня бирелер, арттырылыр да, äммя жукнын нейе бар, анысы да алыныр шул.

30 Бу жараусыз колно тыштагы карангылыкка ташлагыз; анда жылау, теш шыкырдатыу булыр. (Быларны äйткяч, Іисусъ тауыш кютяреб äйткян: эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян).

Зач. 106.

31 Äдям Улы Ўз ололлогында, бар арыу пяриштяляре белян килгяч, Ул Ўз ололлогынын престолына утырыр;

32 Аннары Анын карышысына бар калыклар да жыйылырлар; Ул аларны, кöтöўче сарыкларны кязялярдян айырган кюк, бер берсеннян айырыр:

33 Сарыкларны уҥ жагына, äммя кязялярне сул жагына куяр.

34 Шул чакта Падша уҥ жагындагыларга äйтер: эй Атамнын бахиллягянняре! килегез, дöнья булдырылганнан бирле сезгя äзерляб куйган падшалыкка урыннашыгыз.

35 Ачыккан чагымда сез Миҥа ашарга бирдегез, кибенгян чагымда Миҥа эчерттегез; чит жирдя жöргян чагымда сез Мине кабыл кюрдегез;

36 Жалангач чагымда Мине кейендердегез, чирлягян чагымда Мине карадыгыз, öтöрмяндя чагымда сез Минем жаныма килдегез шул, дирер.

37 Шул чагында гаделляр жауаб биреб, Аҥар äйтерляр: эй Ходай! ачыкканыҥны кюреб, без Сине кайчан туйдырдык? жя кибенгяненҥне (кюреб), кайчан эчерттек?

38 Чит жирдя жöргяненҥне кюреб, без Сине кайчан кабыл алдык? жя жалангач икяненгне (кюреб), кайчан Сине кейендердек?

39 Синеҥ чирлягяненҥне, жя öтöрмяндя булганыҥны кюреб, кайчан Синеҥ жаныҥа кердек? дирерляр.

40 Шунда Падша аларга жауабка äйтер: чыннаб äйтямен сезгя: быларны Минем кече энеляремнен берсеня кылгач, Миҥа кылыуыгыз булды, дирер.

41 Аннары сул жагындагыларга äйтер: эй каргаулылар! Минем катымнан шайтанга, анын иптяшляреня äзерляб куйган мянге утка китегез.

42 Ачыккан чагымда сез Минга ашарга бирмядегез, кибенгян чагымда Минга эчертмядегез;

43 Чит жирдя жӧргян чагымда сез Мине кабыл кюрмядегез, жалангач чагымда Мине кейендермядегез, чирлягян чагымда, ӧтӧрмяндя чагымда сез Минем жаныма килмядегез шул, дирер.

44 Шунда алар да Аңар жауаб биреб айтерляр: эй Ходай! Синең ачыкканыңны, жя кибенгяненңне, жя чит жирдя жӧргяненңне, жалангачлыгыңны, жя чирлягяненңне, жя ӧтӧрмяндя булганыңны кюреб, без Синга кайчан кызмят итмядек? дирерляр.

45 Шунда Ул аларга жауабка айтер: чыннаб айтямен сезгя: быларны шушы кечкенялярнен берсеня дя кылмагач, Минга кылмаганыгыз булды, дирер.

46 Аннары былар мянге азабка китярляр, ӓммя гаделляр мянге тормошка (керерляр), дигян.

26-нчы бюлем.

Зач. 107.

1 Бу сюзлярне барысын да айтеб бетергяч, Іисусъ Ўз ӧйрянеўчеляреня айткян:

2 Тагы ике кӧннян соң Пасха буласын белясез, шул чакта Ӓдям Улын кадакларга тотоб бирерляр, дигян.

3 Шул кӧннярдя архіерейляр, княгячеляр, калык башлыклары Каіафа атлы архіерейнен жортона жыйылганнар.

4 Алар Іисусны хайля белян тотоб алыб, ўтерергя киңяш иткянняр.

5 Алар айткянняр: алайда калык болганышмасын диб, мыны бяйрям кӧннӧ (кылмыйык), дигянняр.

Зач. 108.

6 Іисусъ Виѳаніядя кутырлы тянне Симоннын ӧйӧндя утырган чакта,

7 Анын жанына бер катын сауыт белян кыйбатлы мѵро алыб килеб, Ул утырган кӧйӧ, Анын башына койган.

8 Ӧйрянеўчеляр мыны кюреб, жаратмыйчы айткянняр: мыны ник ӓрям итте?

9 Бу мѵроны бик кыйбат сатыб, (акчасын) сораныучыларга бирергя мӧңким эйе ич, дигянняр.

10 Іисусъ мыны белеб, аларга айткян: ник сез бу катынны жӧдятясез? ул Минга жакшы эш кылды.

11 Сораныучылар жалан сезнен белян ич, ӓммя Мин жалан сезнен белян булмам.

12 Бу мѵроны тянемя койоб, ул Мине кюмяргя ӓзерляде.

13 Чыннаб айтямен сезгя: бӧтӧн дӧньядя кайда гна булса да шушы Евангеліе сӧйлянелся, ул катынны искя тӧшӧрӧб, анын ней кылганы да айтелер, дигян.

14 Шул чакта ун икенен берсе, Искаріоть Іуда дигяне архіерейлляргя барыб,

15 Äйткян: сез минга ней бирерсез? мин Аны сезгя тотоб бирем, дигян. Алар ангар утыз кӧмӧш тянкя бирмякче булганнар.

16 Шуннан сунг ул Іисусны тотоб бирергя кӧйлӧ багыт эзлягян.

17 Тӧчӧ кюмяч кӧнняренен элекеге кӧнӧндя, ӧйрянеӳчеляре Іисуска килеб айткянняр: Синга пасха äзерляргя безгя кайда кушасынг? дигянняр.

18 Ул айткян: калага шундый исемне кешегя барыб, ангар айтегез: Ӧйрятеӳче айтя: инде багытым жакыннашты, синенг ӧйӧндя ӧйрянеӳчелярем белян пасха кыларым диб айтте дигез, дигян.

19 Ӧйрянеӳчеляре Іисусъ кушканча кылганнар, пасха äзерлягянняр.

20 Кич булгач, Іисусъ (килеб) ун ике ӧйрянеӳчесе белян бергя утырган.

21 Ашаган чакта аларга айткян: чыннаб айтямен сезгя, сезнен арадан беряӳ Мине тотоб бирер, дигян.

22 Алар бик кайгыга тӧшӧб, берсе артыннан берсе Ангар айтя башлаганнар: эй Ходай, мин тӧгӧлме? диб.

23 Ул аларга жауаб биреб айткян: Минем белян бергя кулын тозлокка тыгыучы, шул Мине тотоб бирер.

24 Алайда Äдям Улы Ӳз турында жазылганча бара, тик Äдям Улын тотоб биреӳче кешегя жаман булыр, ул кешегя тыумаганы жакшырак булыр ыйы, дигян.

25 Шунда Аны тотоб биреӳче Іуда да айткян: эй Ӧйрятеӳче, мин тӧгӧл ме? дигян. Іисусъ ангар: син айттенг, дигян.

26 Ашаган чакта, Іисусъ икмяк алыб, аны бахилляб сындырган да ӧйрянеӳчеляреня биреб айткян: алыгыз, ашагыз, Бу Минем Тянем, дигян.

27 Аннары сауытны алыб, тау итеб, аларга биреб айткян: мыннан барыгызда эчегез,

28 Бу Минем кюб кешеляр ӧчӧн, жазыклар кичерер ӧчӧн агызган жанга законъ Каным.

29 Сезгя айтямен: мыннан былай бу жӧзӧм жимешенен сыуын Атамнын падшалыгында сезнен белян бергя жанга эчемнек эчясе кӧнгя чаклы эчмямен, дигян.

30 Аннары иман жырлагач, Елеонъ тауына киткянняр.

31 Шунда Іисусъ аларга áйткян: бу тӧндя сез барыгызда Минем турда шиклянерсез; жазылган шул: кӧтӧӳчесен уатыб бетерем, кӧтӧӳдяге сарыклары таралыб бетярляр, диб.

32 Терелеб торгач, сезне Галилеяда карышы алырым, дигян.

33 Петръ Аҥар жауаб биреб áйткян: Синеҥ турда барысыда шиклянсяляр дя, мин ич кайчанда шиклянмям, дигян.

34 Іисусъ аҥар áйткян: чыннаб áйтямен сиҥа: шушы тӧндя ӓтяч кычкыргынчы син Мине ӧч табкыр таҥарсын, дигян.

35 Петръ Аҥар áйткян: ӓгяр миҥа Синеҥ белян бергя ӳляргя туры кился дя, мин Сине таҥмам, дигян. Бар ӧйрянеӳчеляр дя шулаӣ диб áйткянняр.

36 Шуннан суҥ Іисусъ алар белян Геѳсиманія дигян урынга килгяч, анда ӧйрянеӳчеляреня áйткян: Мин тегендя барыб теляк итеб килгенче, сез мында утырыб торогоз, дигян.

37 Аннары Петрны, Зеведейнен ике улын Ӳзе белян алыб киткян дя, эче пошоб, кайгыра башлаган.

38 Шунда Іисусъ аларга áйткян: Минем жаным ӳлярлек булыб кӧйя, мында Минем белян уяу тороб торогоз, дигян.

39 Аннары алардан бер-аз читкя китеб, жӧз тюбян жыгылыб, инялеб áйткян: эй Атам, мӧҥким булса, бу сауыт Миннян ӳтсен эйе, алайда Мин телягянчя тӧгӧл, ӓммя Син телягянчя (булсын), дигян.

40 Аннары ӧйрянеӳчеляре жанына барыб, аларнын жоклаганын кюреб, Петрга áйткян: шулай итеб, сез Минем белян бер гня сагат тя уяу тора алмадыгыз меней?

41 Алданмас ӧчӧн, уяу торогоз, теляк итегез, тын уяу, ӓммя тян халсез, дигян.

42 Тагы икенче табкыр читкяряк китеб, былай диб инялгян: эй Атам, ӓгяр бу сауыт Миннян ӳтя алмаса, Мин аннан эчмей кала алмасам, айса Синеҥ иркеҥ булсын, дигян.

43 Кабат килеб, Ул тагы аларнын жоклаб жатканнарын кюргян, аларнын кюзлярен жоко баскан икян шул.

44 Тагынук аларны калдырыб, читкя китеб, ӧчӧнчӧ табкыр шул сюзлярне áйтеб теляк иткян.

45 Аннары ӧйрянеӳчеляре жанына килеб, аларга áйткян: сез ӓле гел жоклаб жатасыз икян; мына инде сагат жакыннашты, Ӓдям Улы жазыклылар кулына тотоб биреля.

46 Торогоз, áйдягез, мына Мине тотоб биреӳче жакыннашты, дигян.

47 Ул мыны әйткян чагындук, ун икенен берсе Іуда килеб житкян; анын белян бергя архіерейлярдян, калык башлыкларыннан жибярелгян кюб кеше кылычлар, казыклар алыб (килгянняр).

48 Аны тотоб биреўче аларга былай әйтеб билге куйган: мин Кемне ўбсям, шул Ўзе, Аны тотоб алыгыз, дигян.

49 Шул сяттюк ул Іисуска жакыннашыб, эй Өйрятеўче, сөйөн! диб әйтеб, Аны ўбкян.

50 Іисусъ аңар әйткян: эй дус! син мында нейгя килдеӊ? дигян. Шул чакта Іисуска жакын килеб, Аны кул белян тотоб алганнар.

51 Шунда Іисусъ белян бергя булганнарнын берсе кулын сузыб, кылычын алган да, архіерей колонын колагын чабыб өзгян.

52 Шунда Іисусъ аңар әйткян: кылычыңны кире урнына тык, кылыч алыучылар барысыда кылычтан харяб булырлар шул.

53 Әлля син, Мин казерюк Атама ўтенсям, Ул Миңа ун ике легіоннан да артык пяриштяляр жибярмяс диб уйлыйсың мы?

54 Шушылай буласы диб жазылган сюзляр ничек жиреня килер эйе суң? дигян.

55 Шул сяттюк Іисусъ калыкка әйткян: талаучыга чыккандый, кылычлар, казыклар алыб, сез Мине тотоб алырга чыккан, чиркяўдя өйряткян чагымда, Мин көндя сезнен белян утырдым ич, әммя сез Мине тотоб алмадыгыз, дигян.

56 Бу барда пагамбярляр жазган жиреня килер өчөн булды, дигян. Шул чакта өйрянеўчеляре барысыда Аны калдырыб качканнар.

Зач. 109.

57 Іисусны алыб китеўчеляр Аны Каіафа атлы архіерейгя алыб барганнар; анда князячеляр, оло кешеляр жыйылыб торганнар.

58 Шунда Петръ жырактын Анын артыннан архіерей жортона житкенче барган; бетеўне кюрер өчөн, ул ишек алдына кереб, кызмятчеляр белян бергя утырган.

59 Архіерейляр, оло кешеляр, хокөм итеўчеляр барысыда Іисусны ўтертер өчөн, Аңар карышы жалган айыб эзлягянняр;

60 Тик табалмаганнар: кюб жалган таныкчылар килгянняр, алайда (айыб) табмаганнар. Калдыгында ике жалган таныкчы килеб,

61 Әйткянняр: Ул әйтте: Алла чиркяўен жимереб, өч көндя аны торгозоб житкезерем диде, дигянняр.

62 Архіерей тороб Аңар әйткян: быларнын Сиңа карышы таныклауларына Син ник бер жауаб та бирмейсен? дигян.

63 Іисусъ дяшмягян. Аннары архіерей Аңар әйткян: тере Алланы алыб соройммын Синнян: әйт безгя, Алла Улы Христосъ Син ме? дигян.

64 Іисусъ аңар айткян: (дӧрӧс) айттең; тагынук сезгя айтямен: мыннан ары сез Кодрятленен уң жагында утырыб, кюк болотлары ӧстӧндя килеӱче Ӓдям Улын кюрерсез, дигян.

65 Шул чакта архіерей ӱз кейемнярен жыртыб айткян: Ул Алланы курлый, тагы безгя нейгя таныкчылар? мына сез казер Анын Алланы курлаганын эшеттегез.

66 Сезгя ничек тея? дигян. Алар жауаб биреб айткянняр: Аны ӱтерергя тейеш, дигянняр.

67 Шул чагында Іисуснын жӧзӧня тӧкӧргянняр, башына сукканнар, кайсылары жаңакларына сугыб,

68 Айткянняр: эй Христосъ, Сиңа кем сукты? белеб айт безгя, дигянняр.

69 Петръ тышта, ишек алдында утырган; анын жанына бер катын кызмятче килеб айткян: син дя Галилея Іисусы белян эйең, дигян.

70 Ӓммя Петръ барысынында алдында таңыб айткян: син ней айткянне белмеймен, дигян.

71 Ул кабкадан чыкканда, аны икенчесе кюреб, шундагыларга айткян: бу да Назорей Іисусъ белян эйе, дигян.

72 Ул тагы бу кешене белмеймен диб карганыб танган.

73 Бер-ауыктан суң шунда тороучылар Петрга жакын килеб айткянняр: чыннаб син алар арасыннан, сӧйляшеӱең дя кюрсятеб тора, дигянняр.

74 Шуннан суң ул: бу кешене белмеймен диб каргана башлаган, таңа башлаган. Шул сяттюк ӓтяч кычкырган.

75 Петръ Іисуснын аңар: ӓтяч кычкыргынчы син Мине ӧч табкыр таңарсын диб айткян сюзен исеня тӧшӧргян. Аннары чыгыб китеб, бик интегеб жылаган.

27-нче бюлем.

Зач. 110.

1 Иртя белян архіерейляр, калык башлыклары барысыда жыйылышыб киняш итеб, Іисусны ӱтерергя куйганнар.

2 Аны бяйляб алыб киткянняр дя Понтій Пилатъ тюрягя итеб биргянняр.

Зач. 111.

3 Шул чакта Іисусны тотоб биргян Іуда, Аны айыблаганны кюреб, ӱкенеб, утыз кӧмӧш тянкяне архіерейляргя, башлыкларга кайтарыб,

4 Айткян: айыбсыз канны сатыб биреб, жазыклы булдым, дигян. Алар аңар: безнен анда ней эшебез бар? ӱзең кара, дигянняр.

5 Ул аннары тянкялярне чиркяӱгя ташлаб чыккан да, китеб асылынган.

6 Архiерейляр тянкялярне алыб айткянняр: быларны, кан бяясе булганга кюря, чиркяў казнасына салырга тейеш тӧгӧл, дигянняр.

7 Киняш итеб, чит кешелярне кюмяр ӧчӧн, ул акчага чюлмякчедян жир сатыб алганнар.

8 Шунныктан ул жирне бӧгӧнгя чаклы кан жире диб айтеля.

9 Шул чакта Iеремiя пагамбяр арткылы айтелеў жиреня килгян, ул айткян: Израиль уллары бяялягяннен бяясен, утыз кӧмӧш тянкяне алыб,

10 Ул акчаны чюлмякче жире ӧчӧн тюляделяр, Ходай минга шулай айтте, дигян.

11 Iисусъ тюря алдында торганда, тюря Аннан сораган: Син Iудея Падшасы мы? дигян. Iисусъ ангар: (дӧрӧс) айтясен, дигян.

12 Архiерейляр, калык башлыклары Аны айыблаб торганда, Ул бер дя дяшмягян.

13 Аннары Пилатъ Ангар айткян: Синга карышы ней чаклы таныклык иткянняреn эшетмейсен меней? дигян.

14 Iисусъ анын бер сюзеня дя жауаб бирмягян, тюрянен шунгар бик исе киткян.

15 Тюрянен (Пасха) бяйряменя быгаудагыларнын берсен, калык телягянен жибяря торган жоласы бар икян.

16 Шул чакта аларнын быгауда тороучы Варавва атлы билгеле кешеляре булган.

17 Алар жыйылыб житкяч, Пилатъ аларга айткян: икесенен кайсын жибяр диб телейсез: Варавваны мы, алля Христосъ дигян Iисусны мы? дигян.

18 Ул аларнын Аны кӧнчӧлӧк белян тотоб биргянняреn белгян.

19 Шул арада, Пилатъ хокӧм урнында утырган чакта, катыны ангар былай диб айтергя жибяргян: Ул гаделгя бер нястя дя кылма, мин Анын ӧчӧн бӧгӧн тӧшӧмдя бик кюб азабландым шул, дигян.

20 Äммя архiерейляр, оло кешеляр калыкны: Варавваны жибярт, äммя Iисусны ўтерт диб айтергя котортканнар.

21 Аннары тюря алардан тагы сораган: бу икенен кайсын жибяр диб телейсез? дигян. Алар: Варавваны, дигянняр.

22 Пилатъ аларга айткян: Христосъ дигян Iисуска сун ней кылыйым? дигян. Алар ангар барысыда: Аны кадаклат, дигянняр.

23 Тюря айткян: Ул ничек усаллык кылды сун? дигян, äммя алар: Аны кадаклат диб бигряк тя шяб кычкырганнар.

24 Пилатъ ничек ится дя булыша алмаганын кюреб, äммя калыкнын бигряк тя болганганын кюреб, сыу алган да, калык алдында

кулын жыуыб айткян: мин бу гаделнен канына айыблы тӧгӧл, ӱзегез карагыз, дигян.

25 Калык барда жауаб биреб айткян: Анын каны безгя, безнен балаларыбызга да (тӧшсӧн), дигянняр.

26 Шуннан суң алар (телягянчя) Варавваны жибяргян, äммя Іисусны кыйнатыб, кадакларга биргян.

Зач. 112.

27 Шул чакта тюрянен салдатлары Іисусны хокӧм урнына алыб килеб, Анын жанына бӧтӧн полкны жыйганнар.

28 Шунда Іисуснын кейемен салгызыб, Аңар кызыл кейем кейгезгянняр;

29 Башына чянечкеле агач чыбыгыннан ӱрмя ӱреб кейгезгянняр; уң кулына таяк тотторганнар; аннары Анын алдында тезлянеб тороб, Аннан мыскыл итеб, айткянняр: эй Іудея Падшасы, сӧйӧн! диб.

30 Аңар тӧкӧргянняр, таягын алыб, башына сукканнар.

31 Аны мыскыллаб туктагач, ӧстӧндяге кызыл кейемне салгызыб, Ӱз кейемен кейгезгянняр, аннары кадакларга алыб киткянняр.

32 Чыгыб барган чакта, Киринеянын Симонъ атлы кешене очратыб, аңар Іисуснын качын кютяртеб баргызганнар.

Зач. 113.

33 Голгоѳа исемне Мангай урны дигян жиргя житкяч,

34 Іисуска эчяргя ӱт катыштырган серкя биргянняр, Ул аны татыб караган да, эчясе итмягян.

35 Іисусны кадаклаучылар Анын кейемнярен жирябя салыб ӧляшкянняр.

36 Аннары шунда Аны саклаб утырганнар.

37 Анын башы ӧстӧня айыбын кюрсятеб: Бу Іудея Падшасы Іисусъ диб жазыб куйганнар.

38 Шунда Анын белян бергя ике талаучыны кадаклаганнар: берсен уң жагына, икенчесен сул жагына.

39 Жаныннан узыучылар башларын селкеб, Аны курлаб,

40 Äйткянняр: эй чиркяӱне жимереб, ӧч кӧндя торгозоб житкезеӱче! Ӱзеңне Ӱзең коткар; äгяр Син Алла Улы булсаң, качыңнан тӧш, дигянняр.

41 Архіерейляр, князячеляр, калык башлыклары, фарисейляр дя шулай мыскыллаб айткянняр:

42 Бютяннярне коткарган, äммя Ӱзен Ӱзе коткара алмый. Äгяр Ул Израиль Падшасы булса, айса инде качыннан тӧшсӧн, шунда Аңар ышанырбыз;

43 Ул Аллага ышанган ыйы, ăгяр Аҥар жараулы булган булса, инде Аны Алла коткарсын; Ул Ўзе: Мин Алла Улы диб айткян эйе, дигянняр.

44 Анын белян кадакланган талаучылар да шулай Аны курлаганнар.

45 Алтынчы сагаттян тугызынчы сагаткя чаклы бӧтӧн жир ӧстӧндя карангы булыб торган.

46 Тугызынчы сагат тирясендя Іисусъ каты тауыш белян кычкырыб айткян: Или, Или! лама савахѳани? дигян. бу: эй Аллам, эй Аллам, Син Мине ник ташладыҥ? дигян сюз була.

47 Шунда тороучыларнын кайсылары мыны эшетеб: Ул Иліяны чакыра, дигянняр.

48 Шул сяттюк алар арасыннан берсе жӧгӧрӧб барыб, болот алыб, аҥар серкя сеҥдереб, аны таякка элеб, Іисуска эчяргя биргян.

49 Ўнгяляре айткянняр: тукта ăле, караб торойок, Илія Аны коткарырга килер микян? дигянняр.

50 Іисусъ тагы каты тауыш белян кычкырыб, тынын чыгарган.

51 Шул чакта чиркяў шаршауы жугары кырыйыннан тюбян кырыйына чаклы икегя айырылган; жир титрягян, ташлар жарылганнар.

52 Каберляр ачылганнар, кюб ўлгян изгелярнен тянняре терелгянняр;

53 Іисусъ терелеб торгач, алар каберляреннян чыгыб, арыу калага барыб, кюб кешеляргя кюренгянняр.

54 Сотникъ та, анын белян бергя Іисусны саклаб тороучылар да, жир титрягянне, бютян эшляр булганны да кюреб, бик куркышыб айткянняр: чыннаб Бу Алла Улы икян, дигянняр.

55 Анда тагы кюб катыннар да жырактын караб торганнар; алар Іисуска Галилеяда эяреб, Аҥар кызмят итеб жӧргянняр.

56 Алар арасында Марія Магдалина, Іаковъ белян Іосіянын анасы Марія, тагы Зеведей улларынын анасы да булган.

57 Кич булгач, Аримаѳеядан Іосифъ атлы бер бай кеше килгян, ул да Іисуснын ӧйрянеўчесе икян.

58 Ул Пилатка барыб, Іисуснын тянен сораган. Пилатъ тянне бирергя кушкан.

59 Іосифъ тянне алыб, аны таза киндер белян чырмаган;

60 Аннары аны ўзенен таш тауга тишеб жасаган жаҥа кабереня куйган; кабер ауызына зур таш каблаб киткян.

61 Шунда Марія Магдалина, тагы бютян Марія да булган; алар кабер карышысында утырганнар.

Зач. 114.

62 Пятницанын иртягесен архіерейляр белян фарисейляр жыйылышыб, Пилатка килеб,

63 Ййткянняр: эй тюря! теге жалганчынын тере чагында: өч көннян суң терелеб тором дигяне исебезгя төштө.

64 Шуңар кюря Син Анын каберен өч көнгя чаклы саклатчы, өйрянеўчеляре төння килеб, Аны урламасыннар, калыкка: Ул ўлгяненнян терелеб тордо димясенняр. Аннары сунгы алдауы элекегесеннян дя жаманырак булыр, дигянняр.

65 Пилатъ аларга айткян: сезнен сакчыларыгыз бар, барыгыз, ўзегез белгянчя саклатыгыз, дигян.

66 Алар барыб, кабер жанына сакчылар куйганнар, ташын пичятлягянняр.

28-нче бюлем.

Зач. 115.

1 Суббота ўткяч, атнанын элекеге көнөндя, таңаткан чакта Марія Магдалина, тагы бютян Марія белян каберне карарга барган.

2 Кинят жир бик каты титрягян, Ходай пяриштясе кюктян төшөб, кабер жанына килеб, ауызындагы ташны аударыб, анын өстөня утырыб торган.

3 Анын төсө жяшен кюк, кейеме кар кюк ак икян.

4 Сакчылар аннан куркыб, калтрашыб ўле мясялле булганнар.

5 Пяриштя катыннарга боролоб айткян: сез курыкмагыз, мин сезнен кадакланган Іисусны эзлей килгянегезне белямен.

6 Ул мында жук, Ул Ўзе айткянчя, терелеб тордо. Килегез, Ходай жаткан урынны кюрегез.

7 Аннары тизеряк барыб, Анын өйрянеўчелярения айтегез: Ул ўлгян жиреннян терелеб торган, Ул сезне Галилеяда карышы алыр, Аны анда кюрерсез, дигез. Мына мин сезгя айтеб бирдем, дигян.

8 Алар кабердян жятляб чыкканнар да, куркыб, бик сөйөнөшөб, Анын өйрянеўчелярения хабяр итяргя жөгөргянняр; алар Анын өйрянеўчелярения хабяр итяргя барган чакта,

9 Мына Іисусъ аларга очраб: сөйөнөгөз! дигян. Алар жакын килеб, аягын тотоб, Аңар башырганнар.

10 Шунда Іисусъ аларга айткян: курыкмагыз! барыгыз, агай-энеляремя айтегез, алар Галилеяга барсыннар, шунда Мине кюрерляр, дигян.

11 Катыннар барган чакта, сакчыларнын кайсылары калага кайтыб, ней булганны барысында архіерейляргя белдергянняр.

12 Архіерейляр башлыклар белян жыйылышыб киӊяш иткянняр дя, салдатларга байтак акча биреб,

13 Äйткянняр; сез тöння без жоклаганда, öйрянеӱчеляре килеб, Аны урлаганнар диб äйтегез.

14 Äгяр ул баш тюрягя эшетелся, без аны кöйлярбез, сезне кайгыга калдырмабыз, дигянняр.

15 Сакчылар акча алыб, алар öйряткянчя кылганнар; шул сюз Іудейляр арасында бу кöнгя чаклы жяйелеб тора.

Зач. 116.

16 Ун бер öйрянеӱче Іисусъ барырга кушкан тöшкя Галилеяга, тау öстöня киткянняр.

17 Шунда алар Аны кюреб, Аӊар башырганнар, äммя кайсылары шиклянеб торганнар.

18 Іисусъ жакын килеб, аларга äйткян: кюктя дя, жирдя дя Миӊа äр-тöрлö кыуат бирелде.

19 Инде барыгыз, бар калыкларны да öйрятегез, аларны Ата, Ул, Святый Тын исеменя чумылдырыгыз.

20 Мин сезгя кушканны барын да кыларга аларны да öйрятегез. Мына Мин дöнья беткенче бар кöннярдя дя сезнен белян дигян. Аминь.

# Маркъ жазган арыу Евангеліе.

1-нче бюлем.

Зач. 1.

1 Алла Улы Іисусъ Христоснын Евангеліесенен башы.

2 Пагамбярляр жазганча: мына Мин Синеӈ алдыӈнан Ўз пяриштямне жибярем, ул Синеӈ алдыӈнан жулыӈны äзерляб куяр;

3 Ходайга жул äзерлягез, Аӈар туры сукмаклар жасагыз диб буш кырда кычкырыучынын ауазы дигянчя,

4 Буш кырда чумылдырыучы Іоаннъ булган, ул жазыклар кичелер öчöн тяўбя итеў чумылдырыуын сöйлягян.

5 Шунда аӈар бöтöн Іудея жагындагылар, Іерусалимдягеляр чыгыб, барысыда жазыкларын айтеб, аннан Іорданъ сыуында чумылдырылганнар.

6 Іоаннын öстöндяге кейеме дöя жононнан, билендяге эзяре тиредян булган, ашамныгы сикерткя белян кыр балы булган.

7 Ул былай äйтеб сöйлягян: минем артымнан минням Кыуатлы киля, мин Анын башмагынын кайышын эйелеб чишяргя дя тормоймын.

8 Мин сезне сыу белян чумылдырдым, äммя Ул сезне Святый Тын белян чумылдырыр, дигян.

Зач. 2.

9 Шул кöннярдя Іисусъ Галилея Назаретыннан килеб, Іоаннан Іорданда чумылдырылган.

10 Іисусъ сыудан чыккан сяттюк, (Іоаннъ) кюк ачылыб, Іисусъ öстöня кюгярчен ряўешле булыб ингян Тынны кюргян.

11 Шунда кюктян ауаз килгян: Син Минем сöйöклö Улым, Синдя Минем ризалыгым, диб.

12 Шуннан суӈ тизюк Тын Аны буш кырга алыб барган.

13 Буш кырда Ул кырык кöн торган, шайтаннан сыналган, кейекляр белян булган; анда Аӈар пяриштяляр кызмят иткянняр.

14 Іоаннъ тотоб бирелгяч, Іисусъ Алла падшалыгынын Евангеліесен сöйляб, Галилеяга килгян.

15 Ул äйткян: инде багыт житте, Алла падшалыгы жакыннашты, тяўбя итегез, Евангеліегя ышаныгыз, дигян.

Зач. 3.

16 Галилея дингезе жаныннан ӯтеб барганда, Іисусъ дингезгя ау салыб торган Симонны, анын энесе Андрейне кюргян; алар балыкчылар икян.

17 Іисусъ аларга äйткян: Минем артымнан барыгыз, Мин сезне кешелярне тотоучы итярмен, дигян.

18 Алар шундук ауларын калдырыб, Анын артыннан киткянняр.

19 Аннан бер-аз киткяч, Зеведей Іаковын, анын энесе Іоанны кюргян, алар да кимядя ауларын тöзятяляр икян.

20 Шул сяттюк Ул аларны чакырган; алар аталары Зеведейне жалчылары белян бергя кимядя калдырыб, Анын артыннан киткянняр.

21 Капернаумга килгянняр; килгяч суббота кöннö Іисусъ синагогага кереб, öйрятеб утырган.

22 Анын öйрятеӯеня исляре киткян, Ул аларны кодряте барын тойдороб öйряткян шул, äммя князячеляр кюк тöгöл.

Зач. 4.

23 Аларнын синагогаларында бер женнянгян кеше бар икян, ул кычкырыб,

24 Äйткян: эй Іисусъ Назарянинъ! безгя теймя, бездя Синеҥ ней эшеҥ бар? Син безне бетерергя килгян, Син Кем икянне белямен, Син Алланын Изгесе, дигян.

25 Іисусъ аҥар кисятеб äйткян: дяшмя, анын эченнян чык, дигян.

26 Шул сяттюк жен аны калтратыб, бик каты тауыш белян кычкырыб, анын эченнян чыккан.

27 Шуннан суҥ барысы да куркышыб, бер берсеннян сорашканнар: бу ней хал? бу нейдей жаҥа öйрятеӯ? Ул шакшы тыннарга да кодрят белян кисятя, алар Аны тыҥныйлар, дигянняр.

28 Аннары тизюк Анын хабяре бöтöн Галилея тиряляреня жяйелгян.

Зач. 5.

29 Синагогадан чыккач, (Іисусъ) тизюк Іаковъ белян Іоанны алыб, Симонъ белян Андрей öйöня килгян.

30 Симонъ катынынын анасы тир кастасы белян жата икян; аны шундук Іисуска äйткянняр.

31 Ул анын жанына барыб, кулыннан тотоб торгозган, шул сяттюк тир кастасы беткян; аннары ул аларга кызмят итя башлаган.

32 Кич булгач, кояш байыган чакта, Анын жанына бар чирлелярне, женнелярне китергянняр.

33 Бöтöн кала ишек тöбöня жыйылган.

34 Шунда Ул төрлө чир белян азабланган кюб кешене сауыктырган, кюб женнярне (кешелярдян) кыуалаб чыгарган, женняргя Ул Христосъ икянне белгянняреn айтергя бойормаган.

Зач. 6.

35 Иртягесен бик иртя тороб чыккан да буш жиргя китеб, анда теляк иткян.

36 Симонъ да, анын белян булганнар да Іисусъ артыннан жөгөргянняр.

37 Аны табкач, Аңар: Сине барда эзлейляр, дигянняр.

38 Ул аларга айткян: айдягез жакындагы ауылларга, калаларга барыйык, Мин анда да сөйляргя тейеш, Мин шунын өчөн килдем шул, дигян.

39 Ул бөтөн Галилеядя синагогаларда өйрятеб жөргян, женнярне дя кыуалаб чыгарган.

40 Шунда Аңар тяне кутырлаган бер кеше килеб, инялеб, Анын алдында тезлянеб тороб айткян: телясяң, Син мине тазарта алыр ыйың дигян.

41 Іисусъ аны кызганыб, кулын сузыб, аңар тейенеб айткян: телеймен, тазарын, дигян.

42 Іисусъ шул сюзне айткяч тя, анын кутыры койолган, ул аннары тазарыб калган.

43 Іисусъ аны жибяргян чакта, аңар кисятеб,

44 Айткян: аң бул, беряўгя дя бер сюз дя айтмя, тик барыб, ўзеңне священниккя кюрсятеб, тазарганыңа, Моисей кушканча, аларга таныклыкка бюляк китер, дигян.

45 Аммя ул чыгыу белян, ней булганны сөйляб жяйелдеря башлаган, шунныктан аннары Іисусъ калага кюренеб керя алмаган, тик каладан тышта, буш жирлярдя гня торган. Шунда Аңар төрлө жирдян килгянняр.

2-нче бюлем.

Зач. 7.

1 Бер-ауык көннярдян суң, Іисусъ тагы Капернаумга килгян; анда Анын бер өйдя икянен эшеткянняр.

2 Шул сяттюк кюб кеше килеб тулган, ишек катында да урын калмаган; Ул аларга сюз сөйлягян.

3 Шунда Аңар дюрт кеше бер сансызны кютяреб китергянняр.

4 Кеше кюблектян Іисуска жакыннашырлык булмагач, алар Ул утырган өйнөн тюбясен ачыб, сансызны жаткан урны белян (Анын алдына) төшөргянняр.

5 Іисусь аларнын ышаныуын кюреб, сансызга áйткян: улым, синґа жазыкларынґ кичереля, дигян.

6 Анда князячелярнен берауыгы утыра икян, алар ўз кюнґеллярендя уйлаганнар:

7 Ул ник былай Алланы курлый? Бер Алладан бютян кем жазыкларны кичеря алыр? дигянняр.

8 Іисусъ шундук Ўз тыны белян, алар ўз эчлярендя шулай уйлаганны белеб, аларга áйткян: сез кюнґеллярегездя ник алай уйлыйсыз?

9 Ней асатрак: сансызга жазыкларынґ кичереля диб áйтеў ме? áлля тор да, урнынґны алыб кит диб áйтеў ме?

10 Áммя Áдям Улынын жир öстöндя жазыклар кичерергя кыуаты барын сез белсен диб, (áйтямен дигян дя сансызга áйткян):

11 Синґа áйтямен: тор да, урнынґны алыб, öйöнґя кайт, дигян.

12 Ул шундук торган да, урнын алыб, барысы алдында чыгыб киткян; барысыда исляре китеб, Алланы мактаб áйткянняр: мындый эшне без бер чакта да кюрмядек, дигянняр.

Зач. 8.

13 Іисусь тагынук дингез жанына чыккан, бар калык Анын катына барган, Ул аларны öйряткян.

14 Узыб барган чакта, Ул сатлык мал акчасын жыя торган тöштя утырган Алфей улы Левійне кюреб, анґар áйткян: Минем артымнан бар, дигян. Ул тороб, Анґар эяреб киткян.

15 Іисусь анын öйöндя утырган чакта, Анын белян бергя öйрянеўчеляре, тагы кюб мытарлар, жазыклылар утырганнар; алар кюб икян, барысыда Анын белян жöргянняр.

16 Князячеляр, фарисейляр, Ул мытарлар белян, жазыклылар белян ашаганны кюреб, Анын öйрянеўчеляреня áйткянняр: ник Ул мытарлар белян, жазыклылар белян бергя ашый, эчя? дигянняр.

17 Іисусъ мыны эшетеб, аларга áйткян: сауларга лекарь киряк тöгöл, áммя чирлеляргя (киряк). Мин жазыклыларны тяўбягя öндяргя килдем, áммя гаделлярне тöгöл, дигян.

Зач. 9.

18 Іоаннь öйрянеўчеляре белян фарисейляр öйрянеўчеляре ураза тотканнар. Шунда Іисуска килеб áйткянняр: Іоаннъ öйрянеўчеляре, фарисейляр öйрянеўчеляре ник ураза тоталар, áммя Синенґ öйрянеўчелярен ней öчöн ураза тотмойлар? дигянняр.

19 Іисусъ аларга áйткян: кодаларга кеяў алар белян чагында ураза тотарга мöнґким ме? Кеяў алар белян чагында ураза тотарга мöнґким тöгöл.

20 Алардан кеяӱ алыныр кӧнняр килеб житяр, житкяч, шул кӧннярдя ураза тотарлар.

21 Беряӱ дя тузган кейемгя агартмаган киндердян жамау салмый, жугыйса жаңа жамау тузган кейемне айырыр да, жыртыгы тагы да чагырак булыр.

22 Жаңа аракыны да беряӱ дя иске турсыкка салмый, жугыйса жаңа аракы турсыкны айырыр да, аракы да агар, турсыгы да ӓрям булыр; ӓммя жаңа аракыны жаңа турсыкка тутырырга тейеш, дигян.

Зач. 10.

23 Бер суббота кӧннӧ Аңар ашлык басыуыннан ӱтеб барырга туры килгян; барган чакта Анын ӧйрянеӱчеляре ашлык башларын ӧзӧб-ӧзӧб алганнар.

24 Фарисейляр Аңар ӓйткянняр: кара, алар ник суббота кӧннӧ тейеш тӧгӧлне кылалар? дигянняр.

25 Ул аларга ӓйткян: Давидъ ӱзе дя, анын белян булганнар да, ачыккач, жӧдягяч, ул ней кылганны бер чакта да укымадыгыз мы ӓлля?

26 Ничек ул Авіаѳаръ архіерей багытында, Алла ӧйӧня кереб, священниклярдян бютянгя беряӱгя дя ашарга тейеш тӧгӧл китереб куйылган икмяклярне алыб, ӱзе дя ашаган, ӱзе белян булганнарга да биргян, дигян.

27 Аларга тагы ӓйткян: суббота кеше ӧчӧн, ӓммя кеше суббота ӧчӧн тӧгӧл.

28 Шунныктан Ӓдям Улы субботага да башлык, дигян.

## 3-нчӧ бюлем.

1 Іисусъ тагы синагогага килгян; анда кулы короган бер кеше булган.

2 Іисусны айыблар ӧчӧн, Ул бу кешене суббота кӧннӧ тӧзятмяс ме диб, Аны караб торганнар.

3 Ул кулы короган кешегя ӓйткян: уртага чыгыб тор, дигян.

4 Аннары аларга ӓйткян: суббота кӧннӧ жакшылык кыларга тейеш ме, ӓлля усаллык кыларга мы? жанны сакларга тейеш ме, ӓлля ӓрям итяргя ме? дигян. Ӓммя алар дяшмягянняр.

5 Ул аларнын кюңелляре катыланганга кайгырыб, аларга ачыу белян караб, теге кешегя ӓйткян: кулыңны суз, дигян. Ул сузган, сузгачук анын кулы икенчесе кюк сау булган.

Зач. 11.

6 Фарисейляр чыгыб, тизюк иродныкылар белян бергя, Іисусны ничек итеб бетерейек икян диб, Аңар карышы киняш корганнар.

7 Ӓммя Іисусъ Ӱз ӧйрянеӱчеляре белян дингез жанына киткян.

8 Анын артыннан Галилеядан, Іудеядян, Іерусалимнян, Идумеядян, тагы Іорданнын ары жагыннан да кюб калык барган; Тиръ белян Сидонъ тиряляpендя тороучы бик кюб кеше, Ул ней кылганны эшетеб, Анын жанына килгянняр.

9 Калык кюблектян, Ул Ӱзен тыгызламасыннар диб, ӧйрянеӱчеляреня Ӱзе ӧчӧн кимя ӓзерляргя кушкан.

10 Кюб (кешене) тӧзяткян, шуҥар кюря жаралылары Аҥар тейенер ӧчӧн, Анын жанына тыгылышыб килгянняр.

11 Женняр дя Аны кюргяч, Анын алдында жыгылыб тороб, Син Алла Улы диб кычкырганнар.

12 Ӓммя Ул Ӱзен билгеле итмясенняр диб, аларга бик каты кисяткян.

Зач. 12.

13 Аннары тау ӧстӧня менеб, Ӱзе телягяннярне чакырыб алган, алар Аҥар килгянняр.

14 Аларнын ун икесен Ӱзе белян бергя жӧрӧргя, сӧйляргя жибярергя сайлаб куйган.

15 Аларга чирлярне тӧзятергя, женнярне (кешедян) чыгарырга кыуат биргян.

16 Симонны Петръ диб атаб,

17 Зеведей улы Іаковны, анын энесе Іоанны Воанергесъ диб атаб куйган, Воанергесъ дигяне кюкряӱ уллары дигян сюз.

18 Андрейне, Филиппны, Варѳоломейне, Матѳейне, Ѳоманы, Алфей улы Іаковны, Ѳаддейне, Кананитъ (дигян) Симонны,

19 Искаріотъ Іудасын куйган, шушысы Іисусны тотоб биргян.

Зач. 13.

20 Аннары бер ӧйгя кергянняр: анда тагы калык кюб жыйылганныктан, аларга икмяк ашар хал дя булмаган.

21 Іисуснын жакыннары, Ул акылдан чыккан диб сӧйляшкянне эшетеб, Аны алыб китейек диб килгянняр.

22 Іерусалимнян килгян князячеляр ӓйткянняр: Анын эчендя веельзевулъ бар. Ул женнярне женняр башлыгынын кӧчӧ белян чыгара, дигянняр.

23 Ул аларны дяшеб алган да, аларга мясалляр китереб ӓйткян: шайтан шайтанны ничек кыуалаб чыгарсын?

24 Ӓгяр падшалык ӱзе ӱз алдында айырылышса, ул падшалык тора алмас.

25 Жорт та ӱзе ӱз алдына айырылса, ул жорт тора алмас.

26 Ӓгяр шайтан да ӱзеня ӱзе карышылык итеб, айырылса, ул тора алмас, анын бетяр багыты житкян була.

27 Беряў дя кöчлöнöн ӧйöня кереб, элеке кöчлöнöн ўзен бяйлямяся, анын нястяляреn талаб китя алмас, шул чакта гна анын ӧйöн талаб китя алыр, дигян.

Зач. 14.

28 Чыннаб айтямен сезгя: ädям улларына бар жазыклары да кичерелер, ничек итеб курласалар да, курлаганнары да (кичерелер).

29 Тик кем Святый Тынны курласа, аңар кичерелеў булмас гумергя, äммя ул мянгегя айыблы булыр, дигян.

30 (Мыны Ул) Анда жен бар дигянняреня кюря äйткян.

31 Шунда анасы белян агалары килгянняр; алар ӧйнöн тыш жагында тороб, Аны чакыртканнар.

32 Анын äйлянясендя калык утырган. Аңар äйткянняр: мына анаң да, агаларың да, туталарың да тышта Сине чакыралар дигянняр.

33 Ул аларга äйткян: кем Минем Анам? кем Минем агаларым? дигян.

34 Аннары äйлянясендя утырыучыларга караныб äйткян: мына Минем анам, мына Минем агаларым да.

35 Кем дя кем Алла иркен кылыб торса, шул Миңа ага-эне, тута-сеңел, ана да, дигян.

## 4-нче бюлем.

Зач. 15.

1 Іисусъ тагы дингез жанында ӧйрятя башлаган. Анын жанына кюб калык жыйылган, шунныктан Ул кимягя кереб, дингез ӧстöндя утырган, äммя калык бар да дингез жанында, жир ӧстöндя торган.

2 Ул аларны мясялляр белян кюб ӧйряткян; ӧйрятеб аларга äйткян:

3 Тыңнагыз äле: мына чячеўче чячяргя чыккан.

4 Чячкян чагында кайсы (бöртöгö) жул кырыйына тöшкян; кошлар очоб килгянняр дя аларны чюбляб бетергянняр.

5 Кайсысы ташлык жиргя тöшкян; анда балчык аз гна булган: балчык сай булганныктан алар тизюк тишелеб чыкканнар.

6 Кояш чыккач, алар шиңеб беткянняр; тамырлана алмаганга кюря, короганнар.

7 Кайсысы тигяняклеккя тöшкян; тигяняк ўсеб житкяч, аларны басыб алган, аннары алар жимеш китермягянняр.

8 Кайсысы жакшы жиргя тöшкян: алары тишелеб ўсеб жимеш китергянняр: кайсысы утыз, кайсысы алтмыш, кайсысы жöз (бöртöк) китергян, дигян.

9 Аннары аларга äйткян: эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 16.

10 Калык киткяч, Анын жанындагылар, ун ике (ӧйрянеӱчесе) дя бергя Аннан мясял турысында сораганнар.

11 Ул аларга айткян: сезгя Алла падшалыгынын жяшереклярен белергя бирелгян, ӓммя теге тыштагыларга барысы да мясял белян айтеля.

12 Алар жазыкларын кичерттермяс ӧчӧн, (Аллага) кайтмас ӧчӧн, кюзляре белян карасалар да кюрмейляр, колаклары белян эшетсяляр дя аңнамыйлар, дигян.

13 Аннары аларга айткян: сез бу мясялне аңнамыйсыз меней? бар мясяллярне ничек аңнарсыз суң?

14 Чячеӱче сюз чячя.

15 Жул кырыйына чячелгяне шушындый кешелярне белдеря: алар эченя сюз чячеля, тик эшеткян сятлярендюк шайтан килеб, аларнын кюңеленя чячелгян сюзне алыб китя.

16 Шунын кюк ташлык жиргя чячелгяне дя сюзне эшеткяч тя, аны тизюк сӧйӧнӧч белян кабыл алган кешелярне белдеря;

17 Тик алар жяйелгян тамырлары жукка кюря, ныклыклары да булмаганга, эшеткян сюз ӧчӧн суңыннан кайгы, жя кысаннык туры кился, шул сяттюк шикляня башлыйлар.

18 Тигяняклеккя чячелгяне сюзне былай тыңнаучыларны белдеря:

19 Бу гумернен сагышлары, байлыкка алданыулык, тагы бютян няпесляр дя аларга кереб, сюзне басыб бетеряляр; аннары ул сюз жимеш китермей.

20 Ӓммя жакшы жиргя чячелгяне мындыйларны белдеря: алар сюзне эшетеӱ белян кабыл алалар, аннары берсе утызлаб, икенчесе алтмышлаб, ӧчӧнчӧсӧ жӧзляб жимеш китеря, дигян.

21 Аннары тагы аларга айткян: эшямне сауыт астына, жя жата торган урын астына утыртыр ӧчӧн китеряляр меней? аны эшямдялгя утыртырга (китеряляр) тӧгӧл ме?

22 Кюренмей каласы бер жяшерен дя жук; жяшереб куйганнын да ич берсенен тышка чыкмый каласы жук.

23 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 17.

24 Аларга тагы айткян: эшеткянегезгя аң салыгыз. Ничек ӱлчяӱ белян ӱлчясягез, ӱзегезгя дя шулай ӱлчянер, сез тыңнаучыларга арттырылыр да.

25 Барга бирелер, ӓммя жукнын нейе бар, анысы да алыныр шул, дигян.

26 Тагынук айткян: Алла падшалыгы кеше жиргя ташлаган орлокка ошаулы:

27 Ул (кеше) тӧння дя, кӧндӧз дя, жоклой да, тора да, ӓммя орлок ничек тишелеб, ничек ўскянне белмей.

28 Жир ўзе жимеш китеря: элеке ул жяшел ужым ўстеря, аннары баш чыгарта, аннары башакны тӧш белян тутыра.

29 Ашлык житкяч, ул (кеше) урыр багыт житкянгя кюря, тизюк уракчылар жибяря, дигян.

30 Аннары айткян: Алла падшалыгын нейгя ошатыйык? жя аны ничек мясял белян айтеб кюрсятейек?

31 Ул горчица орлогона ошаулы: ул орлокно жиргя чячкяндя, ул жирдяге барча орлоклардан да ыуагырак була;

32 Ӓммя чячкячен, тишелеб чыга да, бар ўлямнярдян дя олорак була, зур тармаклар чыгара, анын кюлягясендя ауа кошлары килеб, кунаклаб утырырлык була, дигян.

33 Шундый кюб мясялляр белян, алар тынґный алган тинґете, Ул аларга сюз сӧйлягян.

34 Аларга мясялсез сӧйлямягян, ӓммя ӧйрянеўчеляреня аулакта бар турныда анґнаткан.

Зач. 18.

35 Шул кӧннӧ кич Ул аларга айткян: теге жакка кичейек, дигян.

36 Аннары алар калыкны жибяреб, Аны кимядяге кӧйӧ, ўзляре белян бергя алыб киткянняр; Анын белян бютян кимяляр дя булган.

37 Шунда бик шяб дауыл кютярелгян; тулкыннар кимягя кереб, кимягя сыу тула башлаган.

38 Ӓммя Ул кормада мендяр салыб жоклаган икян. Аны уятыб, Анґар айткянняр: эй Ӧйрятеўче! без бетябез, Син анґар кӧймӧйсенґ меней? дигянняр.

39 Ул торган да, жилне тыйыб, дингезгя айткян: тынычлан, басыл, дигян. Жил туктаб, тыб-тыныч булган.

40 Аннары аларга айткян: сез ник алай куркыучан? ничек сезнен ышаныуыгыз жук? дигян.

41 Шунда бик куркышыб, бер-берсеня айтешкянняр: Бу кем? жил дя, дингез дя Аны тынґныйлар, дигянняр.

5-нче бюлем.

Зач. 19.

1 Аннары алар дингезнен ары жагындагы Гадара жиреня килгянняр.

2 Ул кимядян чыккач та, Анґар ўлек куя торган урыннан чыккан женне кеше очраган.

3 Ул каберляр эчендя тора икян; ич беряў дя аны чылбырга да бяйляб тота алмаган.

4 Кюб табкыр аны быгаулаб, чылбырлаб караганнар, äммя ул чылбырларын öзöб, быгауларын ыуатыб бетергян шул; шулай итеб аны тыярга беряўнен дя кöчö житмягян.

5 Ул жалан тöння дя, кöндöз дя таулар арасында, каберлярдя кычкырыб, ташларга бярелеб жöргян.

6 Ул Іисусны жырактын кюреб, жöгöрöб килеб, Аңар жыгылыб башырган.

7 Аннары каты тауыш белян кычкырыб äйткян: эй жугарыгы Алланын Улы Іисусъ! Синең миндя ней эшең бар? Алланы алыб Сиңа тилмерямен: мине азаблама, дигян.

8 Іисусъ аңар äйткян икян шул: эй шакшы тын! син бу кешедян чык диб.

9 Аннары: син ней атлы? диб сораган. Ул жауабка äйткян: мин легіонъ атлы, без (мында) кюб шул, дигян.

10 Алар Аңар: безне бу тирядян кыуыб жибярмясяня диб, бик ўтенгянняр.

11 Шунда тау кырыйында зур табын дунгыз кöтяляр икян.

12 Шакшы тыннар барысы да Аңар ўтенгянняр: безне дунгызлар эченя жибярче, без алар эченя керейек, дигянняр.

13 Шундук Іисусъ аларга бойорган. Шакшы тыннар чыгыб, дунгызлар эченя кергянняр; шул сяттюк кöтöў текя жардан дингезгя атылыб тöшкян, äммя алар ике меңняб икян, алар дингезгя батканнар.

14 Дунгыз кöтöўчеляре жöгöрöб кайтыб, калага да, ауылларга да белдергянняр; кешеляр ней булганны кюрергя чыкканнар.

15 Іисусъ катына килгяч, эчендя легіонъ торган женнянгян кешенен кейенеб, акыллы утырганын кюреб, алар бик куркышканнар.

16 Кюргян кешеляр женне кешегя ней булыу турысында, дунгызлар турысында да аларга äйткянняр.

17 Алар Іисуска: безнен тирядян китсяня диб, ўтеня башлаганнар.

18 Ул кимягя кергяч, жен азабландырган кеше Аннан Анын белян бергя жöрöргя сораган.

19 Äммя Іисусъ аңар бойормаган: Ул äйткян: син öйöңя ўзеңнекеляр жанына кайт та, Ходай сиңа ней кылганны, Ул сиңа изгелек иткянне аларга äйтеб бир, дигян.

20 Ул китеб, Іисусъ аңар ней кылганны ун кала (дигян жирдя) сöйляб жöрöй башлаган. Барысынында исляре киткян.

Зач. 20.

21 Іисусъ кимягя утырыб, тагы икенче жакка кичкяч, Анын жанына бик кюб калык жыйылган. Ул дингез жанында икян.

22 Мына синагога башлыкларынын берсе, Іаиръ атлы кеше килгян: ул Іисусны кюреб, Анын аягы астына жыгылыб,

23 Аңар бик ўтенеб äйткян: кызым ўляр чигендя жата, Син барыб анын öстöня кулларыңны салсана, ул сауыгыб, тере калсын ыйы, дигян.

24 Іисусь анын белян киткян.

Зач. 21.

25 Анын артыннан кюб калык барган, алар Аңар тыгыз иткянняр. Шунда ун ике жыл кан агыуы белян азабланган бер катын булган.

26 Ул кюб имчеляргя им иттереб, тик кюб азаб кна кюргян, бар нястясен таратыб бетереб, ич тя пайда табмаган, äммя бигеряк тя начарланган.

27 Ул Іисусъ турысында эшетеб, калык арасында артыннан килеб, Анын кейеменя тейенгян.

28 Ул äйткян икян: Анын кейеменя гня тейенсям дя сауыгырым диб.

29 Тейенеў белян анын кан агыуы туктаган; шундук тянендя чиреннян тöзялгянен тойган.

30 Шул сяття Іисусъ Ўзеннян кыуат чыкканны тойоб, калыкка боролоб äйткян: Минем кейемемя кем тейенде? дигян.

31 Öйрянеўчеляре Аңар äйткянняр: Ўзеңне калык тыгызлаганны кюря тороб, Миңа кем тейенде? диб äйтясен, дигянняр.

32 Äммя Ул мыны кылыучыны кюрмякче булыб, äйлянясеня караган.

33 Катын ўзеня ней булганны белеб, куркыб калтраб килгян дя, Анын алдында жыгылыб, Аңар бар дöрöсöн äйтеб биргян.

34 Іисусь аңар äйткян: кызым! сине ышаныуың коткарды, син тынычлык белян кит, инде чиреңнян сауыккан кöйö тор, дигян.

35 Ул мыны äйткян чакта, синагога башлыгыннан килеб äйткянняр: кызың ўлде, инде Öйрятеўчене нейгя öшяндерясен? диб.

36 Äммя Іисусъ бу сюзне эшеткяч тя, синагога башлыгына äйткян: курыкма, ышаныб кна тор, дигян.

37 Петръ белян Іаковтан башка, тагы Іаковъ энесе Іоаннан башка, Ул бютян бер кешегя дя Ўзе белян барырга кушмаган.

38 Синагога башлыгынын öйöня баргач, анда булган тамашаны, ўкереб жылаганны кюргян дя,

39 Кереб, аларга äйткян: ник тамашаланасыз? нейгя жылыйсыз? кыз ўлмягян ич, жоклой гна, дигян.

40 Алар Аннан кöлöшкянняр. Äммя Ул барысында чыгаргач, кызнын атасы белян анасын, тагы Ўзе белян бергя булганнарны алыб, кыз жата торган тöшкя кергян.

41 Кызны кулыннан тотоб, аңар айткян: талиѳа куми, дигян; бу: кызым, сиңа айтямен, тор дигян сюз була.

42 Кыз шул сяттюк торган да, жӧрӧй башлаган: кыз ун ике жяшендя икян. Андагыларнын исляре киткян.

43 Іисусъ аларга: бу эшне беряў дя белмясен диб, бик нык кисяткян, кызга ашарга бирегез, дигян.

6-нчы бюлем.

Зач. 22.

1 Аннан чыккач, Ул ўскян жиреня килгян; ӧйрянеўчеляре дя Анын белян барганнар.

2 Суббота житкяч, Ул синагогада ӧйрятя башлаган; эшетеўчелярнен кюбесе исляре китеб айткянняр: Аңар бу кайдан икян? Аңар нейдей белемнек бирелгян? Мындый кодрятляр Анын кулыннан ничек була?

3 Ул балта остасы тӧгӧл ме? Марія улы тӧгӧл ме? Іаковъ белян Іосіянын, Іуда белян Симоннын энесе тӧгӧл ме Ул? Анын туталары да мында безнен арадала баса, дигянняр. Шулай итеб, Анын турысында шик тотканнар.

4 Ӓммя Іисусъ аларга айткян: пагамбяр ўскян жирендяге кюк, туганнары арасындагы кюк, ӧйӧндяге кюк, бер жирдя дя кадерсез булмый, дигян.

5 Анда Аңар бер кодрят тя кыларлык булмаган, тик бер-ауык чирлелярнен ӧстӧня кулын салыб кна аларны сауыктырган.

6 Аларнын ышанмаганнарына исе киткян. Аннары айляня тирядяге ауылларда жӧрӧб ӧйряткян.

Зач. 23.

7 Аннары ун ике (ӧйрянеўчесен) чакырыб алыб, аларны икешяр, икешяр жибяря башлаган; аларга женнярне (жиңяргя) кыуат биргян.

8 Жулга таяктан бютян бер нястя дя, кабчык та, икмяк тя, эзярлярендя акча да алырга кушмаган;

9 Тик аякларына башмак кна кеяргя кушкан, ике кат кейем кеяргя дя кушмаган.

10 Аларга тагы айткян: бер-бер жирдя ӧйгя керсягез, аннан киткенче шул ӧйдя торогоз.

11 Ӓгяр кем дя кем сезне кабыл алмаса, сезне тыңнамаса, сез аннан чыкканда, аларга таныклыкка аякларыгыздагы тупракны селкеб тӧшӧрӧгӧз. Чыннаб айтямен сезгя: сорау кӧнӧндя Содомъ белян Гоморрга ул калага караганда жиңелеряк булыр, дигян.

12 Алар китеб, тяўбя итегез диб сӧйляб жӧргянняр.

13 Кюб женнярне кыуалаб чыгарганнар, кюб чирлеляргя май сӧртӧб тӧзяткянняр.

Зач. 24.

14 Іисусъ исеме даныккан буйынча, Иродъ падша Анын турысында эшетеб, айткян: бу Чумылдырыучы Іоаннъ ўлгян жиреннян терелеб торган, шуңар кюря ул кодрятляр дя кыла, дигян.

15 Бютянняр айткянняр: бу Иліядыр диб, кайсылары: бу пагамбяр, жя пагамбярлярнен кайсы булса да берсеня ошаулы, дигянняр.

16 Ӓммя Иродъ эшетеб, бу мин башын кистергян Іоанндыр, ул: ўлгян жиреннян терелеб торгандыр, дигян.

17 Шушы Иродъ ўз агасы Филиппъ катынын Иродіаданы ўзеня катын итеб, анын какында Іоанны тоттороб, бяйлятеб, ӧтӧрмянгя жабтырган икян;

18 Іоаннъ Иродка: сиңа агаң (Филиппнын) катынын ўзеңя катын итеб тororга жарамый диб айткялягян шул.

19 Иродіада Іоаннга ачыуы килеб, аны ўтертясе килгян, тик булдыра алмаган.

20 Иродъ Іоаннын гадел, изге кеше икянен белеб, аннан куркыб торган шул, аны саклаган, эшляренен кюбесен ул кушканча кылган, аны жаратыб тыңнаган.

21 Бер дя бер кӧннӧ Иродіадага кӧй килгян: Иродъ тыуган кӧнӧн искя алыб, ўзенен тюряляреня, мең кеше башлыкларына, Галилеядагы калык башлыкларына сый жасаган.

22 Шунда Иродіаданын кызы кергян дя, бейеб, Иродныn ўзенен дя, кунакларынын да кюңелен табкан. Падша кызга айткян: сорасың килгянне миннян сора, мин сиңа бирем, дигян.

23 Миннян ней гня сорасаң да, падшалыгымнын жартысын (сорасаң да) бирем сиңа диб аңар карганган.

24 Кыз чыгыб, анасына: ней соройом? дигян. Ул айткян: Чумылдырыучы Іоаннын башын (сора) дигян.

25 Кыз шундук падша катына жятляб кереб сораган: миңа Чумылдырыучы Іоаннын башын казерюк табакка салыб биргянеңне телейем диб.

26 Падша кайгыга тӧшкян; алайда карганганы буйынча, кунаклары алдында оятка калмас ӧчӧн, аңар бирмей калдырасы килмягян.

27 Шул сяттюк падша ўз сакчысын жибяреб, Іоаннын башын китерергя кушкан.

28 Ул барыб, ӧтӧрмяндя анын башын кисеб, аны табакка салыб китергян дя, кызга биргян, кыз аны анасына биргян.

29 Іоаннын ӧйрянеўчеляре эшетеб, килгянняр дя анын тянен алыб, кабергя куйганнар.

Зач. 25.

30 Апостоллар Іисусъ катына жыйылыб, ней кылганнарын, нейгя өйряткяннярен барысын да Аңар айтеб биргянняр.

31 Ул аларга айткян: сез ўзегез гня буш жиргя барыгыз да, бер-аз жал итегез, дигян. Килеўчеляр, китеўчеляр кюб булганныктан, аларга ашарга да багыт булмаган.

32 Алар ўзляре гня кимягя утырыб, буш жиргя киткянняр.

33 Калык алар киткянне кюргян, кюбесе аларны таныганнар. Бар калалардан да жяяўлеляр алар киткян жиргя жөгөрөб барганнар; алардан алдан барыб житеб, Іисусъ катына жыйылганнар.

34 Іисусъ чыгыб, кюб калыкны кюргян, алар көтөўчесез сарыклар кюк жөргянгя кюря, аларны кызганган. Аннары Ул аларны кюб өйряткян.

35 Байтак багыт ўткяч, өйрянеўчеляре Аңар килеб айткянняр: мында буш кыр, инде багыт та кюб ўтте;

36 Аларны жибяр, алар жакын тирядяге калаларга, ауылларга барыб, ўзляреня икмяк алсыннар, аларнын ашарларына бер дя жук шул, дигянняр.

37 Ул аларга жауаб биреб айткян: аларга ашарга сез бирегез, дигян. Алар Аңар айткянняр: без ўзебез барыб, ике жөз динарійгя икмяк алыб аларга ашарга бирейек меней? дигянняр.

38 Ул аларга айткян: сезнен ничя икмягегез бар? барыгыз, карагыз әле, дигян. Алар барыб белеб: биш икмяк белян, ике балык бар, дигянняр.

39 Аннары аларга барысында жяшел ўлям өстөня өйөр-өйөр утыртырга кушкан.

40 Рят сайын жөзяр кеше, иллешяр кеше утырганнар.

41 Биш икмяк белян ике балыкны алыб, кюккя таба караб, бахиллягян, аннары икмяклярне сындырыб, калыкка өляшергя өйрянеўчеляреня биргян. Ике балыкны да барысынада өляшкян.

42 Барысыда ашаб туйганнар.

43 Калган икмяк сыныкларын, балык кисяклярен ун ике карнаша тулук жыйганнар.

44 Икмяк ашаучылар ирляр гня биш меңняб булганнар.

Зач. 26.

45 Шул сяттюк Іисусъ, Ўзе калыкны жибяреб бетергенче, өйрянеўчеляреня кимягя утырыб, алдан ары жакка Виѳсаидага таба кичяргя кушкан.

46 Аларны жибяреб, Ўзе тау өстөня теляк итяргя менгян.

47 Кимя кич дингез уртасында булган, әммя Іисусъ жангызы гна жирдя калган.

48 Жил карышы булганныктан, аларга жӧзяргя читен икянен кюргян. Тӧннӧн дюртенче бюлемендя Ул алар катына дингез ӧстӧннян жяяўляб килгян, алар жаныннан ўтеб китясе булган.

49 Ӓммя алар Анын дингез ӧстӧннян жяяўляб килгянен кюреб, кеше шяўляседер бу диб, кычкыра башлаганнар.

50 Алар барысы да Аны кюреб, курыкканнар шул. Шул сяттюк Ул алар белян сӧйляшя башлаб аларга айткян: нык торогоз! бу Мин, курыкмагыз, дигян.

51 Аннары алар катына кимягя кереб утырган, шундук жил басылган; алар ўз эчлярендя бик жӧдяўгя калыб, исляре киткян.

52 Жӧрякляре таштый катыга кюря, алар икмякляргя ней булганны кюреб, анга килмягянняр.

53 Аннары аннан кичеб, Геннисаретъ жиреня килгянняр дя, жарга килеб туктаганнар.

Зач. 27.

54 Алар кимядян чыгыу белян, (ул жак кешеляре) Аны таныб,

55 Шундагы бар тирягя жӧгӧрӧшкянняр; Анын кайда икянен эшетеб, чирлелярне урыннары белян шунда алыб киля башлаганнар.

56 Ул кая гна барса да, ауылларга мы, калаларга мы, кечкеня гня ауылларга мы, чирлелярне бар тӧштя дя урамнарга чыгарыб салганнар; кейеменен кырыйына гна булса да тейенсеннярля диб Аӈар ўтенгянняр; Аӈар тейенгянняре сауыкканнар.

7-нче бюлем.

1 Іисусъ катына фарисейляр белян Іерусалимнян килгян князячелярнен кайсылары жыйылганнар.

2 Алар Анын ӧйрянеўчеляренен кайсылары жыумаган, тазартмаган кул белян икмяк ашаганны кюреб, аларны ӓрлягянняр.

3 Фарисейляр, Іудейляр барысыда картлар кушканны тотоб, кулларын жакшылаб жыумыйчы, икмяк ашамыйлар шул.

4 Базардан кайткач та жыуынмыйчы ашамыйлар. Тагы бютян тӧрлӧ кюб жолаларны да тоталар: табак-сауытларны, кружкаларны, казаннарны, урыннарны койондоралар.

Зач. 28.

5 Аннары фарисейляр белян князячеляр Аннан сораганнар: Синеӈ ӧйрянеўчелярең ней ӧчӧн картлар кушканны тотмойлар, ӓммя жыумаган кул белян икмяк ашыйлар? дигянняр.

6 Ул аларга жауаб биреб айткян: сез кюз алдында гна кылыныучылар турысында Исаія пагамбяр, жазыуда айтелгянчя, дӧрӧс айткян: бу кешеляр ауызлары белян Мине кадерлейляр, ӓммя кюнелляре Миннян жырак тора.

7 Кеше уйлаб чыгарган бойорокларга, кеше ӧйряткянгя ӧйрятеб, алар Мине бушка кадерлейляр диб.

8 Сез шу Алла бойорогон калдырыб, кеше кушканны тотасыз, кружкаларны жыуыу жоласын, тагы шуңар ошашлы бютян тӧрлӧ (эшляр дя) кюб кыласыз, дигян.

9 Аларга тагы äйткян: картларыгыз кушканны тотар ӧчӧн, Алла бойорогон калдырыуыгыз жакшы мы?

10 Моисей äйткян ич: атаңны санна; тагы: атасына, анасына жаман äйтеўче ўтерелсен, дигян.

11 Äммя сез äйтясез: атасына, жя анасына: мин сиңа бирясе нястя корванъ дейеўче, (корванъ дигяне Аллага бюляк дейеў),

12 Ўз атасына, жя анасына бер дя булышмаса да жарый дейсез.

13 Шулай итеб, сез картларыгыз кушканны кыларга куйыуыгыз белян Алла сюзен чиття калдырасыз; шунын кюк бютян тӧрлӧ (эшляр дя) кюб кыласыз, дигян.

Зач. 29.

14 Аннары Ул бар калыкны чакырыб алыб äйткян: Мине барыгыз да тыңнагыз да аңнаб алыгыз.

15 Кешене тыштан кергян ич-бер нястя шакшыландыра алмый, äммя эченнян чыкканы кешене шакшыландыра.

16 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

17 Ул калык жаныннан ӧйгя кергяч, ӧйрянеўчеляре Аннан мясял турысында сораганнар.

18 Ул аларга äйткян: äле сез дя шулай аңнамыйсыз меней? кешене тыштан кергян ич-бер нястя шакшыландыра алмаганны аңыша алмыйсыз меней?

19 Ул анын кюңеленя кермей ич, äммя карынына керя, аннары тышка чыга, шунын белян äр-бер ашамнык тазара, дигян.

20 Тагы äйткян: кешенен эченнян чыкканы кешене шакшыландыра:

21 Эчтян, кеше кюңеленнян усал уйлар, азгыннык итеў, уйнашлык, кеше ўтереў,

22 Урлау, малга биренеў, жаманнык итеў, жумачылык, оятсызлык, кюремсез кюз, Алланы курлау, олосомаклык, акылсызлык чыга шул.

23 Бу усаллыклар барыда эчтян чыгалар, шулар кешене шакшыландыралар, дигян.

Зач. 30.

24 Аннары аннан китеб, Тиръ белян Сидонъ тиряляреня барган; анда бер ӧйгя кереб, Ўзен беряўгя дя белдерясе килмягян, алайда жяшерен кала алмаган.

25 Анын турысында бер женнянгян кызлы катын эшеткян; ул килеб, Анын аягы астына жыгылыб башырган.

26 Бу катын жалган денне тотоучы булган, ул Сирофиникія жиренеке икян; ул Аңар: кызым эченнян женне чыгарсана диб инялгян.

27 Äммя Іисусъ аңар айткян: элеке балалар ашаб туйсыннар; икмякне балалардан алыб, этляргя ташлауы жакшы тöгöл шул, дигян.

28 Катын Аңар жауаб биреб айткян: анысы дöрöс, эй Ходай! алайда этляр дя öстял астында балаларнын ыуалчыкларын ашыйлар ич, дигян.

29 Ул аңар айткян: бу сюзең öчöн, бар кайт, кызың эченнян инде жен чыкты, дигян.

30 Öйöня кайткач, ул кызынын жене чыгыб, кызы урын öстöндя жатканны кюргян.

Зач. 31.

31 Тиръ белян Сидонъ тиряляреннян чыгыб, Іисусь ун кала (дигян жир) арткылы тагы Галилея дингезе жанына килгян.

32 Шунда Аңар бер саңрау, сакау кешене алыб килгянняр дя анын öстöня кулыңны салсана диб, Аңар инялгянняр.

33 Іисусъ аны калыктан читкяряк алыб китеб, анын колакларына бармакларын тыгыб, тöкöрöб, анын теленя тейенгян дя,

34 Кюккя таба караб, эчтян сулыб, аңар айткян: еффаѳа, дигян, еффаѳа дигяне ачыл дигян сюз.

35 Шул сяттюк анын колаклары ачылган, теленен бяйе чишелеб, ул чиста сöйляшя башлаган.

36 Іисусъ аларга мыны беряўгя дя айтергя кушмаган. Тик аларга Ул ней хатле кисятся дя, алар бигеряк тя жяйелдергянняр.

37 Бик исляре киткян: барын да жакшы кыла, саңрауларны эшетя торган итя, телсезлярне сöйляшя торган итя, дигянняр.

8-нче бюлем.

Зач. 32.

1 Шул кöннярдя калык бик кюб жыйылыб, аларнын ашарларына бер нястя дя булмагач, Іисусъ Ўз Öйрянеўчелярен чакырыб алыб, аларга айткян:

2 Мин бу калыкны кызганамын, алар Минем катымда инде öч кöннян бирле торалар, аларнын ашар нястяляре дя жук.

3 Äгяр аларны öйляреня ач кöйö жибярсям, аларнын жулда халляре бетяр, аларнын кайсылары жырактын килгянняр шул, дигян.

4 Öйрянеўчеляре Аңар жауаб биргянняр: мында буш кырда аларны туйдырырлык икмяк каян аласы? дигянняр.

5 Ул алардан: сезнен ничя икмягегез бар? диб сораган. Алар: жидяў, дигянняр.

6 Ул аннары калыкка жиргя утырырга кушкан, кушкач, жиде икмякне алыб, (Аллага) тау иткян дя сындырыб, ӧйрянеӱчеляреня калыкка ӧляшергя биргян; алар ӧляшкянняр.

7 Аларнын тагы бер-аз балыклары да бар икян; Ул бахилляб аларны да ӧляшергя кушкан.

8 Барысыда ашаб туйганнар; калган сыныкларны жиде карнаша жыйганнар.

9 Ашаучылар дюрт меӊняб булганнар. Аннары аларны жибяргян.

10 Ӱзе шундук ӧйрянеӱчеляре белян кимягя утырыб, Далманувөа тиряляреня килгян.

Зач. 33.

11 Шунда фарисейляр килеб, Анын белян жиӊешя башлаганнар; Аны сынаб, безгя кюктян билге кюрсят, дигянняр.

12 Ул эчтян сулыб айткян: бу тыума нейгя билге сорой? Чыннаб айтямен сезгя: бу тыумага билге бирелмяс, дигян.

13 Аннары аларны калдырыб, жяня кимягя утырыб, икенче жакка кичкян.

14 Шул чакта Анын ӧйрянеӱчеляре икмякляр алырга онотканнар, кимядя Ӱзляре белян бергя бер гня икмякляре булган.

15 Ӓммя Ул аларга кисятеб айткян: карагыз, фарисейляр ӓчеткеченнян, Иродъ ӓчеткеченнян сакланыгыз, дигян.

16 Алар ӱз аралый: икмякляребез жукны айтеӱедер диб уйлашканнар.

17 Iисусъ мыны белеб, аларга айткян: ник сез икмякляребез жук диб уйлыйсыз? Ӓле дя тоймойсыз меней? ӓле дя аӊыша алмыйсыз меней?

18 Кюӊелегез таштый кӧйӧ меней? Кюзлярегез булыб та кюрмейсез ме? колакларыгыз булыб та эшетмейсез ме? исегездя тӧгӧл меней?

19 Мин биш икмякне биш меӊ кешегя сындырыб ашаткач, сыныклар жыйыб ничя карнаша тутырдыгыз? дигян. Алар Аӊар ун икене, дигянняр.

20 Тагы жиде икмякне дюрт меӊ кешегя (сындырыб биргяч), калган сыныкларны ничя карнаша жыйдыгыз? дигян. Алар: жидене, дигянняр.

21 Шуннан суӊ аларга айткян: сез ничек аӊнамыйсыз? дигян.

Зач. 34.

22 Аннары Iисусъ Вивөсаидага килгян; шунда Аӊар бер сукыр кешене китереб, мыӊар тейенсяня диб ӱтенгянняр.

23 Ул сукырны кулыннан тотоб, аны ауылдан житякляб чыгарган да анын кюзляреня тӧкӧрӧб, аӊар кулларын салыб, аннан: бер-бер нястя кюрясен ме? диб сораган.

24 Ул караб караган да: узыб бара торган кешелярне агачлар кюк кня кюрямен, дигян.

25 Аннары тагы кулларын анын кюзляреня куйыб, аҥар: кара, дигян. Ул тӧзялеб, бар нястяне дя айырмачык кюря башлаган.

26 Аннары аны ӧйӧня былай йтеб жибяргян: бу ауылга кермя, ауылда беряӱгя дя сӧйляшмя, дигян.

Зач. 35.

27 Аннары Іисусъ Ӱз ӧйрянеӱчеляре белян Филиппъ Кесаріясенен ауылларына барган. Жулда чагында Ул ӧйрянеӱчеляреннян сораган: кешеляр Мине кем диб айтяляр? дигян.

28 Алар жауаб биргянняр: Чумылдырыучы Іоаннъ диб, кайсылары Илія диб, ӓммя кайсылары пагамбярлярнен берседер диб айтяляр, дигянняр.

29 Ул аларга ӓйткян: сез ӱзегез Мине кем диб белясез? дигян. Петръ Аҥар жауаб биреб ӓйткян: Син Христосъ, дигян.

Зач. 36.

30 Іисусь аларга Ӱзе турысында беряӱгя дя ӓйтергя кушмаган.

31 Аннары Ул аларны: Ӓдям Улы кюб азаб кюрясе диб, калык башлыклары, архіерейляр, княгячеляр Аны кабыл алмаслар, Аны ӱтерерляр диб, Ул ӧчӧнчӧ кӧннӧ терелеб торор диб, ӧйрятя башлаган. Ул бу турда айырмачык ӓйткян.

32 Петръ Аны читкяряк алыб китеб, Аҥар кире кагыб, ӓйтя башлаган.

33 Ӓммя Ул боролоб, ӧйрянеӱчеляреня таба караб, Петрны туктатыб ӓйткян: кит Миннян шайтан, син шу Аллага жараганны уйламыйсын, ӓммя кешегя жараганны (уйлыйсын), дигян.

34 Аннары ӧйрянеӱчеляре белян калыкны чакырыб, аларга ӓйткян:

Зач. 37.

Миҥа эярясе килгян кеше, ӱз иркен кылыуны ташласын да качын алыб, Минем артымнан барсын.

35 Жанын сакласы килгян кеше, аны жуяр шул, ӓммя жанын Минем ӧчӧн, Евангеліе ӧчӧн жуйган кеше, аны саклар.

36 Кеше бӧтӧн дӧньяне жыйыб алса да, ӓммя ӱз жанына зыян китерся, аҥар ней пайда булыр?

37 Жя кеше ӱз жанын ней биреб жола алыр?

38 Кем дя кем шушы жазыклы, азгын тыума арасында Миннян, жя сюзляремнян оялса, Ӓдям Улы да Ӱз Атасынын ололигонда арыу пяриштяляр белян бергя килгяч, аннан оялыр, дигян.

9-нчы бюлем.

1 Ул аларга айткян: чыннаб айтямен сезгя: мында тороучыларнын кайсылары, Алла Падшалыгынын кодрят белян килгянен кюрмейче, ӱлмясляр, дигян.

Зач. 38.

2 Аннары алты кӧн ӱткяч, Іисусъ Петрны, Іаковны, Іоанны алыб китеб, аларны гна алыб бейек тау ӧстӧня менгян; Ул анда алар алдында ӱзгяргян.

3 Кейемняре жалтраб торган, кар кюк бик ак булган, жир ӧстӧндяге бер агартыучы да алай агарта алмас.

4 Шунда аларга Илія белян Моисей кюренеб, Іисусъ белян сӧйляшеб торганнар.

5 Шул чакта Петръ Іисуска айткян: эй Ӧйрятеӱче! безгя мында тороргa жакшы; ӧч чатыр коройокчы: берсен Сиңа, берсен Моисейгя, берсен Иліягя, дигян.

6 Ул ней айткянен дя белмей калган, алар бик курыкканнар шул.

7 Шундук аларны болот килеб кюлягялягян: болоттан: Шушы Минем сӧйӧклӧ Улым, Аны тыңнагыз диб ауаз килгян.

8 Алар кинят айлянялареня карангач, ӱзляре белян Іисустан бютянне беряӱне дя кюрмягянняр.

9 Тау ӧстӧннян тӧшкян чакта, Ул аларга кюргянняреn, Ӓдям Улы ӱлгян жиреннян терелеб торгончы, беряӱгя дя айтергя кушмаган.

Зач. 39.

10 Алар бу сюзне ислярендя тотоб, ӱлгян жирдян терелеб тороу ней икян диб бер берсеннян сорашканнар.

11 Аннары алар Іисустан сораганнар: бу ничек княгячеляр элеке Илія килясе дейляр?

12 Ул аларга жауаб биреб айткян: дӧрӧс, Илія элеке килеб, барын да рятляргя тейеш; Ӓдям Улы да, Ӱз турысында жазылганча кюб азабланырга, кимсетелергя тейеш.

13 Ӓммя Мин сезгя айтямен: Илія инде, анын турысында жазылганча, килде; аңар телягянняреn кылдылар, дигян.

14 Аннары ӧйрянеӱчеляре катына килеб, алар айлянясендя кюб калыкны кюргян; княгячеляр ӧйрянеӱчеляре белян жиңешкянне кюргян.

15 Шул сяттюк Аны кюреб, бар калыкнын исе киткян; жӧгӧрӧб килеб, Анын белян кюрешкянняр.

16 Ул княгячелярдян сораган: алар белян ней турысында жиңешясез? дигян.

Зач. 40.

17 Калык арасыннан беряӱ жауаб айткян: эй Ӧйрятеӱче! мин Сиңа телсез тынны улымны китергян эйем.

18 Кайда гна тотса да, ул аны жиргя жыга; ул тешлярен шыкырдатыб, кюбек чыгара, катыб китя; мин ӧйрянеӱчеляреңя: ул тынны кыуыб чыгарыгыз дигян эйем, тик алар булдыра алмадылар, дигян.

19 Іисусъ аңар жауаб биреб айткян: эй ышаныусыз тыума! кайчанга чаклы сезнен белян торойом? кайчанга чаклы сезгя чыдыйым? аны Миңа китерегез, дигян.

20 Аннары аны Аңар китергянняр. Тын Аны кюреӱ белян, чирлене калтраткан; ул жиргя жыгылган да, кюбеген чыгарыб, аунаб жаткан.

21 Іисусъ анын атасыннан сораган: мыңар былай булыуы кюбтян ме? дигян. Ул: баладанук, дигян.

22 Тын аны бетерер ӧчӧн, кюб табкыр утка, сыуга ыргыткалады; ӓгяр Син бер-бер нястя кыла алсаң, безне кызганыб, безгя булыша кюр, дигян.

23 Іисусъ аңар айткян: ӓгяр син ӓз гня ышана алсаң да, ышаныучыга барын да кыларга мӧңким, дигян.

24 Шул сяттюк жегет атасы жылаб кычкырыб айткян: ышанамын эй Ходай! ышанмаганыма булыша кюр, дигян.

25 Іисусъ калык жыйылганны кюреб, шакшы тынга кисятеб айткян: эй телсез, саңрау тын! Мин сиңа кушам, аннан чык, инде мыннан былай аңар кермя диб.

26 Ул шундук аны каты калтратыб, кычкырыб чыккан; жегет ӱлгян кюк булган; кюбесе ӱлде инде ул дигянняр.

27 Ӓммя Іисусъ кулыннан тотоб, аны кютяргян, ул торган.

28 Іисусъ ӧйгя кергяч, ӧйрянеӱчеляре аулакта Аннан сораганнар: без аны ник чыгара алмадык икян? дигянняр.

29 Ул аларга айткян: бу затны тик теляк белян ураза арткылы гна чыгарырга мӧңким, дигян.

30 Аннан чыгыб, алар Галилея арткылы ӱтеб барганнар. Іисусъ Ӱзен беряӱгя дя белдертясе килмягян,

31 Ул шу ул чагында ӧйрянеӱчелярен ӧйрятеб, аларга айткян: Ӓдям Улы кешеляр кулына тотоб бирелер, Аны ӱтерерляр, ӱтергяч, ӧчӧнчӧ кӧнӧндя терелеб торор, дигян.

32 Тик алар бу сюзлярне аңнамаганнар, ӓммя Аннан сорарга курыкканнар.

Зач. 41.

33 Капернаумга килгяч, бер ӧйдя чагында, Ул алардан сораган: сез жулда ўз аралый ней турысында исябляштегез? дигян.

34 Алар дяшмягянняр, жулда ўз аралый кем олорак диб сӧйляшкянняр икян шул.

35 Утыргач, ун икесен дя чакырыб алыб, аларга айткян: кемнен оло буласы киля, ул барысыннанда кече булсын, барысынада кызмятче булсын, дигян.

36 Аннары бер баланы алыб, аны урталарына торгозоб, аны кочаклаб, аларга айткян:

37 Кем Минем исемемя шушындый балаларнын берсен кабыл алса, ул Мине кабыл ала; Мине кабыл алыучы, Мине кабыл алмый, äммя Мине Жибяреўчене (кабыл ала), дигян.

38 Шунда Іоаннъ Аӈар айткян: эй Ӧйрятеўче! без Синеӈ исемеӈ белян женнярне кыуалаб чыгарыучы кешене кюрдек, äммя ўзе безгя эяреб жӧрмягянгя кюря, без аны туктаттык, дигян.

39 Іисусъ айткян: аны туктатмагыз: Минем исемем белян кодрят кылган кеше, беряў дя Мине тизюк жаманный алмас.

40 Сезгя карышы тӧгӧл кеше, сезнен жаклы шул.

41 Кем дя кем Минем исемемя, сез Христосныкылар диб, сезгя бер сауыт сыу эчерся, чыннаб айтямен сезгя: ул сауабын алмый калмас, дигян.

Зач. 42.

42 Кем дя кем шушы Миӈа ышаныучы кечкенялярнен берсен алдандырса, аӈар муйнына тегермян ташы асыб, аны дингезгя ташласалар жакшырак булыр ыйы.

43 Äгяр сине кулыӈ алдандырса, син аны кисеб ташла: сиӈа сыӈар куллы кӧйӧ терелеккя кереўе, ике кулыӈ белян тамукка, сюнмей торган утка китеўдян жакшырак ич.

44 Анда аларнын кортлары да ўлмей, утлары да сюнмей.

45 Äгяр сине аягыӈ алдандырса, аны кисеб ташла: сиӈа аксак кӧйӧ терелеккя кереўе, ике аяк белян тамукка, сюнмей торган утка ташланыудан жакшырак ич.

46 Анда аларнын кортлары да ўлмей, утлары да сюнмей.

47 Äгяр сине кюзеӈ кызыктырса, син аны сыуырыб ал: сиӈа сыӈар кюз белян Алла Падшалыгына кереўе, ике кюзеӈ белян тамук утына ташланыудан жакшырак ич.

48 Анда аларнын кортлары да ўлмей, утлары да сюнмей.

49 Äр-кем ут белян тозланыр, äр-бер корман да тоз белян тозланыр шул.

50 Тоз жакшы нястя; ӓгяр тознон тозлолого булмаса, аны ней белян тӧзятерсез? Ӱзегездя тоз булсын, ӱз арагызда татыулык булсын, дигян.

10-нчы бюлем.

1 Аннан киткяч, Іисусъ Іорданнын ары жагыннан ӱтеб Іудея тиряляреня килгян. Анын катына тагынук калык жыйылган, Ул Ӱз жоласынча аларны тагы ӧйряткян.

Зач. 43.

2 Фарисейляр жакын килеб, Аннан сынаб сораганнар: иргя катынын айырырга мӧҥким ме? дигянняр.

3 Ул аларга жауаб биреб ӓйткян: Моисей сезгя ней бойорган? дигян.

4 Алар ӓйткянняр: Моисей (катынга) айырыу жазыуын жазыб, айырыб жибярергя роксят иткян, дигянняр.

5 Іисусъ аларга жауаб биреб ӓйткян: кюҥелегез катыга кюря, ул сезгя бу бойорокны жазган.

6 Баш булдырыудук Алла аларны ирле катынны иткян.

7 Шуҥар кюря кеше ӱз атасын, анасын калдырыр да,

8 Ӱз катынына кушылыр, аннары икесе бер тян булырлар; шунныктан алар инде икяӱ тӧгӧл, ӓммя бер тян.

9 Алай булгач, Алла кушылдырганны кеше айырмасын, дигян.

10 Ӧйдя ӧйрянеӱчеляре бу турыда тагы сораганнар.

Зач. 44.

11 Ул аларга ӓйткян: кем ӱз катынын айырыб, бютян катын алса, ул катыны ӧстӧннян уйнашлык итя.

12 Ӓгяр катын да ӱз иреннян айырылыб, бютян иргя кится, ул да уйнашлык итя, дигян.

13 Аҥар балаларны китергянняр, Ул аларга тейенсен диб, ӓммя ӧйрянеӱчеляре китереӱчелярне жибярмей торганнар.

14 Мыны кюргяч, Іисусъ сукыраныб, аларга ӓйткян: балаларга Миҥа килергя ирек итегез, аларны туктатыб тормагыз, Алла Падшалыгы шундыйларныкы шул.

15 Чыннаб ӓйтямен сезгя: кем Алла Падшалыгын бала кюк кабыл алмаса, ул анда кермяс, дигян.

16 Аннары аларны кочаклаб, ӧстляреня кулын салыб, аларны бахиллягян.

Зач. 45.

17 Іисусъ жулга чыккан чакта, беряӱ жӧгӧрӧб килеб, алдында тезлянеб тороб, Аннан сораган: эй изге Ӧйрятеӱче! мянге тормошка урыннашыр ӧчӧн, мин ней кылыйым? дигян.

18 Іисусъ аҥар ӓйткян: ник син Мине изге диб ӓйтясеҥ? Беряӱ дя изге тӧгӧл, тик бер Алла гна (изге).

19 Бойорокларны белясен: уйнашлык итмя, ӳтермя, урлама, жалган таныклык итмя, читлямя; атанҥы, ананҥы санна, дигян.

20 Ул Анҥар жауаб биреб айткян: эй Ӧйрятеӳче! мин быларны барысында жяштянюк тоттом, дигян.

21 Іисусъ анҥар караб, аны жаратыб, анҥар айткян: синҥа бер гня нястя житмей: бар, нейеҥ бар барысында сат та, жарлыларга ӧляш, синеҥ малыҥ кюктя булыр: аннары кил дя, качны алыб, Минем артымнан жӧр, дигян.

22 Ул бу сюздян жӧдяӳгя калыб, кайгырыб, аннан киткян, анын малы кюб икян шул.

23 Аннары айлянясеня караныб, Іисусъ Ӱз ӧйрянеӳчеляреня айткян:

Зач. 46.

Байларга Алла Падшалыгына кереӳе ничек читен! дигян.

24 Ӧйрянеӳчеляре Анын сюзляреннян абтраб киткянняр. Ӓммя Іисусъ аларга жауабка айткян: эй балалар! байлыкка ышаныб тороучыларга Алла Падшалыгына кереӳе ничек читен!

25 Бай кешегя Алла Падшалыгына кереӳдян дӧягя иня кюзеннян ӳтеӳе асатрак, дигян.

26 Алар уза исляре китеб, ӳз аралый: айсаҥ кем котола алыр диб? сӧйляшкянняр.

27 Іисусъ аларга караб айткян: кешеляргя бу мӧнҥким тӧгӧл, ӓммя Аллага барда мӧнҥким шул, дигян.

28 Аннары Петръ Анҥар айтя башлаган: мына без барында калдырыб, Синҥа эярдек, дигян.

29 Іисусъ жауаб биреб айткян: чыннаб айтямен сезгя: Минем ӧчӧн, Евангеліе ӧчӧн, ӧйӧн, жя ага-энелярен, жя тута-сеҥнелярен, жя атасын, жя анасын, жя катынын, жя балаларын, жя жирен-сыуын калдырган кеше беряӳ дя,

30 Ӓле шушы кысанныкларда торган чакта, ӧйляр, ага-энеляр, тута-сеҥнеляр, аталар, аналар, балалар, жир-сыулар жӧз ӧлӧш артык алмый калыучы жук, ӓммя буласы гумердя мянге тормошны алмый калмас.

31 Алдагылар кюбесе артта булырлар, ӓммя арттагылар алда булырлар, дигян.

32 Іерусалимгя менеб барган чакта, жулда Іисусъ ӧйрянеӳчеляре алдыннан барган, ӓммя алар Анын артыннан котлары чыгыб, куркышыб барганнар.

Зач. 47.

Ун ике (ӧйрянеӳчесен) чакырыб алыб, Ӱзеня ней буласыны аларга тагы сӧйлӧй башлаган:

33 Мына без Іерусалимгя менеб барабыз; анда Ӓдям Улын архіерейляргя, князячеляргя тотоб биререляр; Аны ӱтерергя хокӧм итярляр; Аны жалган деннеляргя тотоб биререляр;

34 Аннан мыскыл итярляр, Аны кыйнарлар, Аңар тӧкӧрӧб тутырырлар, Аны ӱтерерляр, Ул ӧчӧнчӧ кӧнӧндя терелеб торор, дигян.

35 Шул чакта Зеведей уллары Іаковъ белян Іоаннъ Аңар килеб айткянняр: эй Ӧйрятеӱче! без сорасыны Син безгя кылсаң ыйы диб телейбез, дигянняр.

36 Ул аларга айткян: Мин сезгя ней кылганны телейсез? дигян.

37 Алар Аңар: Ӱз ологонда безнен беребезне уң жагыңа, икенчебезне сул жагыңа утыртсана дигянняр.

38 Іисусь аларга айткян: ней сораганыгызны ӱзегез белмейсез. Мин эчя торган сауыттагын эчя алырсыз мы? Мин чумыла торган чумылыу белян чумыла алырсыз мы? дигян.

39 Алар жауаб биргянняр: алырбыз, дигянняр. Іисусъ аларга айткян: Мин эчя торган сауыттагын эчярсез, Мин чумыла торган чумылыу белян дя чумылырсыз,

40 Ӓммя Ӱземнен уң жагыма, жя сул жагыма утыртыу Минем иркемдя тӧгӧл, тик кемгя ӓзерлягян, шул (утырыр), дигян.

41 Мыны эшетеб, унысы Іаковъ белян Іоанны жаратмаганнар.

42 Іисусъ аларны чакырыб алыб, аларга айткян: калыкларнын тюряляре аларны биляб торганны, ололары аларны ӱз кул астларында тотканны сез белясез.

43 Сезнен арагызда алай булмасын: сезнен арада кем олорак буласы кился, ул сезгя кызмятче булсын;

44 Кем сезнен арада баш буласы кился, ул барысына да кол булсын.

45 Шулай, Ӓдям Улы да Ӱзеня кызмят иттерер ӧчӧн килмяде, ӓммя Ӱзе кызмят итяр ӧчӧн, кюб (кешелярне) жолар ӧчӧн, Ӱз жанын бирергя (килде), дигян.

Зач. 48.

46 Аннары Іерихонга килгянняр. Ул ӧйрянеӱчеляре белян, кюб калык белян Іерихоннан чыккан чакта, Тимей улы сукыр Вартимей жул буйында сораныб утырган.

47 Бу Назорей Іисусъ дигянне эшеткяч, ул: эй Давидъ Улы Іисусъ! мине жарлыка диб кычкыра башлаган.

48 Кюбесе аңар кычкырырга кушмаганнар; ӓммя ул: эй Давидъ Улы! мине жарлыка диб бигеряк тя нык кычкыра башлаган.

49 Іисусъ туктаб, аны чакырырга кушкан. Сукырны чакырыб, аңар айткянняр: курыкма, тор, сине чакыра, дигянняр.

50 Ул ӧст кейемен салган да, тороб, Іисусъ катына килгян.

51 Іисусъ аңар жауабка айткян: Мин сиңа ней кылганны телейсен? дигян. Сукыр Аңар айткян: эй Ӧйрятеӳче! кюря торган булсам ыйы, дигян.

52 Іисусъ аңар айткян: бар, ышаныуыҥ сине коткарды, дигян. Ул шул сяттюк кюря башлаган; аннары жул белян Іисуска эяреб киткян.

11-нче бюлем.

Зач. 49.

1 Іерусалимгя, Елеонъ тауына, Виѳсфагія белян Виѳанія атлы ауылларга жакыннашкач, Іисусъ Ӳзенен ике ӧйрянеӳчесен жибяреб,

2 Аларга айткян: шушы алдыгыздагы ауылга барыгыз: анда кереӳ белян тизюк, бер кеше дя атланмаган, бяйляб куйган жяш ишякне очратырсыз; аны чишеб, алыб килегез.

3 Ӓгяр беряӳ сезгя: ней эшлейсез? дися, сез: Ходайга киряк диб жауаб бирегез, ул шундук аны биреб жибярер, дигян.

4 Алар барыб, урамда, кабка тӧбӧндя бяйляб куйган жяш ишякне очратканнар да аны чишеб алганнар.

5 Анда тороучыларнын кайсылары аларга айткянняр: ней эшлейсез? ник ишяк колонон чишясез? дигянняр.

6 Ӧйрянеӳчеляр аларга Іисусъ кушканча айткянняр, айткяч аларны жибяргянняр.

7 Жяш ишякне Іисусъ катына алыб килгянняр дя анын ӧстӧня кейемнярен жяйгянняр. Іисусъ анын ӧстӧня атланган.

8 Кюбесе кейемнярен жулга жяйеб барганнар; кайсылары агач ботакларын кисеб алыб, жулга тюшяб барганнар.

9 Алдан барыучылар да, арттан килеӳчеляр дя былай кычкырганнар: Осанна! Ходай исеменя Килеӳче даннаулы!

10 Атабыз Давиднын Ходай исеменя киля торган падшалыгы даннаулы! эй жугарыдагы Осанна! диб.

Зач. 50.

11 Іисусъ Іерусалимгя килеб, чиркяӳгя кергян; анда барында караб бетергяч, кич булганга кюря, ун ике (ӧйрянеӳчесе) белян Виѳаніяга киткян.

12 Икенче кӧннӧ алар Виѳаніядян чыккач, Анын ашасы килгян.

13 Жапраклы смоква агачын жырактын кюреб, анда бер-бер нястя очратмам мы диб, (анын жанына) барган; тик барыб, анда жапрактан бютян бер нястя дя табмаган, ул чакта смоква багыты тӧгӧл икян шул.

14 Іисусъ аңар айткян: мыннан былай гумергя синнян беряӳ дя жимеш ашамасын! дигян. Мыны ӧйрянеӳчеляре эшеткянняр.

15 Аннары Іерусалимгя килгянняр. Іисусъ чиркяӳгя кереб, чиркяӳдя сатыу итеӳчелярне, алыучыларны кыуа башлаган; акча

алыштырыучыларнын öстяллярен, кюгярчен сатыучыларнын скямьяларен аударыб бетергян.

16 Чиркяӳ арткылы бер нястя дя алыб жöрöргя кушмаган.

17 Аларны öйрятеб айткян: Минем öйöм бар калыкларга да теляк öйö диб аталыр диб жазылмаган меней? äммя сез аны талаучылар оясы иткянегез дигян.

18 Мыны князячеляр белян архіерейляр эшетеб, Аны ничек булса да бетерергя кöй эзлей башлаганнар; Анын öйрятеӳеня бар калыкнын да исе киткянгя кюря, Аннан курыкканнар.

19 Кич булгач, Ул каладан чыгыб киткян.

20 Иртя белян узыб барышлый, смоква агачынын тамырына чаклы короб беткянен кюргянняр.

21 Петръ исеня тöшöрöб, Аңар айткян: эй Öйрятеӳче! кара, Син каргаган смоква агачы короган, дигян.

22 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян:

Зач. 51.

23 Аллага ышаныулыкны нык тотогоз. Чыннаб айтямен сезгя: äгяр кем ӳз кюңелендя шиклянмейче, айткянемчя булыр диб ышаныб, шушы тауга: кютярелеб, дингезгя атыл дися, ул дигянчя булыр.

24 Шунныктан сезгя айтямен: телягегездя ней гня сорасагыз да, алырыгызга ышаныгыз, ышаныуыгызча сезгя булыр.

25 Теляктя торган чакта, кюктяге Атагыз сезгя жазыкларыгызны кичерсен дисягез, беряӳгя-беряӳгя ӳпкягез булса, кичерегез.

26 Äгяр сез кичермясягез, кюктяге Атагыз да сезгя жазыкларыгызны кичермяс, дигян.

Зач. 52.

27 Кабат тагы Іерусалимгя килгянняр. Ул чиркяӳ эчендя жöргян чакта, Анын катына архіерейляр, князячеляр, калык башлыклары килеб,

28 Аңар айткянняр: Син мыны кем бойороуы белян кыласын? Мыны кыларга Сиңа кыуат кем бирде? дигянняр.

29 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: Мин дя сездян бер турда соройом, Миңа жауаб бирегез, Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны айтермен.

30 Іоаннын чумылдырыуы кюктян булды мы, äлля кешелярдян ме? Миңа жауаб бирегез, дигян.

31 Алар ӳз аралый уйлаганнар: äгяр кюктян дисяк, Ул безгя: ник суң аңар ышанмадыгыз? дирер;

32 Äммя кешелярдян дирергя, калыктан курыкканнар: Іоанны барда чын пагамбяргя санаганнар шул.

33 Шунныктан Іисуска жауаб биреб айткянняр: белмейбез, дигянняр. Іисусъ та аларга жауаб биреб айткян: Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны айтмям, дигян.

12-нче бюлем.

Зач. 53.

1 Аннары Іисусъ аларга мясалляр китереб айтя башлаган: бер кеше жöзöм агачлары утыртыб, айлянясен койма белян айляндергян, эчендя (жöзöм сыуын) агызгыч жасаган, башня торгозган, аннары аны бакчачыларга табшырыб, киткян.

2 Багыт житкяч, бакчачылардан бакчадагы жöзöм жимешен алырга, бакчачылар катына кызмятчесен жибяргян.

3 Äммя алар аны тотоб, кыйнаганнар да, бер дя бирмей жибяргянняр.

4 Ул аларга тагы икенче кызмятчене жибяргян; анысынын да башын таш атыб тишкянняр дя, кадерсез итеб жибяргянняр.

5 Ул тагы бютянне жибяргян. Анысын да ӱтергянняр; бютянняренен дя кюбесен жя кыйнаганнар, жя ӱтергянняр.

6 Анын бик сöйгян бер гня улы бар икян; улымнан оялырлар диб калдыгында ул аларга ӱз улын жибяргян.

7 Äммя бакчачылар бер берсеня айткянняр: бу атасы урнына каласы; айдягез, ӱтерейек аны, аннары аңар каласы мал безнеке булыр, дигянняр.

8 Аны тотоб ӱтергянняр дя бакчадан чыгарыб ташлаганнар.

9 Бакча эясе инде ней кылар? Ул килеб, бакчачыларны ӱтертер дя бакчаны бютянняргя бирер.

10 Мыны сез укымадыгыз меней: öй салыучылар жараусыз кюреб ташлаган таш почмак астына нигез булган,

11 Ходайдан булган бу, безнен кюз алдыбызда ис китярлек дигянне?

12 Шунда Аны тотоб алмакчы булганнар, тик калыктан курыкканнар: мясалне алар турысында айткянне аңнаганнар. Аны калдырыб, жаныннан киткянняр.

Зач. 54.

13 Іисусны сюзеннян эляктерейек диб, Анын катына фарисейлярнен, иродныкыларнын кайсыларын жибяргянняр.

14 Алар килеб, Аңар айткянняр: эй Öйрятеӱче! без Синең туры кеше икяненңне белябез, Син беряӱгя дя жараулы булыйым димейсен, кешесеня караб кылмыйсын шул, äммя Алла жулына дöрöс öйрятясен. Кесаргя имана тюляргя тейеш ме, äлля жук мы? бирейек ме, äлля бирмейек ме? дигянняр.

15 Ул аларнын жумалауларын белеб, аларга айткян: ник сез Мине сыныйсыз? Минга бер динарій китерегез, Мин аны кюрейем, дигян.

16 Алар китергянняр. Ул аларга айткян: бу кем тӧсӧ, кем исеме жазылган? дигян. Алар Аңар: Кесарнеке дигянняр.

17 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: Кесарнекен Кесаргя, äммя Алланыкын Аллага бирегез, дигян. Аңар исляре киткян.

Зач. 55.

18 Анын жанына терелеб тороу булмас диб айтеўче саддукейляр килеб, Аннан былай диб сораганнар:

19 Эй Ӧйрятеўче! Моисей безгя: беряўнен агасы ўлеб, катынын калдырса, äммя балалар калдырмаса, анын катынын энесе алыб, агасына нясел булдырсын диб жазган:

20 Жиде ага-эне бар ыйы: элекегесе катын алгач, ўлде, нясел калдырмады.

21 Аннары аны икенчесе алды: ул да ўлде, нясел калдырмады; ӧчӧнчӧсӧ дя шулай булды.

22 Шулай итеб, аны жидесе дя алыб, нясел калдырмадылар: барысыннан да суң катын да ўлде.

23 Терелеў кӧнӧндя, терелеб торгач, ул кайсына катын булыр? жидесе дя аны катынга алганнар ыйы шул, дигянняр.

24 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: сез шушынын белян, Алла жазыуын, Алла кыуатын белмейче, саташасыз меней?

25 Ўлгянняр терелеб торгач, ӧйлянмейляр дя, кеяўгя дя китмейляр, äммя кюктяге пяриштяляр кюк торалар.

26 Äммя ўлгянняр терелеб тороу турысында, Алла Моисейгя кыуак жанында: Мин Авраамъ Алласы, Исаакъ Алласы, Іаковъ Алласы дигянне Моисей княгялярендя укымадыгыз меней?

27 Алла ўлгянняр Алласы тӧгӧл, äммя тереляр Алласы. Шулай итеб, сез бик саташасыз, дигян.

Зач. 56.

28 Княгячеляр арасыннан беряў килеб, аларнын жиңешкяннярен эшетеб, Ул аларга жакшы жауаб биргянне кюреб, Аннан сораган: бар бойорокларнын иң олосо кайсы? дигян.

29 Іисусъ аңар жауаб биргян: бар бойорокларнын иң олосо бу: эй Израиль, тыңна! Ходай Аллагыз бер Ходай.

30 Ходай Алланңы бар кюңелең белян, бар жаның белян, бар уйың белян, бар кӧчӧң белян сӧй. Шушы иң оло бойорок.

31 Икенчесе дя шуңар ошаулы: жакыныңны ўзеңне сӧйгян кюк сӧй. Былардан оло бютян бойорок жук, дигян.

32 Княгяче Аңар айткян: жакшы (айттең), Ӧйрятеӱче, Алла бер, Аннан бютян Алла жук диб дӧрӧс айттең.

33 Аны бар кюңел белян, бар уй белян, бар жан белян, бар кӧч белян сӧйӧӱ, тагы жакынны ӱзеңне сӧйгян кюк сӧйӧӱ, бар жандырыулардан да, корманнардан да артык, дигян.

34 Іисусъ ул акыллы жауаб биргянне кюреб, аңар айткян: син инде Алла Падшалыгыннан жырак тӧгӧл, дигян. Шуннан суң беряӱ дя Аннан сорарга кыймаган.

35 Чиркяӱдя ӧйрятя торган кӧйӧ, Іисусъ айткян: княгячеляр Христосны ник Давидъ улы дейляр?

36 Давидъ ӱзе Святый Тын тойдорган буйынча айтя: Ходай Минем Ходайыма айткян: дошманнарыңны аягың астына салгынчы, Минем уң жагымда утыр диб.

37 Шулай, Давидъ ӱзе Аны Ходай дигяч, Ул ничек суң анын улы була? дигян. Кюб калык аны кинянеб тыңнаган.

Зач. 57.

38 Іисусъ ӧйрятеб, аларга былай айткян: княгячелярдян сакланыгыз: алар озон кейем кейеб жӧрӧӱне, урамнарда кеше башырганны,

39 Синагогаларда алда утырыуны жараталар.

40 Алар, тол катыннарнын жортларын ашаб бетереӱчеляр, кюренер ӧчӧн гня озаклаб теляк итеӱчеляр, артыгырак айыбланырлар, дигян.

41 Аннары Іисусъ (чиркяӱгя) акча сала торган тартма карышысында утырыб, тартмага калык акча салганны караб торган; байларнын кюбесе кюб-кюб салганнар.

42 Шунда бер жарлы гна тол катын килеб, ике лепта салган, икесе бер кодрантъ була.

43 Іисусъ Ӱз ӧйрянеӱчелярен чакырыб алыб, аларга айткян: чыннаб айтямен сезгя: бу жарлы тол катын акча тартмасына салыучыларнын барысыннан да кюберяк салды.

44 Барысыда артыгы бардан салдылар шул, аммя бу жарлы кӧйӧ нейе бар барын, бар тормошон салды, дигян.

## 13-нчӧ бюлем.

Зач. 58.

1 Іисусъ чиркяӱдян чыккан чакта, Анын ӧйрянеӱчеляренен берсе Аңар айткян: эй Ӧйрятеӱче! кара але, ничек ташлар, ничек каралдылар! дигян.

2 Іисусъ аңар жауаб биреб айткян: шушы зур каралдыларны кюрясең ме? мында таш ӧстӧндя таш та калмас, барысында жимереб бетерерляр, дигян.

3 Ул Елеонъ тауы өстөндя, чиркяў карышысында утырган чакта, Петръ, Іаковъ, Іоаннъ, Андрей Аннан аулакта сораганнар:

4 Әйтче безгя, бу кайчан булыр? былар буласы чакта ничек билге булыр? дигянняр.

5 Іисусъ аларга жауаб биреб әйтя башлаган: сак булыгыз, беряў-беряў сезне жангыштырмасын.

6 Кюбесе Минем исемем белян килерляр, мин (Христосъ) дирерляр, кюбесен жангыштырырлар да.

7 Сугышлар булганны, сугыш хабярлярен эшеткяч, курыкмагыз, былар булырга тейеш шул; алайда ул әле бетеў төгөл.

8 Калык калыкка, падшалык падшалыкка жабышыр; урны-урны белян жир титряр, ачлыклар булыр, калык болганыр. Былар азабларнын башланыуы гна, дигян.

Зач. 59.

9 Сез ўзегез сагайыгыз: сезне шу хокөмгя тотоб бирерляр, синагогаларда кыйнарлар; Минем сяятлей сезне тюряляр алдына, падшалар алдына житякляб итярляр, алар алдында (Минем турда) таныклык итяр өчөн.

10 Элгяре бар калыкларга да Евангеліе сөйлянергя тейеш.

11 Сезне тотоб биреўчеляр анда алыб барган чакта, ней әйтербез диб көйөнмягез, алдан уйламагыз, әммя шул сагаття сезгя ней бирелер, шуны әйтегез; әйтеўчеляр сез булмассыз шул, әммя Святый Тын (әйтер).

12 Агасы энесен, атасы улын ўлемгя бирер, балалары ата-аналарына карышы тороб, аларны ўтерерляр.

13 Минем исемем өчөн сезне барда кюрялмаслар; алайда калдыкка чаклы тюзгяне котолор, дигян.

Зач. 60.

14 Даніилъ пагамбяр әйткянчя, жирянгеч нястяляр торорга тейеш төгөл урында жирянгеч нястяляр торганны кюргяч, (укыган кеше аңнасын), Іудеядя тороучылар тауларга качсыннар.

15 Өй тюбясендя булганы өйөня төшмясен, өйөмнян бер-бер нястя алыб китейем диб кермясен.

16 Басыуда булганы, кейememне алыб китейем диб, кире кайтмасын.

17 Ул көннярдя ауырлы катыннарга, имчяк имезеўчеляргя читен булыр.

18 Качарыгызга кыш туры килмясен эйе диб телягез.

19 Ул көнняр кайгылы булыр, анын кюк кайгы Алла булдырган дөнья була башлаганнан бирле әлегя чаклы булганы жук, булмас та.

20 Ӓгяр Ходай ул көннярне кыскартмаса, бер тян дя котолмас ыйы, тик Ул Ӱзе сайлаган сайланганнары какына ул көннярне кыскартыр.

21 Ул чакта беряӱ сезгя: мына мында Христосъ, жя ана тегендя дейся, ышанмагыз.

22 Жалган христослар, жалган пагамбярляр чыгарлар; мөӊким булса, сайланганнарны да жангыштырыр өчөн, кодрятляр кюрсяткян булырлар.

23 Ӓммя сез сак торогоз; мына Мин сезгя барысында алданук айттем, дигян.

Зач. 61.

24 Ул көннярдя шундый кайгыдан суӊ кояш карангыланыр, ай ӱз жактысын жактыртмас.

25 Жондозлар кюктян койолорлар, кюктяге чиреӱляр дя кузгалышырлар.

26 Аннары болотлар өстөндя зур кодрят белян, оло дан белян килеӱче Ӓдям Улын кюрерляр.

27 Ул чакта Ул Ӱз пяриштяляревн жибяреб, дөньянен дюрт жагыннан да жир кырыйыннан башлаб, кюк кырыйына чаклы, сайлаганнарын жыйдырыр.

28 Смоква агачыннан ошаш алыгыз: анын ботаклары жомошаб, жапрак жара башлагач, жяй жакын икянне белясез.

29 Шунын кюк былар барысыда булганны кюргяч, инде жакын, ишек төбөндя диб белегез.

30 Чыннаб айтямен сезгя: шушы тыума беткенче, былар барысыда булыр, дигян.

Зач. 62.

31 Кюк белян жир бетярляр, ӓммя Минем сюзлярем була торор.

32 Ул көннө, ул сагатне бяряӱ дя белмей, кюктяге пяриштяляр дя, Улы да (белмей), тик Ата гна (беля).

33 Карагыз, уяу торогоз, теляк итегез, ул багыт кайчан буласын белмейсез шул.

34 Ул багыт жулга киткяндя жортон калдырыб, ӱз кызмятчеляреня башкарыб торорга кушыб, ӓр-берсеня ӱз алдына эш биреб, кабка сакчысына жокламый торорга кушыб киткян кешегя ошаулы.

35 Алай булгач, сез уяу торогоз: жорт эясенен кич ме, төн уртасында мы, ӓтяч кычкырганда мы, иртя белян ме, кайчан килерен белмейсез.

36 Тоймастын килеб, сезне жоклаган көйө очратмасын.

37 Сезгя айткянне буганнарга да айтямен: уяу торогоз, дигян.

14-нче бюлем.

1 Пасхага, тӧчӧ кюмяч кӧнняреня ике кӧн калгач, архіерейляр, князячеляр Іисусны хайля белян тотоб алыб, ўтерергя кӧй эзлягянняр.

2 Алайда калык болганышмасын диб, мыны бяйрям кӧннӧ (кылмыйык) дигянняр.

Зач. 63.

3 Ул Виѳаніядя кутырлы тянне Симоннын ӧйӧндя утырган чакта, бер катын алавастръ сауыт белян кыйбатлы нардъ майы, катыштырмаган мѵро алыб килеб, сауытын ачыб, Анын башына койган.

4 Кайсылары мыны жаратмыйчы ўз-аралый айткянняр: ник бу мѵроны ӓрям итте?

5 Мыны ӧч жӧз динарійдян дя кыйбатырак сатыб, (акчасын) сораныучыларга ӧляшергя мӧнким эйе ич, дигянняр. Катынга зарланганнар.

6 Ӓммя Іисусъ айткян: теймягез аҥар, ник сез аны жӧдятясез? ул Миҥа жакшы эш кылды.

7 Сораныучылар жалан сезнен белян ич, телягян чагыгызда аларга жакшылык кыла алырсыз, ӓммя Мин жалан сезнен белян тӧгӧл.

8 Ул булдыра алганын кылды, тянемне алдан майлаб, кюмяргя ӓзерляде.

9 Чыннаб айтямен сезгя: бӧтӧн дӧньядя кайда гна булса да шушы Евангеліе сӧйлянелся, ул катынны искя тӧшӧрӧргя, анын ней кылганы да айтелер, дигян.

Зач. 64.

10 Ун икенен берсе, Искаріотъ Іуда дигяне Іисусны архіерейляргя тотоб бирергя диб, алар катына барган.

11 Алар мыны эшеткяч, сӧйӧнӧшкянняр, аҥар кӧмӧш тянкяляр бирмякче булганнар; аннары ул Аны тотоб бирергя кӧйлӧ багыт эзлягян.

12 Тӧчӧ кюмяч кӧнняренен элеке кӧнӧндя, пасха бярянен чалыр багытта, ӧйрянеўчеляре Аҥар айткянняр: пасханы кайда ашасы итясен? без барыб ӓзерлярбез, дигянняр.

13 Ӧйрянеўчеляренен икесен жибяреб, аларга айткян: калага барыгыз, анда сезгя кувшинъ белян сыу кютяреб барыучы кеше очорар, анын артыннан барыгыз;

14 Ул кергян ӧйнӧн эясеня айтегез: Ӧйрятеўче: Мин ӧйрянеўчелярем белян пасха ашасы бюлмя кайда? диб айтя дигез.

15 Ул сезгя идяненя жяйгян, ӓзерляб куйган зур бюлмя кюрсятер, безгя шунда ӓзерлягез, дигян.

16 Ойрянеўчеляре киткянняр. Калага килгяч, Ул аларга айткянчя, туры китереб, шунда пасха ӓзерлягянняр.

17 Кич булгач, Ул ун ике (ойрянеўчесе) белян килгян.

18 Ашаб утырган чакта, Іисусъ айткян: чыннаб айтямен сезгя: Минем белян бергя ашаучы, сезнен арадан беряў Мине тотоб бирер, дигян.

19 Алар кайгыга тöшöб, берсе артыннан берсе Аңар: мин тöгöл ме, мин тöгöл ме? диб айтя башлаганнар.

20 Ул аларга жауаб биреб айткян: ун икегезнен берсе, Минем белян бергя тозлокка мана торганы;

21 Алайда Ӓдям Улы Ўз турында жазылганча бара, тик Ӓдям Улын тотоб биреўчегя жаман булыр, ул кешегя тыумаганы жакшырак булыр ыйы, дигян.

22 Ашаган чакларында Іисусъ икмяк алыб, бахиллягян дя сындырыб, аларга биреб айткян: алыгыз, ашагыз, бу Минем Тянем, дигян.

23 Аннары сауытны алыб, тау итеб, аларга биргян; аннан барысыда эчкянняр.

24 Шунда Ул аларга айткян: бу Минем кюб кешеляр öчöн агыза торган жаңа законъ Каным.

25 Чыннаб айтямен сезгя: инде Мин жимеш сыуын Алла Падшалыгында жаңа эчемнек эчяр кöнöмя чаклы эчмямен, дигян.

26 Аннары иман жырлагач, Елеонъ тауына киткянняр.

27 Шунда Іисусъ аларга айткян: бу тöннö сез барыгызда Минем турда шиклянерсез, жазылган шул: кöтöўчесен уатыб бетерем, сарыклары таралыб бетярляр диб.

28 Аннары терелеб торгач, Мин сезне Галилеядя карышы алырым, дигян.

29 Петръ Аңар айткян: барысыда шиклянсяляр дя, мин шиклянмям, дигян.

30 Іисусъ аңар айткян: чыннаб айтямен сиңа: син бöгöн шушы тöндя, ӓтяч ике табкыр кычкыргынчы, Мине öч табкыр таңарсын, дигян.

31 Петръ тагы бигеряк ныклаб айткян: ӓгяр миңа Синең белян бергя ўлляргя туры кился дя, мин Сине таңмам, дигян; барысыда шулай диб айткянняр.

32 Аннары алар Геѳсиманія дигян урынга килгянняр, килгяч ойрянеўчеляреня айткян: Мин барыб теляк итеб килгенче, сез мында утырыб торогоз, дигян.

33 Аннары Ӳзе белян бергя Петрны, Іаковны, Іоанны алыб киткян дя куркыныб кӧйӧня башлаган.

34 Аларга айткян: Минем жаным ӳлярлек булыб кӧя, сез мында тора тороб, уяу торогоз, дигян.

35 Аннары бер аз китеб, жиргя жыгылыб, мӧҥким булса, бу сят Миннян узсын ыйы диб, инялеб

36 Айткян: эй Авва Ӓтей! Сиҥа барда мӧҥким, бу сауытны Миннян уздыр, алайда Мин телягянчя тӧгӧл, ӓммя Син телягянчя (булсын), дигян.

37 Аннары кайтыб, ӧйрянеӳчеляренен жоклаб жатканнарын очратыб, Петрга айткян: Симонъ! жоклойсын меней? син бер гня сагат тя уяу тора алмадыҥ меней?

38 Алданмас ӧчӧн, уяу торогоз, теляк итегез, тын уяу, ӓммя тян халсез, дигян.

39 Тагы китеб, шул сюзне айтеб инялгян.

40 Кайтыб, аларны тагы жоклаган кӧйӧ очраткан, аларнын кюзлярен жоко баскан икян шул; алар Аҥар ней жауаб бирергя дя белмягянняр.

41 Аннары ӧчӧнчӧ табкыр килеб, аларга айткян: сез ӓле гел жоклаб жатасыз икян; бетте инде, сагат житте; мына Ӓдям Улы жазыклылар кулына тотоб биреля.

42 Торогоз, айдягез, мына Мине тотоб биреӳче жакыннашты, дигян.

Зач. 65.

43 Ул мыны айткян сяттюк, ун икенен берсе Іуда килеб житкян; анын белян бергя архіерейлярдян, княгячелярдян, калык башлыкларыннан жибярелгян кюб калык кылычлар, казыклар алыб (килгянняр).

44 Аны тотоб биреӳче аларга былай айтеб билге куйган: мин Кемне ӳбсям, шул Ӳзе, Аны тотоб алыгыз да саклаб кна алыб китегез, дигян.

45 Килеӳ белян Аҥар жакыннашыб, эй Равви, Равви! диб Аны ӳбкян.

46 Аннары Аны куллары белян тотоб алганнар.

47 Шунда тороучыларнын берсе кылычын сыуырыб алыб, архіерей колонон колагын чабыб ӧзгян.

48 Шунда Іисусъ аларга айткян: талаучыга чыккандый, кылычлар, казыклар алыб, сез Мине тотоб алырга чыккан.

49 Чиркяӳдя ӧйряткян чагымда, Мин кӧндя сезнен белян булдым, ӓммя сез Мине тотоб алмадыгыз; жазылганы жиреня килсен инде, дигян.

50 Ул чакта (ӧйрянеӳчеляре) барда Аны калдырыб качканнар.

51 Бер жегет жалангач тян őстőннян жабынгыч бőркянеб, Анын артыннан барган; салдатлар ул жегетне тотканнар,

52 Тик ул жабынгычын калдырыб, алардан жалангач кőйő качкан.

53 Іисусны архіерей катына алыб килгянняр; аңар бар архіерейляр, княгячеляр, калык башлыклары жыйылганнар.

54 Петръ жырактын Анын артыннан архіерей жортона кергенче барган; анда кызмятчеляр белян бергя ут жанында жылыныб утырган.

55 Архіерейляр белян бőтőн синедріонъ Іисусны ӱтерер őчőн, Аңар карышы таныклык эзлягянняр, тик таба алмаганнар.

56 Кюбесе Анын őстőннян жалган таныклык иткянняр, тик бу таныклыклары житярлек булмаган.

57 Кайсылары тороб, Анын őстőннян жалган таныклык итеб айткянняр:

58 Без Анын: шушы кул белян торгозган чиркяӱне жимерем дя őч кőннян суң кул белян торгозмаган бютян чиркяӱ торгозормын диб айткянен эшеттек, дигянняр.

59 Андый таныклыклары да житярлек булмаган.

60 Аннары архіерей уртага тороб, Іисустан сораган: быларнын Сиңа карышы таныклауларына Син ник бер жауаб та бирмейсен? дигян.

61 Ӓммя Ул дяшмягян, бер жауаб та бирмягян. Архіерей тагы сораб айткян: Даннаулынын Улы Христосъ Син ме? дигян.

62 Іисусъ айткян: Мин диб, мына Кодрятленен уң жагында утырыучы Ӓдям Улынын кюк болотлары őстőндя килгянен кюрерсез, дигян.

63 Шул чакта архіерей ӱз кейемнярен жыртыб айткян: тагы безгя нейгя таныкчылар?

64 Алланы курлаганны эшеттегез, сезгя ничек тея? дигян; алар барысыда: Аны ӱтерергя тейеш дигянняр.

65 Аннары кайсылары Аңар тőкőря башлаганнар, жőзőн бőркяб, Аңар сугыб, белеб айт! дигянняр. Кызмятчеляр дя Анын жаңакларына сукканнар.

66 Петръ тюбян, ишек алдында утырган чакта, архіерейнен бер катын кызмятчесе килгян дя,

67 Жылыныб торган Петрны кюреб, аңар тегяляб караб айткан: син дя Іисусъ Назарянинъ белян эйең, дигян.

68 Ул таңыб, син ней айткянне белмейем, аңнамыйым дигян дя алдагы ишек алдына чыккан: шул сяттюк ӓтяч кычкырган.

69 Кызмятче катын аны тагы кюреб, шунда тороучыларга айтя башлаган; бу алар арасыннан диб. Ул тагы танган.

70 Бер-ауыктан суҥ, шунда тороучылар Петрга тагы äйткянняр: чыннаб син алар арасыннан, син Галилеянеке, сöйляшеӳеҥ дя шулай, дигянняр.

71 Äммя ул: сез äйтя торган кешене белмейем диб карганыб таҥга башлаган.

72 Шундук äтяч икенче табкыр кычкырган. Петръ Іисуснын аҥар: äтяч ике табкыр кычкыргынчы, син Мине öч табкыр таҥарсын диб äйткян сюзен исеня тöшöргян дя жылый башлаган.

15-нче бюлем.

Зач. 66.

1 Шундук иртя белян архіерейляр, калык башлыклары, княгячеляр, бöтöн синедріонъ киҥяш иткянняр дя, Іисусны бяйляб, Пилатка итеб биргянняр.

2 Пилатъ Аннан сораган: Син Іудея Падшасы мы? диб. Ул аҥар жауаб биреб äйткян: (дöрöс) äйтясен, дигян.

3 Архіерейляр Аны кюб туры белян айыблаганнар.

4 Пилатъ Аннан тагы сораган: Син бер жауаб та бирмейсен ме? кара, Сиҥа карышы ней чаклы таныклык итяляр? дигян.

5 Äммя Іисусъ мыҥар да бер жауаб та бирмягян; Пилатнын шуҥар бик исе киткян.

6 Ул аларга бяйрям сайын быгаудагыларнын берсен, алар сораганын жибяря икян.

7 Шул чакта бер Варавва атлы кеше ӳз иптяшляре белян быгауда тора икян, алар калык болганышкан чакта, кеше ӳтергянняр икян.

8 Калык Пилаттан ул аларга жалан кыла торганын кылсын диб кычкырыб сорой башлаган.

9 Пилатъ аларга жауаб биреб äйткян: телеймесез, мин сезгя Іудея Падшасын жибярем? дигян.

10 Ул архіерейлярнен Аны кöнчöлöк белян тотоб биргяннярен белгян икян.

11 Äммя архіерейляр калыкны: безгя Варавваны жибяргянеҥ жакшырак диб äйтергя котортканнар.

12 Пилатъ аларга тагы äйткян: сез Іудея Падшасы диб атый торганга мин ней кылсын диб телейсез? дигян.

13 Алар: Аны кадаклат! диб кычкырганнар.

14 Пилатъ аларга äйткян: Ул ничек усаллык кылды суҥ! дигян. Äммя алар: Аны кадаклат! диб бигеряк тя шяб кычкырганнар!

15 Аннары Пилатъ калык телягянне кылыйым диб, аларга Варавваны чыгарыб биргян, äммя Іисусны кыйнатыб, кадакларга биргян.

Зач. 67.

16 Салдатлар Аны жорт эченя, преторія дигян урынга житякляб китергянняр дя шунда бӧтӧн полкны жыйганнар.

17 Іисусны кызыл кейемгя кейендергянняр: башына чянечкеле агач чыбыгыннан ўрмя ўреб кейгезгянняр;

18 Аннары Анын белян исянняшкян булыб, эй Іудея Падшасы, сӧйӧн! диб айтя башлаганнар.

19 Анын башына таяк белян сукканнар. Аңар тӧкӧргянняр, алдында тезлянеб тороб, башырганнар.

20 Аны мыскыллаб туйгач, ӧстӧннян кызыл кейемне салгызыб, Аңар Ўз кейемен кейгезгянняр: аннары Аны кадакларга алыб киткянняр.

21 Басыудан кайтыб узыб барыучы беряўгя, Киринеянеке Александръ белян Руѳъ атасы Симонга, Іисуснын качын кютяртеб баргызганнар.

Зач. 68.

22 Іисусны Голгоѳа исемне Маңгай урны дигян жиргя алыб килгянняр.

23 Анда Аңар эчяргя смѵрна катыштырган аракы биргянняр, тик ул аны алмаган.

24 Аны кадаклаучылар, кемгя ней теяр диб, Анын кейемняреня жирябя салганнар, (жирябя чыкканча) ӧляшкянняр.

25 Ӧч сагат тирясе икян. Аны кадаклаганнар.

26 Айыбы Іудея Падшасы диб жазыб куйылган.

27 Анын белян бергя ике талаучыны кадаклаганнар: берсен уң жагына, икенчесен сул жагына.

28 Жазыудагы сюзнен: усаллар белян тингя саналган дигяне жиреня килгян.

29 Жаныннан узыучылар башларын селкеб, Аны курлаб айткянняр: эй чиркяўне жимереб, ӧч кӧндя торгозоб житкезеўче!

30 Ўзеңне коткар, качтан тӧш, дигянняр.

31 Архіерейляр белян княгячеляр дя шулай мыскыллаб, бер-берсеня айткянняр: бютяннярне коткарган, äммя Ўзен коткара алмый.

32 Израиль Падшасы Христосъ инде качтан тӧшсӧн, без дя кюрер эйек, аннары ышаныр ыйык, дигянняр. Анын белян бергя кадакланганнар да Аны курлаганнар.

33 Алтынчы сагаттян тугызынчы сагаткя чаклы бӧтӧн жир ӧстӧндя карангы булыб торган.

34 Тугызынчы сагаття Іисусъ каты тауыш белян кычкырыб айткян: Элои! Элои! лама савахѳани? диб, бу: эй Аллам! эй Аллам! Син Мине ник ташладын̆? дигян сюз була.

35 Мыны эшетеб, шунда тороучыларнын кайсылары айткянняр: мына Иліяны чакыра, дигянняр.

36 Берсе жӧгӧрӧб барыб, болотка серкя сен̆дереб, аны таякка элеб, Ан̆ар эчяргя биреб айткян: туктагыз äле, караб торойок, Илія Аны (качтан) алырга килер микян? дигян.

37 Аннары Іисусъ тагы каты кычкырыб, тынын чыгарган.

38 Шул чакта чиркяў шаршауы жугары кырыйыннан тюбян кырыйына чаклы икегя айырылган.

39 Іисусъ карышысында тороучы сотникъ, Ул тынын шулай кычкырыб чыгарганны кюреб айткян: чыннаб бу кеше Алла Улы икян, дигян.

40 Анда тагы жырактын караб тороучы катыннар да булганнар, алар арасында Марія Магдалина, кече Іаковъ белян Іосія анасы Марія, тагы Саломія да булган;

41 Алар Іисуска Галилеяда чагында эяреб жӧрӧб, Ан̆ар кызмят иткянняр; анда тагы Анын белян бергя Іерусалимгя килгян бютян катыннар да кюб булган.

42 (Ул пятница суббота алдындагы кӧн булганга кюря), кич булгач,

Зач. 69.

43 Аримаѳеянын Іосифъ килгян, ул бик кадерле кин̆яшче икян, ўзе Алла падшалыгын кӧтя икян; ул кыйыуланыб Пилатка кереб, Іисуснын тянен сораган.

44 Іисусъ тиз ўлгянгя Пилатнын исе киткян; сотникны чакырыб алыб, аннан: кюбтян ўлде ме? диб сораган.

45 Сотниктан белгяч, тянне Іосифка биргян.

46 Іосифъ киндер сатыб алыб, Іисусны качтан алыб, киндергя тӧрӧб, таш тауга тишеб жасаган кабергя куйган, кабер ауызына таш каблаган.

47 Марія Магдалина белян Іосія Маріясы Аны кайда куйганны караб торганнар.

## 16-нчы бюлем.

Зач. 70.

1 Суббота ўткяч, Марія Магдалина, Іаковъ Маріясы, тагы Саломія барыб Іисуска сӧртӧргя диб, эйесле май сатыб алганнар.

2 Атнанын элекеге кӧнӧндя, бик иртя белян, кояш чыккан чакта, алар кабер катына килгянняр.

3 Килгяндя бер-берсе белян: безгя кабер ауызындагы ташны кем аударыр икян? диб сӧйляшкянняр.

4 Килеб карасалар, кюряляр, таш аударылган, äммя ул бик зур икян.

5 Кабергя кергяч, алар уҥ жакта утырган, ак кейем кейгян жегетне кюргянняр; бик курыкканнар.

6 Ул аларга айткян: курыкмагыз, сез кадакланган Іисусъ Назарянинны эзлейсез; Ул терелеб тордо, мында жук, мына Аны куйган урын.

7 Äммя сез барыгыз, Анын öйрянеўчеляреня, Петрга да айтегез: Ул сезне Галилеядя карышы алыр, Ўзе сезгя айткянчя, Аны анда кюрерсез, дигез.

8 Алар чыгыб, кабер жаныннан жöгöрöшöб киткянняр; алар бик курыкканнар, калтрашканнар; курыкканныктан беряўгя дя бер сюз дя айтмягянняр.

Зач. 71.

9 Атнанын элекеге кöнöндя иртюк, терелеб торгач, Іисусъ иҥ элеке Марія Магдалинага кюренгян, Іисусъ аннан жиде женне кыуалаб чыгарган икян.

10 Ул кайтыб мыны Іисусъ белян жöргянняргя, сулкылдаб жылаучыларга белдергян.

11 Äммя алар, анын: Іисусъ тере, мин Аны кюрдем дигянен эшетеб, ышанмаганнар.

12 Аннан суҥ Іисусъ öйрянеўчеляренен икесеня жулда, бер ауылга барган чакларында, бютян тöслö булыб кюренгян.

13 Алар да кайтыб, бютянняргя белдергянняр, äммя алар быларга да ышанмаганнар.

14 Калдыгында Ул ун бер (öйрянеўчесеня), бергя утырган чакларында кюренеб, ышанмаганнары öчöн, кюҥелляреп каты тотканнары öчöн, Аны терелеб торгач кюреўчеляргя дя ышанмаганнары öчöн, аларны äрлягян.

15 Аннары аларга айткян: бöтöн дöньягя жöрöб, булдырылганнарнын барысынада Евангеліене сöйлягез.

16 Ышанган кеше, чумылдырылган кеше котолор, äммя ышанмаган кеше айыблы булыр.

17 Ышанганнарга мындый билгеляр булырлар: Минем исемем белян женнярне кыуалаб чыгарырлар, жаҥа телляр белян сöйляшерляр;

18 Жыланнарны кулга алырлар, бер-бер ўтергеч нястя эчсяляр дя, аларга зыян теймяс; чирлеляр öстöня кулларын салырлар, алар сауыгырлар, дигян.

19 Шулай итеб, Ходай, öйрянеўчеляре белян сöйляшкяннян суҥ, кюккя кютярелеб, Алланын уҥ жагыннан утырган.

20 Äммя алар китеб, äр-бер жирдя Евангеліене сöйлягянняр; Ходай аларга булышкан, сюзне шундук булган билгеляр белян ныклаган. Аминь.

# Лука жазган арыу Евангеліе.

1-нче бюлем.

Зач. 1.

Безнен арада бöтöнняй билгеле эшляр турысында кюбесе инде сöйляў тöзöй башладылар;

2 Безгя ул эшлярне Сюзне баштанук кюреўчеляр, (Аҥар) кызмят итеўчеляр айтеб бирделяр;

3 Шуҥар кюря, эй кадерле Өеофилъ, барысында баштанук тырышыб тикшергяч, мин дя сиҥа ряттян жазасы иттем,

4 Сиҥа элеке өйряткян нястянен нык төбөн белсен диб.

Зач. 2.

5 Іудея падшасы Иродъ кённярендя Авія няселенен чиратында Захарія атлы священникъ булган; анын катыны Ааронъ няселеннян икян, исеме Елисавета атлы булган.

6 Алар Ходайнын бар бойороклары, дөрёсляндергечляре буйынча шиксез тороб, икесе дя Алла алдында дөрёс булганнар.

7 Аларнын балалары булмаган. Елисавета бала тыудырмый икян, икесе дя кюб жяшяб картайганнар икян.

8 Бер табкыр Захарія ўз чиратында Алла алдында чиркяў кызмятен иткян чакта,

9 Священникляр арасында булган жолача, жирябя сикерткяч, аҥар Ходай чиркяўеня кереб, ладанъ эйесе чыгарыу ряте тейгян.

10 Ладанъ эйесе чыгарган чакта, кюб калык барда тыш бюлемдя теляк иткян.

11 Шул чакта аҥар ладанъ жандыра торган урыннын уҥ жагында Ходай пяриштясе кюренгян.

12 Захарія аны кюргяч, жөдяб киткян, аҥар куркыу төшкян.

13 Äммя пяриштя аҥар äйткян: курыкма Захарія, синеҥ теляген эшетелде, катыныҥ Елисавета сиҥа ул тыудырыр, аҥар Іоаннъ диб ат куярсын.

14 Сиҥа сөйөнөч, кыуаныч булыр; анын тыуыуына кюб кешеляр сөйөнөрляр.

15 Ул Ходай алдында оло булыр; аракыны да, ўнгя исерткеч эчемнекне дя эчмяс, анасы эченнянюк Святый Тынга тулыланыр.

16 Израиль улларынын кюбесен Ходай Аллаларына кайтарыр.

17 Анын алдыннан Илія тыныдый тын белян, анын кыуатыдый кыуат белян, аталарынын кюҥелляren балаларына борорга, карыш кешелярне гаделляр белян бер уйлы итяргя, äзерлягян калыкны Ходайга китереб куярга килер, дигян.

18 Захарія пяриштягя äйткян: мин мыны нейдян белерем? мин ўзем дя карт, катыным да картайыб беткян инде, дигян.

19 Пяриштя аҥар жауаб биреб äйткян: мин Алла алдында тороучы Гавріилъ, мине Алла синеҥ белян сөйляшергя, сиҥа бу арыу хабярне äйтергя жибярде.

20 Мына син шушы айткян сюзляремнен ўз багытында булырына ышанмаганыӈ өчөн, шул эш буласы кӧнгя чаклы дяшмей тороpсон, сӧйляшя дя алмассын, дигян.

21 Ул арада калык Захаріяны кӧтӧб заркыб торган, ул чиркяўдя озаклаганга абтраб торганнар.

22 Ӓммя ул чыккач, алар белян сӧйляшя алмаган, чиркяўдя аӈар кюренеў булганын белгянняр; аларга билгеляр белян гня аӈнаткан; шуннан суӈ ул телсез булыб торган.

23 Кызмят итя торган кӧнняре ўткяч, ул ўз ӧйӧня кайткан.

Зач. 3.

24 Шул кӧннярдян суӈ анын катыны Елисавета буйга узган; биш ай кешегя белдермягян, ул айткян:

25 Кешеляр арасындагы курлыгымны алыр ӧчӧн, шушы кӧннярдя Ходай миӈа шулай кылгандыр, дигян.

26 Алтынчы айда Алладан Гавріилъ пяриштя Галилеядяге Назаретъ дигян калага,

27 Давидъ няселеннян чыккан Іосифъ атлы иргя жяряшелгян кызга жибярелгян, кызнын аты Марія.

28 Пяриштя анын катына кереб айткян: эй дяўлятле, сӧйӧн! Ходай Синеӈ белян; Син катыннар арасында даннаулы, дигян.

29 Марія аны кюргяч, анын сюзляреннян жӧдяб киткян: былай айтеб кюрешеўе ней белдереўе икян? диб уйлаб торган.

30 Пяриштя Аӈар айткян: эй Марія, курыкма! Син Алла алдында дяўлят табтыӈ.

31 Мына Син буйга узыб, Ул тыудырырсын, Аӈар Іисусъ диб ат куярсын.

32 Ул оло булыр, Жугарыгынын Улы диб аталыр, Ходай Алла Аӈар атасы Давиднын престолын бирер;

33 Ул Іаковъ тыумасына гумергя падшалык итяр, Анын падшалыгы ич тя бетясе тӧгӧл, дигян.

34 Марія пяриштягя айткян: миӈа ир жакыннашмаган кӧйӧ, бу ничек булсын? дигян.

35 Пяриштя Аӈар жауаб биреб айткян: Сиӈа Святый Тын иӈяр, Сине Жугарыгынын кыуаты бӧркяр, шул сяятлей тыуасы Изге дя Алла Улы диб айтелер.

36 Мына Синеӈ бала китермей диб айтеля торган карендяшеӈ Елисавета, ул да картайган кӧнӧндя буйга узыб улланды, аӈар инде алтынчы ай;

37 Алланын бер гня сюзе дя булмый калмас шул, дигян.

38 Аннары Марія айткян: мына мин Ходай мяндясе, айса минга син айткянчя булсын, дигян. Шуннан ары пяриштя Анын катыннан киткян.

Зач. 4.

39 Шул кённярдя Марія тороб, таулар жагына Іуда каласына ашыгыб барган.

40 Захарія ӧйӧня кергяч, Елисавета белян исянняшкян. Елисавета Маріянын исянняшкянен эшеткяч,

41 Елисавета эчендяге бала уйнаклаб киткян; Елисавета Святый Тынга тулыланыб,

42 Зур тауыш белян кычкырыб айткян: Син катыннар арасында даннаулы, Синнян тыуасы да даннаулы!

43 Ходайымнын Анасы минга килеўе бу минга ничек булды?

44 Исянняшкян тауышынгны колагым эшеткячтюк, эчемдяге балам сӧйӧнӧб уйнаклады.

45 Ышанган Син, бахетле, Синга Ходайдан айтелгян жиреня килер шул, дигян.

46 Шул чакта Марія айткян: минем жаным Ходайны данный,

47 Минем кюнгелем Коткарыучы Аллама сӧйӧня;

48 Ул Ўз мяндясенен жыуашлыгына кюз салды, мыннан былай бар затлар да мине даннарлар шул;

49 Кодрятле минга зурлык бирде, Анын исеме арыу.

50 Аннан куркыучыларга Анын изгелеге тыумыштан тыумышка тора.

51 Ул Ўз кулынын кыуатын кюрсятте; кюнгелляре олосомак уйлыларны таратты.

52 Кӧчлӧлярне престолларыннан тӧшӧргян, äммя жыуашларны кютяргян.

53 Ачыкканнарны дяўляткя туйдырган, äммя байсымакларны коро калдырган.

54 Ўз мяндясе Израилне кабыл алды,

55 Аталарыбызга айткянчя, Авраамга,анын няселеня мянгегя кыласы изгелеген исеня тӧшӧрдӧ, дигян.

56 Марія анын белян ӧч айлаб торган, аннары ӧйӧня кайткан.

57 Елисаветанын тыудырыр багыты житкян; ул ул тыудырган.

58 Кюрешеляре белян карендяшляре, Ангар Ходай зур изгелек кылганны эшетеб, анын белян бергя сӧйӧнӧшкянняр.

59 Сигезенче кӧнӧндя балага кисеў кыларга килгянняр; аны атасы исеме белян Захарія диб атамакчы булганнар.

60 Мынгар анасы айткян: жук, ул Іоаннъ диб аталсын, дигян.

61 Аңар айткянняр: няселендя андый исем белян атала торган беряӱ дя жук, дигянняр.

62 Аннары аңар ничек исем бирясе киля икян диб, атасыннан билгеляр белян сораганнар.

63 Захарія кечкеня гня такта сораб алган да: анын исеме Іоаннъ диб жазыб биргян. Барысынында исляре киткян.

64 Шул сяттюк анын ауызы, теле ачылган; ул аннары Алланы даннаб, сӧйляшя башлаган.

65 Аларнын тиря жагында тороучыларнын барысынада куркыныч тӧшкян; мынын барысы турысында да Іудеянен бӧтӧн таулык жагында сӧйляшкянняр.

66 Эшетеӱчеляр барысыда мыны кюңелляреня салыб, бу бала нейдей булыр икян? дигянняр. Анда Ходайнын кулы торган.

67 Анын атасы Захарія Святый Тынга тулыланыб, пагамбярлек итеб айткян:

68 Израиль Алласы Ходай даннаулы, Ул Ӱз калкына килеб, Аңар котолоу кылды шул.

69 Ӱз мяндясе Давидъ жортоннан безгя Коткарыучы чыгарды;

70 Ӓӱӓледянюк булган изге пагамбярляренен ауызыннан белдергянчя,

71 Безне дошманнарыбыздан, безне кюрялмый тороучыларнын барысынында кулыннан коткарасысын,

72 Аталарыбызга изгелек кыласысын, Ӱзенен изге багадясен исеня алырын,

73 Атабыз Авраамга карганыб айткянен,

74 Безне, дошманнарыбыз кулыннан котолгач, курыкмыйчы

75 Гумеребезнен бар кӧннярендя дя Ӱз алдында арыулык белян, дӧрӧслӧк белян Ӱзеня табындыртасын (исеня тӧшӧрдӧ).

76 Эй бала, син дя Жугарыгынын пагамбяре диб айтелерсен, син шу Ходай алдыннан килеб, Аңар алдан жул ӓзерлярсен,

77 Анын калкына жазыклары кичелеб котолоуны ангартырсын,

78 Аллабызнын арыу кюңеленен изгелеге буйынча (котолоуны) ангартырсын; шул (изгелеге буйынча) безгя жугартын Кояш чыгышы,

79 Карангыда, ӱлем карангысында утырыучыларны жактыртырга, аякларыбызны тыныч жулга ынгайларга килде.

80 Бала ӱз-кӧйӧ белян ӱскян, тыны ныкланган; аннары Израилгя кюренер кӧнӧня чаклы буш кырларда торган.

2-нче бюлем.

Зач. 5.

1 Шул кӧннярдя кесарь Августь бӧтӧн жирдяге калыкны тикшереб жазарга кушкан.

2 Бу жазыу Кириній Сирія жирен биляб торганда элекенче жазыу булган.

3 Шул чакта барысыда жазылырга барганнар, ӓр-кайсы ӱз каласына (барган).

4 Шулай Іосифъ та Галилеядан, Назаретъ каласыннан Іудеяга, Давиднын Виѳлеемъ атлы каласына барган, ул шу Давидъ жортоннан, анын няселеннян икян.

5 Жазылырга диб ул ӱзеня жяряшелгян катыны Маріяны да алыб барган; Марія (ул чакта) жӧклӧ икян.

6 Алар анда чагында, Анын тыудырыр багыты житкян.

7 Ул шунда ӱзенен элек Улын тыудырган, Аны биляб, утлыкка салган, узгынчылар керя торган ӧйдя аларга урын табылмаган шул.

8 Ул жактагы кырда кӧтӧӱчеляр булганнар, алар тӧння ӱз кӧтӧӱлярен саклаб торалар икян.

9 Кинят аларга Ходай пяриштясе кюренгян, шундук аларга Ходайнын даны жактырган; алар бик курыкканнар.

10 Пяриштя аларга ӓйткян: курыкмагыз, мин сезгя зур сӧйӧнӧч ӓйтям, ул бар кешеляргя дя булыр:

11 Бӧгӧн сезгя Давидъ каласында Коткарыучы тыуды, Ул Ходай Христосъ Ӱзе.

12 Мына сезгя билге: биляб салган кӧйӧ утлыкта жата торган Баланы очратырсыз, дигян.

13 Кинят ул пяриштя белян кюктяге бик кюб чиреӱляр кюренеб, Алланы даннаб жырлаганнар:

14 Шӧкӧр жугарыгы Аллага, жир ӧстӧндя тынычлык, кешеляргя арыу ризалыгы диб.

15 Пяриштяляр алар катыннан кюккя кютярелгяч, кӧтӧӱчеляр бер-берсеня ӓйткянняр: ӓйдягез Виѳлеемга, анда ней булганны кюрейек, безгя Ходай ней белдерде икян? дигянняр.

16 Алар ашыгыб барганнар да Марія белян Іосифны, тагы утлыкта жата торган Баланы очратканнар.

17 Кюргяч, Ул Бала турысында аларга ней белдерелгянне ӓйтеб биргянняр.

18 Эшетеӱчелярнен барысынында аларга кӧтӧӱчеляр ӓйткян сюзляргя исляре киткян.

19 Ӓммя Марія бу сюзлярне барысында ӱз кюҥеленя салыб, исеннян жибярмей тоткан.

Зач. 6.

20 Кӧтӧўчеляр ўзляреня айтелгянчя барында эшеткянняреня, кюргянняреня Алланы даннаб, мактаб, кире кайтканнар.

21 Сигез кӧннян суӈ, Баланы кистерер багыт житкяч, Аны анасы эчендя була башлагынчук пяриштя атаганча, Іисусъ диб атаганнар.

Зач. 7.

22 Моисей законы буйынча, тазарыу кӧнняре тулгач, алар Аны Ходай алдына куярга диб, Іерусалимгя алыб килгянняр.

23 Ходай законында блай жазылган: элеке тыуган ир баланын ӓрберсе Ходайга аталсын диб.

24 Алар тагы Ходай законында айтелгянчя, корманга ике кюгярчен, жя ике бала кюгярчен китерергя диб килгянняр.

Зач. 8.

25 Ул чакта Іерусалимдя Симеонъ атлы кеше булган; ул гадел, изге тормошло, Израилнен сӧйӧнӧчӧн кӧтӧб тороучы кеше икян; анда Святый Тын торган.

26 Аӈар Святый Тын элекюк айткян икян: Ходайнын Христосын кюрмейче ўлмяссен диб.

27 Тын тойдорган буйынча, ул чиркяўгя килгян. Бала Іисуска законъ жоласын кылар ӧчӧн, атасы белян анасы Аны чиркяўгя алыб килгяч,

28 Симеонъ Аны кулына алыб, Алланы даннаб айткян:

29 Эй Ходай! Ўзеӈ айткян буйынча, казер мин мяндяӈне тынычландырыб жибярясен:

30 Инде минем кюзлярем

31Син бар калыкларнын кюзе алдында ӓзерлягян коткарыуны,

32 Жалган деннелярне жактыртасы жактыны, Ўз калкыӈ Израилнен данын кюрделяр, дигян.

33 Іосифнын да, Бала анасынын да Анын турысында алай айткянгя исляре киткян.

34 Симеонъ аларны бахиллягян; аннары Бала анасы Маріяга айткян: мына Бу Израиллярнен кюбесенен жыгылырына, торорона, кешелярнен Анын турысында сюзгя килереня жата.

35 Синеӈ ўзеӈнен дя ўзягеӈнян кылыч ўтяр. Шулай кюб кюӈеллярнен уйлары кюренер, дигян.

36 Анда Ассиръ рыуыннан чыккан Фануилъ кызы, катын пагамбяр Анна да бар икян; ул иргя китеб, ире белян жиде жыл торгач, тол калган, бик озак жяшяб картайган;

37 Тол кӧйӧ сиксян дюрт жяшкя житкян, тӧн, кӧн ураза тотоб, теляктя тороб, Аллага кызмят итеб, жалан чиркяўдя булган.

38 Шул чакта ул да жакын килеб, Ходайны даннаб Іерусалимъ кешеляренен коткарыуны кӧтӧб торганнарынын барысынада Бала турысында сӧйлягян.

39 Ходай законынча барында кылыб бетергяч, алар Галилеяга ӱз калалары Назаретка кайтканнар.

40 Бала Ӱз кӧйӧ белян ӱскян, тыны ныкланган, белемнеккя тулыланган, Анда Алланын дяӱляте торган.

41 Жыл сайын атасы белян анасы Іерусалимга Пасха бяйряменя жӧргянняр.

42 Ул ун ике жяшендя чагында, алар шулай жолача тагы Іерусалимга бяйрямгя килгянняр.

43 Бяйрям кӧнняре ӱткяч, ӧйгя кайткан чакта, бала Іисусъ Іерусалимда калган; анасы да Іосифъ та мыны белмягянняр,

44 Ӓммя Ул бютян кешеляр белян киля торгандыр диб уйлаганнар. Кӧннӧк жулны ӱткяч, Аны карендяш-рыулары, белешляре арасыннан эзлей башлаганнар.

45 Табмагач, Аны эзляб, кире Іерусалимга кайтканнар.

46 Ӧч кӧннян суҥ Аны чиркяӱдя очратканнар, Ул анда ӧйрятеӱчеляр арасында аларны тыҥнаб, алардан сораб утыра икян.

47 Тыҥнаучылар барысыда Анын акылына, биргян жауабларына исляре китеб торганнар.

48 (Атасы, анасы да) Аны кюргяч, исляре киткян. Анасы Аҥар айткян: эй Улым! Син безгя ник былай кылдыҥ? Мына атаҥ да, мин дя сине бик кӧйӧнӧб, эзляб жӧрдӧк, дигян.

49 Ул аларга айткян: ник суҥ сез Мине эзлядегез? сез ӓлля Миҥа Атамныкында булырга тейеш икянен белмядегез ме? дигян.

50 Ӓммя алар Ул аларга айткян сюзлярне аҥнамаганнар.

51 Аннары Ул алар белян бергя китеб, Назаретка кайткан; анда аларга баш салыб торган. Анасы бу сюзлярне барысында ӱз кюҥелендя саклаб тоткан.

52 Ӓммя Іисусъ белемнеккя дя буйга да ӱсеб, Аллага да, кешеляргя дя сӧйӧклӧ булган.

## 3-нчӧ бюлем.

Зач. 9.

1 Тиверій кесарнен падшалык итеӱенен ун бишенче жылында, Іудеяда Понтій Пилатъ башлык булыб торганда, Галилеяда дюртенче ӧлӧш падшасы булыб Иродъ торганда, анын агасы Филиппъ Итурея белян Трахонитъ жирендя дюртенче ӧлӧш падшасы булыб торган чакта, Лисаній Авилинея жирендя дюртенче ӧлӧш падшасы булыб торган чакта,

2 Анна белян Каіафа архіерейляр багытында, Захарія улы Іоаннга буш кырда Алладан сюз булган.

3 Шул чакта Іоаннъ жазыклар кичелер öчöн тяўбя итеў чумылдырыуын сöйляб, Іорданнын бöтöн тиря-жюнендя жöргян.

4 Бу турда Исаія пагамбяр сюзляренен княгясендя блай диб жазылган: Ходайга жул äзерлягез, Анар туры сукмаклар жасагыз диб буш кырда кычкырыучынын ауазы диб;

5 Äр-бер жылга тулыб торсон, äр-бер тау да, тюбя жир дя тябяняклянсен, кыйык тöшляр тöзлянсенняр, шома тöгöл жуллар шомарсыннар;

6 Аннары äр-бер тян Алланын коткарыуын кюрер, диб.

7 Іоаннъ ўзеня чумылырга килгян калыкка äйткян: эй жылан тыумалары! буласы кыйыннан качарга сезгя кем äйтте?

8 Тяўбягя тейешле жимеш булдырыгыз; безнен атабыз Авраамъ диб кюнелегездя уйламагыз, мин сезгя äйтямен: шушы ташлардан Авраамга балалар булдырырга Алланын кыуатыннан киля дим.

9 Балта инде агач тöбöндя жата: жакшы жимеш китермей торган агачнын äр-кайсын кисяляр дя утка ташлыйлар, дигян.

10 Калык аннан: без сун ней кылыйык? диб сораган.

11 Ул аларга жауаб биреб äйткян: кемнен ике кейеме бар, ул аны кейемсезгя бирсен; кемнен ашамныгы бар, ул да шулай итсен, дигян.

12 Мытарлар да чумылдырылырга диб килеб, анар äйткянняр: эй öйрятеўче, без ней кылыйык? дигянняр.

13 Ул аларга жауаб биргян: алырга куйылганнан артыгын алмагыз, дигян.

14 Салдатлар да шулай аннан: без ней кылыйык? диб сораганнар. Ул аларга äйткян: беряўне дя рянжетмягез, äляклямягез, ала торган жалыгызга тук булыгыз, дигян.

15 Калык Мессіяны кöтöб торганныктан, барысыда ўз кюнелляренде Іоанны: бу Христосъ тöгöл микян? диб уйлаганнар.

16 Іоаннъ барысынада äйткян: мин сезне сыуда чумылдырам, äммя миннян Кыуатлы киля, мин Анын башмагынын кайышын чишяргя дя тормоймын, Ул сезне Святый Тын белян, ут белян чумылдырыр.

17 Анын кöряге кулында: Ул ындырын äрчер, бодайын клятеня жыяр, äммя саламын сюнмяс утта жандырыр, дигян.

18 Калыкны öйрятеб, ул аларга бютян кюб сюзляр дя сöйлягян.

Зач. 10.

19 Іоаннъ дюртенче öлöшнö биляб тороучы Иродны, агасы катыны Иродіада сяятлей, тагы бютян тöрлö жаман эшляре öчöн дя оялтканга кюря,

20 Иродъ бар усал эшляреня őстяб, Іоанны őтőрмянгя жабтырган.

21 Бар калык та чумылдырылгач, Іисусъ та чумылдырылганнан суң теляк иткян чакта, кюк ачылган,

22 Святый Тын кюгярчен ряўешле тянне булыб, Анын őстőня ингян, кюклярдян ауаз булган: Син Минем сőйőклő Улым, Синдя Минем ризалыгым! диб.

Зач. 11.

23 Іисусъ Ўз кызмятен итя башлаган чагында, утыз жяшлярдя икян. Кешеляр уйлаганча, Ул Іосифъ, Илій,

24 Матѳатъ, Левій, Мелхій, Іаннай, Іосифъ,

25 Маттаѳій, Амосъ, Наумъ, Еслимъ, Наггей,

26 Мааѳъ, Маттаѳій, Семеій, Іосифъ, Іуда,

27 Іоаннанъ, Рисай, Зоровавель, Салаѳіиль, Нирій,

28 Мелхій, Аддій, Косамъ, Елмодамъ, Иръ,

29 Іосій, Еліезеръ, Іоримъ, Матѳатъ, Левій,

30 Симеонъ, Іуда, Іосифъ, Іонанъ, Еліакимъ,

31 Мелеай, Маинанъ, Маттаѳай, Наѳанъ, Давидъ,

32 Іессей, Овидъ, Воозъ, Салмонъ, Наассонъ,

33 Аминадавъ, Арамъ, Есромъ, Фаресъ, Іуда,

34 Іаковъ, Исаакъ, Авраамъ, Ѳара, Нахоръ,

35 Серухъ, Рагавъ, Фалекъ, Еверъ, Сала,

36 Каинанъ, Арфаксадъ, Симъ, Ной, Ламехъ,

37 Маѳусалъ, Енохъ, Іаредъ, Малелеилъ, Каинанъ,

38 Еносъ, Сиѳъ, Адамъ Улы, Алла Улы булган.

## 4-нче бюлем.

Зач. 12.

1 Іисусъ Святый Тынга тулыланыб, Іорданнан кайткан; шуннан суң Аны Тын буш кырга алыб барган.

2 Шунда Аны шайтан кырык кőн сынаган; шул кőннярдя Ул бер нястя дя ашамаган, ӓммя ул кőнняр ўткяч, калдыгында ачыккан.

3 Шунда шайтан Аңар ӓйткян: ӓгяр Син Алла Улы булсаң, шушы ташка икмяк булырга куш, дигян.

4 Іисусъ аңар жауаб биреб ӓйткян: кеше икмяк белян гня тора алмас, ӓммя Алланын ӓр-бер сюзе белян торор диб жазылган, дигян.

5 Аннары Аны бейек тау őстőня меңгереб, кюз ачыб кюз жомгончы, шайтан Аңар дőньядяге бар падшалыкларны кюрсяткян.

6 Шунда шайтан Аңар ӓйткян: шушыларнын барысында, аларнын эямен дя Синең кулыңа бирем, алар миңа бирелгян шул, аны телясям кемгя бирямен.

7 Алай булгач, Син миңа башырсаң, барыда Синеке булыр, дигян.

8 Іисусъ аңар жауаб биреб айткян: кит Миннян, шайтан! жазылган ич: Ходай Аллаңа башыр, бер Аңар гна кызмят ит  диб, дигян.

9 Аннары шайтан Аны Іерусалимга алыб барган; анда чиркяў тюбясенен кырыйына бастырыб, Аңар айткян: ăгяр Син Алла Улы булсаң, мыннан тюбян сикер;

10 Жазылган ич: Сине Ўз пяриштяляреня саклатыр;

11 Алар Сине кулларына кютяреб барырлар, аягың ташка сөртөнмяс, диб.

12 Іисусъ аңар жауаб биреб айткян: тагы айтелгян ич: Алла Ходайыңны сынама диб, дигян.

13 Бөтөнняй сынаб бетергяч, шайтан Анын жаныннан бер-ауыкка чаклы киткян.

14 Аннары Іисусъ тын кыуатына тулыланыб, Галилеяга кайткан; Анын турысында хабяр шундагы бөтөн тирягя жяйелгян.

15 Ул аларны синагогаларында өйряткян; Аны барысыда даннаганнар.

Зач. 13.

16 Аннары Іисусъ асралган каласына Назаретка килгян; анда Ўз гадятенчя, суббота көннө синагогага кереб, укыр өчөн аяк өстөня торган.

17 Аңар Исаія пагамбяр княгясен биргянняр; Ул, княгяне ачыб, блай диб жазылган төшнө табкан:

18 Ходай Тыны Миндя; Ул Мине жарлыларга изге хабяр сөйлягря майлады, кайгылы кюңеллелярне төзятергя, тоткондагыларга котоласыларын, сукырларга кюря торган буласыларын айтергя, интеккянниярне иркенгя чыгарырга,

19 Ходайнын жакшы багытын сөйлягря Мине жибярде диб.

20 Аннары княгяне жабкан да, кызмятчегя биреб, утырган; синагогадагылар барысыда Аңар тегяляб караб торганнар.

21 Шунда Ул аларга айтя башлаган: княгядя сез эшеткян бу сюзляр бөгөн жиреня килде, дигян.

22 Барысыда Аңар: эйе, дөрөс, дигянняр.

Зач. 14.

Анын ауызыннан чыккан дяўлятле сюзляргя исляре китеб айтешкянняр: Бу Іосифъ улы төгөл ме суң? дигянняр.

23 Ул аларга айткян: сез Миңа онгай айтеля торган сюзне айтерсез: төзятеўче! Ўзеңне Ўзең төзят, мында да Ўзең ўскян жирдя, Капернаумда кылганыңны, без эшеткянне кыл диб айтмей калмассыз, дигян.

24 Тагы айткян: чыннаб айтямен сезгя; ўскян жирендя бер пагамбярне дя кабыл кюрмейляр.

25 Чыннаб айтямен сезгя: Илія пагамбяр кённярендя ӧч жыл да алты ай кюк бикляне́б торгач, буган жирдя дя каты ачлык булган чакта, Израилдя тол катыннар кюб булган,

26 Булса да Илія аларнын берсеня дя жибярелмягян, тик Сидонъ Сарептасындагы тол катынга гна (жибярелгян).

27 Тагы шулай Елисей пагамбяр багытында да Израилдя кутырлы тяннеляр кюб булган, аларнын берсе дя тазартылмаган, тик Сирія кешесе Нееманъ гна (тазартылган), дигян.

28 Мыны эшетеб, синагогадагы кешелярнен барысынында бик ачыулары килгян.

29 Шундук тороб, Аны каладан кыуыб чыгарганнар; калалары салынган таунын тюбясеннян тӧртӧб тӧшӧрӧйӧк диб, Аны шул тау тюбясеня алыб барганнар,

30 Ӓммя Ул аларнын урталарыннан ўтеб, читкя киткян.

Зач. 15.

31 Аннары Галилеядяге Капернаумъ каласына килеб, суббота кённярдя калыкны ӧйряткян.

32 Анын ӧйрятеўеня исляре киткян, Анын сӧйляўе кодрятле булган шул.

33 Синагогада шакшы тынны, женнянгян кеше бар икян; ул бик каты тауыш белян кычкырган:

34 Эй Іисусъ Назарянинъ! безгя теймя, бездя Синеӊ ней эшеӊ бар? Син безне бетерергя килгян; Син кем икянне белямен: Син Алланын Изгесе, дигян.

35 Іисусъ аӊар кисятеб айткян: дяшмя, анын эченнян чык! дигян. Жен шундук ул кешене синагога уртасында жыгыб, аӊар бер зыян да тейермейче, анын эченнян чыккан.

36 Барысына да куркыныч тӧшкян; ўз араларында айтешкянняр: бу ней хал? Ул кодрят белян, кыуат белян шакшы тыннарга куша, алар шундук чыгыб китяляр? дигянняр.

Зач. 16.

37 Шуннан суӊ Анын хабяре бӧтӧн тиря жакка жяйелгян.

38 Синагогадан чыгыб, Іисусъ Симонъ ӧйӧня кергян; Симонъ катынынын анасы тир кастасы белян бик азабланыб жата икян: шундук анын турысында Аӊар ўтенгянняр.

39 Ул анын катына килеб, тир кастасын туктаткан, каста шундук беткян. Ул шул сяттюк тороб, аларга кызмят итеб жӧргян.

40 Тӧрлӧ чир белян чирле кешеляре бар кешеляр барысыда, кояш байыган чакта, аларны Анын катына алыб киля башлаганнар. Ул äр-кайсынын ӧстӧня кулларын салыб, аларны тӧзяткян.

41 Кюбесенен эченнян женняр дя кычкырыб чыгыб, äйткянняр. Син Алла Улы Христосъ, дигянняр. Äммя Ул аларга: Ул Христосъ икянне белгянняребн äйтергя кушмаган.

42 Кӧн башлангач, Ул ӧйдян чыгыб, буш жиргя киткян. Калык Аны эзлей барган. Анын катына килгяч, бездян китмясяня диб, Аны жибярмей торганнар.

43 Äммя Ул аларга äйткян: Мин бютян каладагыларга да Алла Падшалыгынын изге хабярен сӧйляргя тейеш, Мин шуңар жибяреддем шул, дигян.

44 Аннары Галилеядяге синагогаларда сӧйляб жӧргян.

5-нче бюлем.

Зач. 17.

1 Бер табкыр, Алла сюзен эшетер ӧчӧн, Іисусъ жанында калык тыгызланган чакта, Ул Геннисаретъ кюле жанында икян.

2 Шунда Ул кюл ӧстӧндя торган ике кайыкны кюргян; балыкчылар кайыкларыннан чыгыб, ауларын жыуалар икян.

3 Кайыкларнын берсеня, Симонныкыңар кереб, Іисусъ аңар жардан бер-ауык жир китяргя кушкан; аннары, кайыкта утырган кӧйӧ, калыкны ӧйряткян.

4 Ӧйрятеб туктагач, Симонга äйткян: тугайгарак кит тя, ауыгызны сӧзяр ӧчӧн салыгыз, дигян.

5 Симонъ Аңар жауабка äйткян: эй Ӧйрятеўче! без тӧнӧ буйы тырыштык, тик бер нястя дя тота алмадык; алайда Синең сюзең буйынча, ауны салыйым, дигян.

6 Шулай кылгач, алар бик кюб балык тотканнар, кюблектян аулары жыртыла башлаган.

7 Аннары икенче кайыктагы иптяшляреня, булышырга килсенняр диб, кул айкаганнар. Алар килгянняр дя ике кайыкны да тутырганнар, кайыклары батарлык булган.

8 Мыны кюреб, Симонъ Петръ Іисуснын тезеня башырыб äйткян: эй Ходай! минем катымнан чыксана, мин жазыклы кеше шул, дигян.

9 Шул хатле балык тотканнарыннан анын ўзеня дя, анын белян бергя булганнарнын барысынада бик куркыныч тӧшкян.

10 Зеведей уллары, Симонъ иптяшляре Іаковъ белян Іоаннъ да (бик курыкканнар). Іисусъ Симонга айткян:курыкма, мыннан блай кешелярне тотоучы булырсын, дигян.

11 Аннары ике кайыкны да жарга чыгарыб, бар нястялярен дя калдырыб, Іисуска эяреб киткянняр.

Зач. 18.

12 Іисусъ бер калада чагында, бӧтӧн тяне кутырлаган бер кеше килеб, Іисусны кюреб, жӧз тюбян жыгылыб, Аҥар блай диб ўтенгян: эй Ходай! телясяҥ, Син мине тазарта алыр ыйыҥ, дигян.

13 Іисусъ кулын сузыб аҥар тейенеб айткян: телеймен, тазарын дигян. Шул сяттюк анын кутырлары койолган.

14 Іисусъ аҥар беряўгя дя айтергя кушмаган, тик священниккя барыб кюренеб, аларга таныклыкка, Моисей кушканча, тазарганы ӧчӧн корман китерергя кушкан.

15 Алай булсада Анын турысында сюз бигряк тя жяйелгян. Аны тыҥнар ӧчӧн, чирляреннян тӧзялер ӧчӧн, Анын катына бик кюб калык жыйылышкан.

16 Ӓммя Ул буш жирляргя китеб, теляк иткян.

Зач. 19.

17 Бер дя бер кӧннӧ, Іисусъ ӧйряткян чагында, шунда Галилеянен дя, Іудеянен дя тӧрлӧ жирляреннян, Іерусалимнян килгян фарисейляр, законга ӧйрятеўчеляр дя бергя утырганда, чирле кешеляр тӧзялгяннян Ходайнын кыуаты кюреня торган.

18 Шунда бер-ауык кешеляр бер сансыз кешене тюшяге белян кютяреб китергянняр дя, аны ӧйгя алыб керергя, Іисусъ алдына салырга тырышканнар.

19 Калык кюблектян аны кертер жул табмагач, ӧй тюбясеня менгянняр дя тюбяне ачыб, сансызны тюшяге белян уртага Іисусъ алдына тӧшӧргянняр.

20 Іисусъ аларнын ышаныуын кюреб, ул кешегя айткян:сиҥа жазыкларын кичереля, дигян.

21 Князячеляр белян фарисейляр ўз аралый уйлаша башлаганнар: бу Алланы курлаучы кем икян? бер Алладан бютян кем жазыкларны кичеря алыр? дигянняр.

22 Іисусъ, аларнын уйларын белеб, аларга жауаб биреб айткян: сез кюҥелегездя ней уйлыйсыз?

23 Ней асатрак айтергя: сиҥа жазыкларыҥ кичереля диб ме, ӓлля тор да жӧрӧ диб ме?

24 Äммя Äдям Улынын жир öстöндя жазыклар кичерергя кыуаты барын сез белсен диб, (äйтямен дигян дя) сансызга äйткян: синга äйтямен: тор да урныгны алыб, öйöня кайт, дигян.

25 Ул шул сяттюк аларнын кюз алдында тороб, жаткан урнын алган да Алланы даннаб, öйöня кайтыб киткян.

26 Барысыда бик куркышканнар; Алланы даннаганнар, котлары чыгыб äйтешкянняр: без бöгöн ис китярлек эшляр кюрдек, дигянняр.

Зач. 20.

27 Шуннан суң Іисусъ чыккан да сатлык мал акчасы жыя торган тöштя утыра торган Левій атлы мытарны кюреб, аңар äйткян: Минем артымнан бар, дигян.

28 Ул бар нястясен калдырган да тороб, Аңар эяреб киткян.

29 Левій ÿз öйöндя Анын öчöн зур сый жасаган; анда кюб мытарлар, бютян кешеляр дя алар белян бергя утырганнар.

30 Княгячеляр белян фарисейляр зарланыб, Анын öйрянеÿчеляреня äйткянняр: сез ник мытарлар белян, жазыклылар белян бергя ашыйсыз, эчясез? дигянняр.

31 Іисусъ аларга жауабка äйткян: лекарь сауларга киряк тöгöл, äммя ауырыуларга киряк.

32 Мин жазыклыларны тяÿбягя öндяргя килдем, äммя гаделлярне тöгöл, дигян.

Зач. 21.

33 Алар Аңар äйткянняр: Іоаннъ öйрянеÿчеляре дя, фарисейляр öйрянеÿчеляре дя ней öчöн онгай ураза тоталар, теляк тя итяляр, äммя Синекеляр ашыйлар да, эчяляр дя? дигянняр.

34 Ул аларга äйткян: туйдагы кодаларга кеяÿ алар белян бергя чагында, ураза тоттора алырсыз мы?

35 Äммя алардан кеяÿ алыныр кöнняр килеб житяр, житкяч, шул кöннярдя алар ураза тотарлар, дигян.

36 Шунда аларга мясял äйткян: беряÿ дя жаңа кейемнян жыртыб алыб, иске кейемгя жамау салмый, салса, жаңа кейемне бозар, жаңа кейемнян алган жамауы иске кейемгя килешмяс.

37 Жаңа аракыны да беряÿ дя иске турсыкка салмый, жугыйса жаңа аракы турсыкны айырыр да, ÿзе дя агар, турсык та äрям булыр.

38 Äммя жаңа аракыны жаңа турсыкка салырга тейеш, аннары алар икесе дя бöтöн кöйö торорлар.

39 Тагы беряÿ дя иске аракыны эчкяч тя, шундук жаңа аракы эчясе килмяс, искесе жакшырак шул, дирер.

6-нчы бюлем.

Зач. 22.

1 Пасханын икенче кӧнӧннян сунгы субботанын элекесендя, Іисусъ ашлык басыуыннан ӱтеб барган чагында, Анын ӧйрянеӱчеляре ашлык башларын ӧзӧб, куллары белян ыуыб ашыйлар икян.

2 Фарисейлярнен кайсылары аларга айткянняр: ник сез суббота кӧннӧ кыларга тейеш тӧгӧлнӧ кыласыз? дигянняр.

3 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: Давидъ ӱзе дя анын белян булган кешеляр дя ачыккач, ул ней кылганны укымадыгыз мы ӓлля?

4 Ничек ул Алла ӧйӧня кереб, священниклярдян башка бютян бер кешегя дя ашарга тейеш тӧгӧл китереб куйылган икмяклярне алыб, ӱзе дя ашаб, анын белян булганнарга да биргян дигян.

5 Аннары аларга айткян: Ӓдям Улы субботага да башлык, дигян.

6 Ул тагы ӱнгя суббота кӧннӧ синагогага кереб ӧйряткян. Анда уӊ кулы короган бер кеше бар икян.

7 Князячеляр белян фарисейляр Іисуснын айыбын табар ӧчӧн, Ул суббота кӧннӧ тӧзятмяс ме диб, Аны караб торганнар.

8 Ӓммя Ул аларнын уйларын белеб, кулы короган кешегя айткян: тор да уртага чык, дигян. Ул торган да чыккан.

9 Шунда Іисусъ аларга айткян: Мин сездян соройом: суббота кӧннӧ ней кыларга тейеш: жакшылык мы, ӓлля усаллык мы? жанны сакларга тейеш ме, ӓлля ӓрям итяргя ме? дигян.

10 Алар дяшмягянняр. Аннары аларнын барысынада айлянеб караган да ул кешегя айткян: кулыӊны суз, дигян, ул шулай иткян, шундук кулы икенчесе кюк сау булган.

11 Аларнын бик каты ачыулары килеб, ӱз араларында Іисуска ней кылыйык икян дейешкянняр.

Зач. 23.

12 Шул кӧннярдя Іисусъ теляк теляргя тау ӧстӧня менеб, тӧнӧ буйы Аллага теляк итеб ӱткязгян.

13 Кӧн булгач, Ӱз ӧйрянеӱчелярен чакырыб, алар арасыннан ун икене сайлаб, аларны апостолъ диб атаган:

14 Ӱзе Петръ диб атаган Симонны сайлаган, анын энесе Андрейне, Іаковны, Іоанны, Филиппны, Варѳоломейне,

15 Матѳейне, Ѳоманы, Алфей улы Іаковны, Зилотъ дигян Симонны,

16 Іаковъ улы Іуданы, Искаріотъ Іудасын, шушысы суӊыннан тотоб биреӱче булган.

Зач. 24.

17 Алар белян таудан тӧшӧб, Іисусъ бер тигез жирдя туктаб торган, анда ӧйрянеӱчеляренен дя кюбесе, тагы бӧтӧн Іудеядан, Іерусалимнан, дингез жанындагы Тиръ белян Сидонъ жирляреннян килгян кюб калык та (туктаб торганнар).

18 Алар Аны тынӷнар өчөн, чирляреннян сауыгыр өчөн килгянняр, тагы шулай женняр азабландыра торган кешеляр дя (килгянняр); алар сауыкканнар.

19 Іисустан кыуат чыгыб, барысында төзяткянгя кюря, бар калык та Аӈар тейенергя тырышкан.

20 Ул кюзлярен өйрянеӳчеляреня таба кютяреб караб, айтя башлаган: жыуаш кюӈеллеляр бахетле, Алда Падшалыгы сезнеке шул.

21 Äле ачыгыучылар бахетле, сез тукланырсыз шул. Äле жылаучылар бахетле, сез кюӈеллелянерсез шул.

22 Äдям Улы өчөн сезне кешеляр кюрялмасалар, сезне айырыб жибярсяляр, сезне курласалар, исемегезне жаман итеб жяйелтсяляр, сез бахетле.

23 Шул көннө сөйөнөгөз, кыуаныгыз, сезгя кюктя сауаб бик оло шул. Аларнын аталары пагамбярляргя шулай кылганнар.

Зач. 25.

24 Эй байлар, сезгя читен булыр, сез инде ӳзегезгя теясе жыуанычны алдыгыз шул.

25 Эй äле туйыныб беткянняр, сезгя читен булыр, сез ачыгырсыз шул. Эй äле көлөӳчеляр, сезгя читен булыр, сез сулкылдаб жыларсыз шул.

26 Бар кешеляр дя сезне жакшы диб сөйляшсяляр, сезгя читен булыр, аларнын аталары жалган пагамбярляргя шулай иткянняр шул.

27 Äммя сез тынӷнаучыларга äйтямен: дошманнарыгызны сөйөгөз, сезне кюрялмый торганнарга жакшылык кылыгыз;

28 Сезне каргаучыларга арыулык телягез, сезне кыйырсытыучылар өчөн теляк итегез.

29 Жаӈагыӈа суккан кешегя икенче жаӈагыӈны да бороб тот; ирексезляб синеӈ өст кейемеӈне алыучыга кюлмягеӈне алырга да ирек бир.

30 Синнян сораучыга äр-кемгя бир, äйбереӈне алган кешедян кайтарыб сорама.

Зач. 26.

31 Сезгя кешеляр ней кылганны телясягез, ӳзегез дя аларга шулай кылыгыз.

32 Äгяр сез ӳзегезне сөйгяннярне гня сөйсягез, сезгя анын өчөн нейдей сауаб булсын? ӳзлярен сөйгяннярне жазыклылар да сөяляр ич.

33 Äгяр ӳзегезгя жакшылык кылганнарга гна жакшылык кылсагыз, сезгя анын өчөн ничек сауаб булсын? жазыклылар да шулай кылалар ич.

34 Ӓгяр бурычны кире кайтарыб алырбыз диб ышаныб торган кешелярегезгя гня бирсягез, анын ӧчӧн сезгя нейдей сауаб булсын? жазыклы кешеляр дя биргян бурычларын кире алыр ӧчӧн жазыклы кешеляргя бурыч биряляр ич.

35 Ӓммя дошманнарыгызны сӧйӧгӧз, жакшылык кылыгыз, бер нястя дя кӧтмӧйче бурычка бирегез, сезгя бик оло сауаб булыр. Жугарыгынын уллары булырсыз. Ул шу тау итмей торганнарга да, усалларга да изгелекле.

36 Инде айсаҥ Атагыз ничек изгелекле, сез дя шулай изгелекле булыгыз.

Зач. 27.

37 Тикшермягез, сезне дя тикшермясляр; айыбламагыз, сезне дя айыбламаслар; кичерегез, сезгя дя кичерелер.

38 Бирегез, сезгя дя бирелер: сезгя кайтарган чагында сауытыгызга ӱлчяӱне тутырыб, селкеб, тыгызлаб, тюбялямя итеб салырлар; сез ничек ӱлчяӱ белян ӱлчясягез, сезгя дя шундый белян ӱлчянер шул, дигян.

39 Аларга тагы мясял айткян: сукыр сукырны житякляб жӧртя алыр мы? икесе дя чокорга жыгылырлар тӧгӧл ме?

40 Ӧйрянеӱче ӧйрятеӱчесеннян оло булмый, бӧтӧнняй ӧйрянеб житкяч тя, ӓр-кем тик ӧйрятеӱчесе кюк кня булыр.

41 Ник туганыҥ кюзендяге ботакка карыйсын, ӓммя ӱз кюзеҥдяге бюряняне сизмейсен?

42 Жя ӱз кюзеҥдяге бюряняне кюрмягяч, син туганыҥа: эй туган! кая мин синеҥ кюзеҥнян ботакны алыйым диб ничек айтя алырсын? Эй кюз алдында гна кылыныучы! элеке ӱз кюзеҥдяге бюряняне ал, аннары туганыҥнын кюзендяге ботакны алырга да кюрерсен.

43 Начар жимеш китеря торган жакшы агач жук, жакшы жимеш китеря торган начар агач та жук;

44 Ӓр-бер агач ӱз жимешеннян беленя шул. Чянечкеле агачтан смоква жыймыйлар, кыуактан да жӧзӧм жыймыйлар.

45 Жакшы кеше ӱзенен жакшы кюҥел сауытыннан жакшыны чыгара, ӓммя жаман кеше ӱзенен жаман кюҥел сауытыннан жаманны чыгара: анын ауызы кюҥел тулылыктан сӧйлӧй шул.

Зач. 28.

46 Ник Мине: Ходай, Ходай диб айтясез, ӓммя ӱзегез Мин айткянне кылмыйсыз?

47 Минем катка килеб, сюзляремне тыҥнаб, аларны кылыучы ӓр-кемнен кемгя ошаулы икянен сезгя айтейем:

48 Ул жир казыб, тирян итеб, таш нигез салыб, анын öстöня öй торгозган кешегя ошаулы; сыу ташыб, шул öйгя бярелгян икян, бярелся дя, нигезен таш öстöня корганга кюря, ул öйнö урныннан кузгата алмаган.

49 (Сюземне) тынӷнаб тороб, кылмаган кеше, öйнö нигезсез кöйö коро жиргя гня салган кешегя ошаулы; сыу ташыб, ул öйгя бярелгян икян, шул сяттюк ул öй ауыб, бöтöнняй жимерелеб беткян.

7-нче бюлем.

Зач. 29.

1 Іисусъ тынӷнаган калыкка шул сюзлярен барында äйтеб бетергяч, Капернаумга кергян.

2 Бер сотникнын бик жараткан кызмятчесе чирляб, ӱлярлек булыб жата икян.

3 Іисусъ турысында эшетеб, ул Анӷар кызмятчесен килеб тöзятсен эйе диб, Аны чакырырга Іудейлярнен калык башлыкларын жибяргян.

4 Алар Іисусъ катына килеб, Анӷар бик ӱтенеб äйткянняр: Син анӷар мыны кыларга ул тейешле,

5 Ул безнен калыкны сöя шул, безгя синагога да салыб бирде, дигянняр.

6 Іисусъ алар белян киткян. Öйгя барыб житяргя бер аз калгач, сотникъ Анӷар дусларын жибяреб äйттергян: эй Ходай! килеб борчолма, Син минем öйöмя керергя мин тейешле тöгöл шул.

7 Шунӷар кюря мин ӱземне ӱзем Синенӷ катынӷа барырга тейешле кюрмядем. Äммя Син сюз гня äйт, кызмятчем сауыгыр.

8 Мин шу ӱзем кеше кул астындагы кеше булсам да, ӱз кулымда салдатлар тотам; берсеня: бар дисям, бара; икенчесеня: кил дисям, киля; кызмятчемя: мыны кыл дисям, ул кыладыр, дигян.

9 Іисусъ мыны эшетеб, анӷар исе киткян; Ӱз артыннан килгян калыкка боролоб äйткян: сезгя äйтямен, Израилдя дя Мин бу хатле ышаныуны очратмадым, дигян.

10 Жибяргян кешеляр öйгя кайткач, чирле кызмятчене сау очратканнар.

Зач. 30.

11 Шуннан сунӷ Іисусъ Наинъ дигян калага барган; Анын белян бергя öйрянеӱчеляренен дя кюбесе, калыкнын да кюбесе барганнар.

12 Ул кала кабкасына жакыннашкан чагында, бер ӱлекне, ананын бердян бер улын кютяреб чыгыб киляляр икян; ул катын тол икян; анын белян бергя каладан кюб калык килгян.

13 Катынны кюреб, Ходай аны кызганыб, анӷар: син жылама дигян.

14 Аннары жакын килеб, ўлекне итя торган урынга тейенгян; кютяреб барыучылар туктаганнар. Іисусъ айткян: эй жегет, сиңа айтямен, тор! дигян.

15 Ўлек тороб утырган да сойляшя башлаган; Іисусъ аны анасына биргян.

16 Барысынада куркыныч тошкян; Алланы даннаб айткянняр: безнен арада оло пагамбяр кюренде, Алла Ўз калкына изгелек итте, дигянняр.

Зач. 31.

17 Іисусъ турысында былай дейеў ботон Іудеяга, буган жяняшя тирягя жяйелгян.

18 Быларнын барысында ойрянеўчеляре Іоаннга кайтыб белдергянняр.

19 Іоаннъ ўз ойрянеўчеляренен икесен чакырыб, Іисуска жибяреб, сораткан: Килясе дигян Син ме, ăлля бютянне котойок ме? диб.

20 Алар Іисуска килеб айткянняр: Чумылдырыучы Іоаннъ безне Сиңа: Килясе дигян Син ме, ăлля бютянне котойок ме? диб сорарга жибярде, дигянняр.

21 Шул чакта Іисусъ кюб кешелярне чирляреннян, жараларыннан, жаман тыннарыннан тозяткян, кюб сукырларны да кюря торган иткян.

22 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: барыгыз, кайтыб, Іоаннга ней кюргянегезне, ней эшеткянегезне айтегез: сукырлар кюря торган булалар, аксаклар (тозок) жоройляр, кутырлы тяннеляр тазаралар, саңраулар эшетяляр, ўлекляр тереляляр, жарлылар изге хабяр сойлойляр диб.

23 Ăммя Минем турда шиклянмягян кеше бахетле, дигян.

24 Аннары Іоаннын жибяргян кешеляре киткяч, Іисусъ калыкка Іоаннъ турысында айтя башлаган: сез буш кырга ней кюрергя бардыгыз? жилдян тирбянгян камышны мы?

25 Суң ней кюрергя бардыгыз? жомошак кейем кейгян кешене ме? асыл кейем кейеб, кубшы тороучылар падша жортонда торалар ич.

26 Суң ней кюрергя бардыгыз? пагамбярне ме? Эйе, сезгя айтямен: пагамбярдян дя олоно.

27 Мына Мин Синең алдыңнан Ўз пяриштямне жибярямен, ул Синең алдыңнан жулыңны ăзерляб куяр диб жазылган ўзе шушы.

28 Мин сезгя айтямен: катыннардан тыуганнар арасында Чумылдырыучы Іоаннан оло пагамбяр беряў дя жук, ăммя Алла падшалыгындагыларнын иң кечесе аннан оло, дигян.

29 Тыңнаб торган бар калык та, мытарлар да Іоаннъ чумылдырыуы белян чумылдырылыб, Алла иркен жиреня китергянняр.

30 Äммя фарисейляр, законъ белеÿчеляр Іоаннан чумылдырылмыйчы, ÿз турыларындагы Алла иркен кабыл алмаганнар.

Зач. 32.

31 Ходай айткян: бу тыума кешелярен кемгя ошатыйым? алар кемгя ошаулы?

32 Алар урамда утырыб, бер берсеня кычкырыучы балаларга ошой; алар айтяляр: без сезгя сыбызгы уйнадык, сез бейемядегез; без сезгя жыларлык жырыулар жырладык, сез жыламадыгыз дейляр.

33 Чумылдырыучы Іоаннъ килде, икмяк тя ашамый, аракы да эчмей; сез анда жен бар дейсез.

34 Äдям Улы килде, ашый да, эчя дя; сез айтясез: мына ашауны, эчемнек эчеÿне жарата торган кеше, мытарларнын, жазыклы кешелярнен дусы, дейсез.

35 Белемнекне ÿз оланнары барысыда дöрöсляделяр, дигян.

Зач. 33.

36 Фарисейлярнен берсе Іисусны ÿзе белян бергя аш ашарга чакырган. Ул фарисей öйöня кереб утырган.

37 Мына шул каладагы бер жазыклы катын, Анын фарисей öйöня кереб утырганын белеб, алавастръ сауыт белян мvро алыб килгян;

38 Килгяч, Анын артында аягы катында тороб, жылый-жылый кюз жяшен Анын аякларына койоб, чяче белян сöрткян, сöрткяч, аякларын ÿбеб, мvро белян майлаган.

39 Іисусны чакырыучы фарисей мыны кюреб, эченнян гня айткян: äгяр Бу пагамбяр булса, Аӊар кем тейенгянне, нейдей катын тейенгянне белер эйе, ул жазыклы катынна баса, дигян.

40 Іисусь Аӊар боролоб айткян: Симонъ! Минем сиӊа бер нястя айтясем бар, дигян. Ул айткян: эй Öйрятеÿче, айт, дигян.

41 Іисусъ айткян: бер бурычка биреÿченен бурычлы ике кешесе бар икян: берсенен биш жöз динарій бирясе бар икян, äммя икенчесенен илле динарій.

42 Аларнын тюляр нястяляре булмагач, ул икесеня дя кичергян. Инде айтче, аны кайсысы кюберяк сöяр? дигян.

43 Симонъ жауаб биргян: кюберяк кичергяне диб уйлыймын дигян. Ул аӊар айткян: син дöрöс айттеӊ, дигян.

44 Аннары катынга таба боролоб, Симонга айткян: син шушы катынны кюрямесен?. Мин синеӊ öйöӊя килдем, син Миӊа аягымны жыуарга сыу да бирмядеӊ, äммя ул Минем аякларыма кюз жяшен койоб, чяче белян сöрттö.

45 Син Мине ўбмядеҥ, ӓммя ул Мин килгяннян бирле аякларымны туктаусыз ўбя.

46 Син Минем башымны май белян дя майламадыҥ, ӓммя ул Минем аякларымны мvро белян майлады.

47 Шуҥар кюря сиҥа айтямен: кюб сӧйгяненя кюря, анын кюб жазыклары да кичереля; ӓз кичерелгян кеше, сӧйӧўендя ӓз сӧя, дигян.

48 Катынга айткян: сиҥа жазыкларыҥ кичереля, дигян.

49 Шунда Анын белян бергя утырыучылар ўз аралый сӧйляшя башлаганнар: бу кем, жазыкларны да кичеря? диб.

50 Ӓммя Ул катынга айткян: сине ышаныуыҥ коткарды; тынычлык белян кайт, дигян.

8-нче бюлем.

Зач. 34.

1 Шуннан суҥ Іисусъ калаларда, ауылларда Алла Падшалыгынын арыу хабярен сӧйляб жӧргян, Анын белян бергя ун ике ӧйрянеўчесе дя.

2 Тагы жаман тыннардан, чирляреннян Ул тӧзяткян катыннарнын да кайсылары (жӧргянняр): эченнян жиде жен чыккан Магдалина Марія,

3 Иродъ жортон караб тороучы Хузанын катыны Іоанна, Сусанна, тагы бютян кюб катыннар да Аҥар ўз маллары белян булышыб жӧргянняр.

4 Кюб калык жыйылышкач, Аҥар бар калалардан да кешеляр килгяч, Ул мясял айткян:

Зач. 35.

5 Чячеўче орлогон чячяргя чыккан; чячкян чагында кайсысы жул читеня тӧшкян дя табталган, аны ауа кошлары да чюбляб бетергянняр.

6 Кайсысы таш ӧстӧня тӧшкян, ул тишелгяч тя, дымы булмаганга кюря, короган.

7 Кайсысы тигяняк арасына тӧшкян, тигяняк ўсеб, аны баскан.

8 Кайсысы жакшы жиргя тӧшкян, шунда ўсеб, бер бӧртӧккя жӧз бӧртӧк китергян, дигян. Мыны сӧйлягяч, кычкырыб айткян: эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

9 Ӧйрянеўчеляре Аннан: бу мясял ней белдеря? диб сораганнар.

10 Ул айткян: сезгя Алла Падшалыгынын жяшереклярен белергя бирелгян, ӓммя бютянняргя мясялляр белян айтеля, алар караб та кюрмейляр, эшетеб тя аҥнамыйлар.

11 Бу мясял мына мыны белдеря: орлок дигяне Алла сюзе.

12 Жул читеня тӧшкяне шушындыйларны белдеря: алар тыҥныйлар, аннары ышаныб котолмасыннар диб, шайтан килеб, аларнын кюҥеленнян сюзне алыб китя.

13 Таш őстőня тőшкяне мындыйларны белдеря: алар сюзне эшетеӯ белян, сőйőнőб кабыл алалар, тик тамырлары жукка кюря, бер ауыкка ышаналар, ӓммя сыналганда бизяляр.

14 Тигяняклеккя тőшкяне мындыйларны белдеря: алары сюзне тыӊныйлар, тик киткячтен, дőнья сагышлары, байлык, тормош рахатлекляре аларны басыб бетеряляр, шунныктан алар жимеш китермейляр.

15 Жакшы жиргя тőшкяне шушындыйларны белдеря: кайсы кешеляр сюзне эшеткяч, аны арыу, таза кюӊеллярендня саклыйлар да тюземнек белян жимеш китеряляр, дигян. Мыны сőйлягяч, Ул кычкырыб ӓйткян: эшетергя колагы бар кеше эшетсен диб.

Зач. 36.

16 Беряӯ дя эшямне жандыргач, сауыт белян каблмый, жя карауат астына куймый, ӓммя кереӯчеляр жактыны кюрсен диб, эшямдялгя утырта.

17 Кюренмей каласы бер жяшерен дя жук, жяшереб куйганнын да беленмейче, кюренмейче каласы жук.

18 Инде айса тыӊнауыгызга аӊ салыгыз; барга бирелер, ӓммя жуктан бар кюк тейгян нястясе дя алыныр шул, дигян.

19 Шунда Аӊар анасы белян агалары килгянняр, тик калык булганныктан, Аӊар жакын киля алмаганнар.

20 Аӊар белдергянняр: анаӊ белян агаларыӊ Сине кюряселяре килеб, тышта торалар, дигянняр.

21 Ул аларга жауаб биреб ӓйткян: Миӊа ана, Миӊа агалар Алла сюзен тыӊнаучылар, аны кылыучылар, дигян.

Зач. 37.

22 Бер дя бер кőннő Іисусъ ӱз őйрянеӱчеляре белян кимягя кереб, аларга ӓйткян: кюлнен теге жагына кичейек, дигян. Шундук киткянняр.

23 Барган чакларында, Ул жокога киткян. Кюл őстőндя дауыллы жил кютярелгян, аларга тулкыннар чайпыла башлаган, хатяр халдя булганнар.

24 Жанына килеб, Аны уятыб, ӓйткянняр: эй Őйрятеӱче, Őйрятеӱче! бетябез, дигянняр. Ӓммя Ул тороб, жилне дя, сыу тулкыннаныуын да тыйган; алар басылган, тыб-тыныч булган.

25 Аннары Ул аларга ӓйткян: сезнен ышаныуыгыз кая? дигян. Алар куркышыб, исляре китеб, бер берсеня ӓйтешкянняр: Бу кем бу? жилгя дя, сыуга да куша, алар Аны тыӊныйлар, дигянняр.

Зач. 38

26 Галилея карышысындагы Гадара жиреня килгянняр.

27 Іисусъ жарга чыккач, Аны кала кешеляренен берсе очраткан. Ул кеше кюбтяннян бирле женнянеб, кейем киймейче, ӧйдя тормойчы каберлярдя тора икян.

28 Ул, Іисусны кюреб, кычкырган, Аңар жыгылыб башырыб, каты тауыш белян айткян: эй жугарыгы Алланын Улы Іисусъ, Синеҥ миндя ней эшеҥ бар? мин Сиҥа тилмерямен,мине азабламасана, дигян.

29 Іисусъ шакшы тынга шул кешедян чыгарга кушкан икян, ул аны кюб жылдан бирле азаблаган шул; аны чылбыр белян бяйляб, быгаулаб, саклаганнар; äммя ул чылбырларын ӧзгян; жен аны буш кырларга кыуыб жӧрткян.

30 Іисусъ аннан сораган: син ней атлы? дигян. Ул айткян: легіонъ, дигян; анын эченя бик кюб женняр кергян икян шул.

31 Женняр Іисуска: безне тӧбсӧз жиргя китяргя кушмасана диб ӱтенгянняр.

32 Шундук тау ӧстӧндя зур табын дунгыз кӧтӧӱе кӧтяляр икян; женняр Іисуска: безгя шушы (дунгызларга) керергя бойорсана диб ӱтенгянняр. Ул аларга роксят биргян.

33 Женняр кешедян чыгыб, дунгызларга кергянняр; шундук кӧтӧӱ текя жардан кюлгя атылыб батыб беткян.

34 Кӧтӧӱчеляр, былай булганны кюргяч, жӧгӧрӧб киткянняр дя калага да, ауылларга да барыб белдергянняр.

35 (Кешеляр) ней булганны кюрергя чыкканнар; Іисусъ катына килгяч, эченнян женняр чыккан кешенен Іисуснын аягы жанында кейенеб, акыллы утырганын очратыб, бик куркышканнар.

36 Кюреӱчеляр женнянгян кешенен ничек тӧзялгянен аларга айткянняр.

37 Гадара тирясендяге бар калык Іисуска: бездян китя кюрсяня диб ӱтенгянняр; аларга бик зур куркыныч тӧшкян икян шул. Іисусъ кайыкка утырыб, кире киткян.

38 Эченнян женняр чыккан кеше Іисуска: мин Синеҥ белян булыр ыйым диб ӱтенгян; äммя Іисусъ аны жибяреб айткян:

39 Ӧйӧҥя кайт, сиҥа Алла ней кылганны айтеб бир, дигян. Ул китеб, бӧтӧн калага Іисуснын аңар ней кылганын айтеб жӧргян.

Зач. 39.

40 Іисусъ кире кайткач, калык Аны кабыл алган, Аны барысыда кӧтӧб торганнар икян.

41 Шунда синагога башлыгы Іаиръ атлы кеше килгян дя Іисуснын аягы астына жыгылыб, Аңар: ӧйӧмя керсяня диб инялгян.

42 Іаирнын ун ике жяшлярдя бер гня кызы бар икян, ул да ӱляр чигендя жата икян. Іисусъ барган чагында, калык Аңар тыгыз иткян.

43 Шунда ун ике жылдан бирле кан агыуы белян азаблана торган бер катын булган; ул бар малын лекарляргя биреб бетергян, тик ич берсе дя аны тӧзятя алмаган;

44 Ул арттан килеб, Іисуснын кейеменен итягеня тейенгян, шул сяттюк кан агыуы туктаган.

45 Іисусъ айткян: Минга кем тейенде? дигян. Барысыда мин тӧгӧл дигяч, Петръ да Анын белян бергя булганнар да айткянняр: эй Ойрятеўче, Сине калык жак жактан тыгызлый ич, аммя Син Минга кем тейенде дисен.

46 Іисусъ айткян: Минга беряў тейенде, Мин Ўземнян чыккан кыуатны сиздем, дигян.

47 Катын, ўзенен жяшеренеб кала алмаганын кюреб, калтраб килеб, Ангар жыгылыб башырган да бар калык алдында ўзенен Ангар ней сябяблей тейенгянен, тейенгяч тя тӧзялгянен айткян.

48 Іисусъ ангар айткян: эй кызым, нык тор, ышаныуың сине коткарды, тынычлык белян кайт, дигян.

49 Іисусъ мыны айткян чакта, синагога башлыгына ойӧннян беряў килеб айткян: кызың ўлде, Ойрятеўчене ошяндермя, дигян.

50 Аммя Іисусъ мыны эшетеб, ангар айткян: курыкма, тик ышан гна, (кызың) котолор, дигян.

51 Ойӧня баргач, бер кешене дя кертмягян, тик Петрны, Іоанны, Іаковны, аннары кызнын атасы белян анасын гна (керткян).

52 Анын ӧчӧн барысыда жылашалар, ўкерешяляр икян. Аммя Іисусъ айткян: жылашмагыз, ул ўлмягян, тик жоклаб кна жата, дигян.

53 Алар кыз ўлгянне белеб, Іисустан кӧлгянняр.

54 Ул барысын да чыгарыб, кызнын кулыннан тотоб дяшкян: эй кыз, тор! дигян,

55 Шундук кызнын тыны кире кайткан; ул шул сяттюк торган. Іисусъ ангар ашарга бирергя кушкан.

56 Атасынын, анасынын исляре киткян. Ул аларга булган эшне ич беряўгя дя айтергя кушмаган.

9-нчы бюлем.

Зач. 40.

1 Іисусъ ун ике ойрянеўчесен чакырыб алыб, буган женнярне чыгарырга, чирлярне тӧзятергя аларга кыуат, кодрят биргян.

2 Аларны Алла Падшалыгын сойлягргя, чирлелярне тӧзятергя жибяргян.

3 Шунда Ул аларга айткян: жулга бер нястя дя алмагыз, таяк та, кабчык та, икмяк тя, кӧмӧш тя, икешяр кейемегез дя булмасын.

4 Бер-бер ойгя керсягез, шунда торогоз, шуннанук жулга чыгыгыз.

5 Ӓгяр дя бер-бер жирдя сезне кабыл алмасалар, сез шундагы каладан чыгышлый, аларга карышы таныклыкка аякларыгыздагы тупракны да селкеб тӧшӧрӧгӧз, дигян.

6 Алар китеб, ауылларда жӧрӧб, ӓр-бер жирдя изге хабяр сӧйлягянняр, (чирлелярне) дя тӧзяткянняр.

Зач. 41.

7 Дюртенче ӧлӧшнӧ биляб тороучы Иродъ, Іисуснын кылган эшлярен барысында эшеткяч, абтраб торган: кайсылары: бу Іоаннъ ӱлгян жиреннян терелеб torгандыр дигянняр;

8 Кайсылары: Илія килгяндер дигянняр, ӓммя кайсылары: боронго пагамбярлярнен берсе терелеб торгандыр дигянняр шул.

9 Иродъ ӓйткян: мин Іоаннын башын кистерттем, Бу, мин шундый эшлярен эшетя торган, кем икян суң? дигян. Аны кюрясе килеб жӧргян.

10 Апостоллар кайткач, ӱзляренен ней кылганнарын Іисуска ӓйткянняр. Ул аларны Ӱзе белян алыб, Виѳсаида дигян кала тирясендяге буш кырга аулакка киткян.

11 Калык мыны белеб, Анын артыннан барган; Ул калыкны кабыл алыб, аларга Алла Падшалыгы турысында сӧйлягян, чирлярен тӧзяттерясе килгяннярен тӧзяткян.

Зач. 42.

12 Кӧн кичкя ауыша башлаган. Ун ике (ӧйрянеӱчесе) Іисусъ жанына килеб, Аңар ӓйткянняр: калыкны жибярче, алар тиря жактагы ауылларга кунарга барыб, шунда ашарларына табсыннар, без мында буш кырда шул, дигянняр.

13 Ӓммя Ул аларга ӓйткян: аларга ашарга сез бирегез, дигян. Алар ӓйткянняр: безнен биш икмяк белян ике балыктан бютян нястябез жук, ӓлля без барыб, бу кешелярнен барысы ӧчӧн дя ашамнык сатыб алыйык мы? дигянняр.

14 Алар анда ирляр гня биш меңняб бар икян. Ӓммя Ул ӧйрянеӱчеляреня ӓйткян: быларны рятляб, ряте сайын иллешяр кеше итеб утыртыгыз, дигян.

15 Алар шулай иткянняр, барысында рятляб утыртканнар.

16 Ул биш икмякне, ике балыкны алыб, кюккя таба караб, аларны бахиллягян дя сындырыб, калыкка ӧляшергя диб ӧйрянеӱчелярня биргян.

17 Барысы да ашаб туйганнар; калган сыныкларны жыйыб, ун ике карнаша тутырганнар.

Зач. 43.

18 Бер багытта Іисусъ аулакта теляк иткян чакта, ӧйрянеӱчеляре дя Анын белян булганнар. Ул алардан сораган: калык Мине кем диб айтя? дигян.

19 Алар жауаб биреб айткянняр: Чумылдырыучы Іоаннъ диб, кайсылары Илія диб, кайсылары боронго пагамбярлярнен берсе терелеб торгандыр диб айтяляр, дигянняр.

20 Іисусъ аларга айткян: сез ӱзегез Мине кем диб белясез? дигян. Петръ жауаб биреб айткян: Алланын Христосы диб белябез, дигян.

21 Ул аларга каты кисяткян:мыны беряӱгя дя айтмягез, дигян.

22 Тагы айткян: Ӓдям Улы кюб азаб кюрясе, калык башлыклары, архіерейляр, княгячеляр Аны кабыл алмаслар, Ул ӱтерелясе, ӧчӧнчӧ кӧннӧ терелеб торасы, дигян.

Зач. 44.

23 Аннары барысынада айткян: Минем артымнан барасы килгян кеше, ӱз иркен кылыуны ташласын да качын алыб, Минем артымнан барсын.

24 Жанын сакласы килгян кеше, аны жуяр, ӓммя жанын Минем ӧчӧн жуйган кеше, аны саклар.

25 Кеше бӧтӧн дӧньяне сӧрӧб алса да, ӓммя ӱзен жугалтса, жя ӱзеня зыян китерся, аңар ней пайда?

26 Кем дя кем Миннян, сюзляремнян оялса, Ӓдям Улы да Ӱз ололmegында, Атасы олологында, арыу пяриштяляр олологында килгян чагында, аннан оялыр.

27 Мин сезгя чыннаб айтямен: мында тороучыларнын кайсылары Алла Падшалыгын кюрмейче ӱлмясляр, дигян.

Зач. 45.

28 Шушы сюзлярдян суң сигез кӧнняб ӱткяч, Іисусъ Петрны, Іоанны, Іаковны алыб, тау ӧстӧня теляк итяргя менгян.

29 Теляк иткян чагында, Анын жӧзӧ ӱзгяргян, кейеме агарыб, жалтраб торган.

30 Шунда ике ир Анын белян сӧйляшеб торганнар, былар Моисей белян Илія булган.

31 Алар ололок белян кюреneб, Аңар Іерусалимдя ней буласыны, Ул ней кыласыны сӧйляшкянняр.

32 Петрны да, анын белян булганнарны да жоко ауырайткан икян; алар уяныб китеб, Іисуснын ололоgон, тагы Анын белян бергя торган ике ирне дя кюргянняр.

33 Алар Іисусъ катыннан китя башлагач, Петръ Аңар айткян: эй Ӧйрятеӱче, безгя мында торорга жакшы; ӧч чатыр коройокчы: берне Сиңа, берне Моисейгя, берне Иліягя, дигян, ӱзе ней айткянен белмягян.

34 Ул мыны әйткян чагында, болот килеб, аларны кюлягялягян; болотка кергяч, алар бик курыкканнар.

35 Болоттан ауаз килгян: Шушы Минем сөйөклө Улым, Аны тыңнагыз диб.

36 Шул ауаз булган чагында Іисусъ жангызы гна калган. Өйрянеўчеляре мыны әйтмей торганнар, ней кюргянняреν шул көннярдя бер кешегя дя сөйляшмягянняр.

Зач. 46.

37 Икенче көннө, алар таудан төшкяч, Іисусны кюб калык очраткан.

38 Калык арасыннан беряў кинят кычкырыб әйткян: эй Өйрятеўче! Сиңа ўтенямен, улыма кюз салсана, ул минем беряў гня шул.

39 Аны жен тота, ул кинят кычкыра башлый, жен аны уатыб бетеря, ауызыннан кюбекляр чыгарта, аны бик азабландырыб, аннан азга гна китя.

40 Мин өйрянеўчеляреңя аны чыгартырга ўтенгян эйем, алар булдыра алмадылар.

41 Іисусъ жауаб биреб әйткян: эй ышаныусыз, азгын тыума! сезнен белян кайчанга чаклы торойом? кайчанга чаклы сезгя чыдыйым? Улыңны мында китер, дигян.

42 Ул килгян чагында, жен аны жыгыб, калтрата башлаган; Іисусъ шакшы тынга кисяткян, кисяткяч, жегетне төзятеб, аны атасына биргян.

43 Барысынын да Алланын ололоғына исляре киткян. Іисуснын бар кылган эшляреня барысынында исляре китеб торган чакта, Ул Ўз өйрянеўчеляреня әйткян:

Зач.47.

44 Сез бу сюзлярне колагыгызга салыгыз: Әдям Улы кешеляр кулына тотоб бирелер, дигян.

45 Тик алар бу сюзне аңнамаганнар, ул сюз аларга карангы булган; алар аны тойоб житкезмягянняр, әммя Аннан бу сюзне сорарга курыкканнар.

46 Аларга арабызда кайсыбыз оло икян диб уй төшкян.

47 Іисусъ аларнын кюңелляренндяге уйларын белеб, бер баланы алыб, аны Ўз алдында торгозоб,

48 Аларга әйткян: бу баланы Минем исемем какына кабыл алган кеше, Мине кабыл ала; әммя Мине кабыл алган кеше, Мине Жибяреўчене кабыл ала: арагызда кайсыгыз иң кече, шул оло дигян.

Зач. 48.

49 Шунда Іоаннъ әйткян: эй Өйрятеўче, без Синең исемең белян женнярне кыуалаб чыгарыучы кешене кюрдек тя, ул безнен белян жөрмягянгя кюря, без аны туктаттык, дигян.

50 Іисусъ аңар айткян: туктатмагыз, сезгя карышы тӧгӧл кеше, сезнен жаклы шул, дигян.

51 Дӧньядян китяр кӧнняре житя башлагач, Анын Іерусалимгя барасы килгян.

52 Ӯз алдыннан хабярчеляр жибяргян; алар китеб, Аны кабыл алырга ӓзерляр ӧчӧн, Самарія жирендяге бер ауылга кергянняр.

53 Тик Аны анда кабыл алмаганнар, Ул Іерусалимгя барыучы ряӯешле булган шул.

54 Мыны кюреб, Анын ӧйрянеӯчеляре Іаковъ белян Іоаннъ айткянняр: эй Ходай! телейемсен, Илія кылган кюк без дя: кюктян ут тӧшӧб, аларны бетерсен диб айтейек ме? дигянняр.

55 Ӓммя Ул аларга таба боролоб, аларны тыйыб айткян: ничек тынышта икянегезне белмейсез.

56 Ӓдям Улы кешелярнен жаннарын бетерергя килмяде, ӓммя сакларга килде шул, дигян. Аннары икенче ауылга киткянняр.

Зач. 49.

57 Алар жулда чагында, беряӯ Іисуска айткян: эй Ходай! Син кайда гна барсаң да мин Сиңа эяреб барым, дигян.

58 Іисусъ аңар айткян: тӧлкӧлярнен ӧнняре бар, ауа кошларынын да оялары бар, ӓммя Ӓдям Улынын баш салыб жатыр урны да жук, дигян.

59 Ӓммя икенчесеня айткян: Минем артымнан бар, дигян. Ул айткян: эй Ходай! миңа элеке кайтыб, атамны кюмяргя роксят бирче, дигян.

60 Іисусь аңар айткян: ӯлеклярен кюмяргя ӯлектейляргя калдыр, ӓммя син барыб, Алла Падшалыгын сӧйля, дигян.

61 Тагы беряӯ айткян: эй Ходай, мин Сиңа эяреб жӧрӧрмен, тик Син элеке миңа ӧйӧмдягеляр белян бахилляшергя роксят бир, дигян.

62 Ӓммя Іисусъ аңар айткян: кулына сука тоткан кеше, кире боролоб карангаланса, Алла Падшалыгы ӧчӧн ышангышлы тӧгӧл, дигян.

10-нчы бюлем.

Зач. 50.

1 Шуннан ары Ходай тагы бютян житмеш ӧйрянеӯче сайлаган да аларны Ӯз алдыннан Ӯзе барасы ӓр-бер калага, ӓр-бер жиргя икешяр-икешяр жибяргян.

2 Аларга айткян: урасы ашлык кюб, ӓммя эшчеляр ӓз; ашлык Эясеня ӯтенегез, Ул урагына эшчеляр жибярсен эйе.

3 Сез барыгыз, Мин сезне бяряннярне бюреляр арасына жибяргяндей жибярямен.

4 (Ўзегез белян) кабчык та, жанчык та, башмаклар да алмагыз, жулда ич беряў белян дя исянняшкяляб жыуанмагыз.

5 Кайсы гна өйгя керсягез дя иң элеке: бу өйгя тынычлык булсын диб әйтегез.

6 Ăгяр анда тынычлык улы булса, (телягян) тынычлыгыгыз аңар килер, ăгяр булмаса, ўзегезгя кайтыр.

7 Шул өйдя торогоз, аларнын нейе бар, шуны ашагыз, эчегез; эшляўчегя эшлягяне өчөн бирергя тейеш ич. Өйдян өйгя кючеб жөрмягез.

8 Бер-бер калага кергяч, сезне кабыл алсалар, сезгя куйган нястяне ашагыз;

9 Андагы чирлелярне тӧзятегез, аларга әйтегез: Алла Падшалыгы сезгя жакыннашты, дигез.

10 Бер-бер калага кергяч, сезне кабыл алмасалар, сез урамнарга чыгыб әйтегез:

11 Калагыздан безгя эяргян тузанны да сезгя селкеб тӧшӧрӧб калдырабыз, алай да Алла Падшалыгы сезгя жакыннашканны белегез, дигез.

12 Сезгя әйтямен: сорау кӧнӧндя Содомъ каласына ул калага караганда жиңелеряк булыр.

13 Айгай сиңа Хоразинъ! айгай сиңа Виѳсаида! ăгяр сездя булган кодрятляр Тиръ белян Сидонда булган булсалар, алар инде кюбтян алама кейем кейенеб, (башларына) кӧл сибеб тяўбя итярляр эйе шул.

14 Алайда Тиръ белян Сидонга сораүда сезгя кюря жиңелеряк булыр.

15 Син дя, эй кюккя чаклы кютярелгян Капернаумъ, тамукка чаклы тӧшӧрӧлӧрсен.

Зач. 51.

16 Сезне тыңнаучы кеше, Мине тыңный; сезне кабыл алмаган кеше, Мине кабыл алмый, ăммя Мине кабыл алмаган кеше, Мине Жибяреўчене кабыл алмый, дигян.

17 Житмеш өйрянеўче сӧйӧнӧшӧб кайтыб, әйткянняр: эй Ходай! Синең исемең какына безне женняр дя тыңныйлар, дигянняр.

18 Ăммя Ул аларга әйткян: кюктян жяшен кюк атылыб тӧшкян шайтанны кюрдем.

Зач.

19 Мына Мин сезгя жыланга да, скорпіонга да, дошманнын бар кӧчӧня дя басарга кыуат бирям, ич-бер нястя сезгя зыян тейермяс.

20 Алайда сезне женняр тыңнаганга сӧйӧнмягез, ăммя исемнярегез кюктя жазылыулы булганга сӧйӧнӧгӧз, дигян.

21 Шул сагаття Іисусъ кюнгеле сӧйӧнӧб айткян: эй Ӓтей, кюкнен, жирнен Ходайы! Син мыны белемнелярдян, акыллылардан жяшереб, балаларга кюрсяткянең ӧчӧн Сине данныймын. Эйе, Ӓтей, Синең иркең шулай булды шул дигян.

Зач. 52.

22 Аннары ӧйрянеўчеляреня таба боролоб айткян: Миңа Атамнан ӓр-ней бирелеўле. Улнын кем икянен Атадан бютян беряў дя белмей, Атанын да кем икянен Улыннан башка, тагы Улы белдерясе килгян кешедян башка (беряўдя белмей).

23 Тагы ӧйрянеўчеляреня караб, аларга гна айткян: сез кюря торганны кюреўче кюзляр бахетле.

24 Мин сезгя айтямен: кюб пагамбярляр, падшалар сез кюря торганны кюряселяре килде, алайда кюрмяделяр; сез эшеткянне эшетяселяре килде, тик эшетмяделяр, дигян.

Зач. 53.

25 Мына законъ белеўче беряў урныннан тороб, Іисусны сынаб айткян: эй Ӧйрятеўче, мянге тормошка урыннашыр ӧчӧн, мин ней кылыйым? дигян.

26 Ул аңар айткян: законда ней диб жазган, ничек диб укыйсын? дигян.

27 Ул жауаб биреб айткан: Алла Ходайыңны бар кюнгелең белян, бар жаның белян, бар кӧчӧң белян, бар уйың белян сӧй, жакыныңны да ўзеңне сӧйгян кюк сӧй диб.

28 (Іисусь) аңар айткян: син дӧрӧс жауаб бирдең; шулай кыл, тере торорсон, дигян.

29 Ӓммя ул ўзен дӧрӧскя чыгарыр ӧчӧн, Іисуска айткян: минем жакыным кем суң? дигян.

30 Іисусъ жауаб биреб айткян: бер кеше Іерусалимнан Іерихонга тӧшӧб бара икян, шунда талаучыларга очраган; алар анын ӧстӧннян кейемен салгызыб алыб, ўзен жаралаб, ўлярлек итеб калдырыб киткянняр.

31 Шул жулданук бер священниккя барырга туры килгян; ул аны кюргян дя узыб киткян.

32 Шунын кюк бер левитъ та шул урынга туры килеб, ул кешенен жанына барыб караган да узыб киткян.

33 Аннары бер Самарія кешесе атланыб бара икян; ул шул кешегя туры килеб, аны кюреб, кызганган.

34 Жакын килеб, анын жараларына май белян аракы сөртөб бяйлягян; аннары аны ишяге өстөня атландырыб, узгынчылар кереб куна торган өйгя алыб барыб, анда анын өчөн сагышланган.

35 Иртягесен киткян чагында, ике динарій чыгарыб, шул өйнөн эясеня биреб айткян: мынын өчөн сагышлансана; ӓгяр мыннан артык акча тотсаҥ да мин кайтышлый сиҥа тюлярмен, дигян.

36 Суҥ инде талаучыларга туры килгян кешенен жакыны шул өч кешенен кайсысы диб уйлыйсын? дигян.

37 Ул айткян: аҥар изгелек иткяне, дигян. Іисусъ аҥар айткян: бар, син дя шулай кыл, дигян.

Зач. 54.

38 Жул белян бара торгач, Іисусъ бер ауылга кергян; шунда Марѳа атлы бер катын Аны ўз өйөня алыб кергян.

39 Анын Марія атлы сеҥнесе бар икян, ул Іисуснын аягы жанына утырыб, Анын сюзен тыҥнаб утырган.

40 Ӓммя Марѳа кюб сыйлар ӓзерляргя сагышланыб жөргян, ул жакын килеб (Іисуска) айткян: эй Ходай, сеҥнем кызмятне жангызыма гна калдырганга Син коймөйсен меней? аҥар айтче, ул миҥа булышсын, дигян.

41 Іисусъ аҥар жауаб биреб айткян: эй Марѳа, Марѳа! син кюбкя сагышланыб жөрөйсен, киряклесе тик бер гня.

42 Марія арыу өлөшнө сайлаб алды, ул аннан алынмас дигян.

11-нче бюлем.

Зач. 55.

1 Бер табкыр бер төштя Іисусъ теляк итеб туктагач, өйрянеўчеляре арасыннан берсе Аҥар айткян: эй Ходай, Іоаннъ ўз өйрянеўчелярен теляк итяргя өйряткян кюк, Син дя безне теляк итяргя өйрятче, дигян.

2 Ул аларга айткян: сез теляк иткян чагында, былай диб айтегез: эй кюктяге Атабыз, данны булыб торсон исемеҥ Синеҥ, килсен падшалыгыҥ Синеҥ, жирдя дя кюктягечя булсын иркеҥ Синеҥ.

3 Көннөк икмягебезне безгя көн сайын бир.

4 Жазыкларыбызны кичер, без дя безгя бурычлы булган ӓр-бер кешегя кичерябез шул. Безне алданырга ирек жибярмя, жаманнан коткар безне диб.

5 Аларга тагы айткян: сезнен арагыздан берегезнен-берегезнен бер дусы булыб, шул дусына ул төн уртасында барыб айтся: эй дусым, миҥа ӓжяткя өч икмяк бирче,

6 Дусым жулга барышлый миҥа керде, аҥар куяр нястям жук шул дися,

7 Анын дусы ӧй эченнян аӊар жауаб биреб айтер: мине кумачаулама, инде ишегем бикляӳле, балаларым да минем белян урында жаталар, мин тороб, синӊа биря алмыйым, дирер.

8 Мин сезгя айтямен: ӓгяр ул кеше тороб, дуслыгы какына аӊар бирмяся дя, китмей сораганына кюря, тороб, аӊар сораганынча бирер.

Зач. 56.

9 Мин дя сезгя айтямен: сорагыз, сезгя бирелер; эзлягез, табарсыз; кагыгыз, сезгя ачарлар.

10 Ӓр-бер сораучы аладыр шул, эзляӳче табадыр, кагыб тороучыга да ачалар.

11 Сезнен арадан кайсы ата, улы икмяк сораса, аӊар таш бирер? жя балык сораса, балык урнына аӊар жылан бирер?

12 Жя кюкяй сораса, аӊар скорпіонъ бирер?

13 Шулай, сез ӳзегез жаман булыб та, балаларыгызга жакшыны биря белгяч, кюктяге Ата Ӳзеннян сораучыларга Святый Тынны бигряк тя бирер, дигян.

Зач. 57.

14 Бер табкыр Іисусъ (бер кеше эченнян) телсез женне кыуыб чыгарган; жен чыккач, телсез кеше сӧйляшя башлаган; калыкнын исе киткян.

15 Аларнын кайсылары айткянняр: Ул женнярне женняр башлыгы веельзевулнын кӧчӧ белян кыуыб чыгара, дигянняр.

16 Кайсылары Аны сынаб, кюктян билге кюрсятче дигянняр.

17 Ӓммя Ул аларнын уйларын белеб, аларга айткян: ӓр-бер падшалык ӳзе ӳз алдына айырылышса, буш калыр; ӳз алдына айырылышкан ӓр-бер жорт та бетяр.

18 Ӓгяр шайтан ӳзе ӳз алдына айырылышса, анын падшалыгы ничек тора алыр? Ӓммя сез : Мин женнярне веельзевулъ кӧчӧ белян чыгара диб айтясез.

19 Ӓгяр Мин женнярне веельзевулъ кӧчӧ белян чыгарам икян, сезнен улларыгыз аларны кем кӧчӧ белян чыгаралар суӊ? Шул сяятлей алар сезне айыблаучы булырлар.

20 Ӓгяр Мин женнярне Алла кыуаты белян чыгарам икян, инде айса сезгя Алла Падшалыгы килеб житкян.

21 Кӧчлӧ кеше ӳз ӧйӧн корал белян саклаб торган чагында, анын малы имен булыр.

22 Ӓгяр аннан кӧчлӧ беряӳ аӊар жабышыб, аны жинся, анын ышаныб торган бар коралын да алыр, талаб алган (малын) да ӧляшер.

Зач. 58.

23 Минем белян бер уйда тӧгӧлӧ, Минҕа карышы; Минем белян бергя жыймаганы, тарата.

24 Шакшы тын кеше эченнян чыккач, сыусыз жирлярдян тынычлык эзляб жӧрӧй; табмагач, айтя: чыккан ӧйӧмя кайтыйым дей;

25 Кайткач, аны себергян кӧйӧ, айбятлягян кӧйӧ очрата.

26 Аннары барыб, ўзе белян бергя тагы ўзеннян дя жаманырак бютян жиде тынны алыб киля дя, кереб шунда торалар. Ул кешегя сунгысы элекегедян дя жаманырак була, дигян.

27 Ул мыны сӧйлягян чагында, калык арасыннан бер катын ауаз кютяреб, Анҕар айткян: Сине кютяреб жӧргян корсак, Сине имезгян имчяк бахетле, дигян.

28 Аммя Іисусъ айткян: Алла сюзен тынҕнаб, аны кылыучылар бигеряк тя бахетле, дигян.

Зач. 59.

29 Калыклар жыйылышкан чагында, Іисусъ айтя башлаган: бу тыума усал, ул билге эзлей, тик анҕар Іона пагамбяр билгесеннян бютян билге бирелмяс.

30 Іона пагамбяр Ниневія кешеляреня билге булган кюк, Адям Улы да шушы тыумага билге булыр.

31 Тӧшлӧктяге катын падша бу тыума кешеляре белян сораудa тороб, аларны айыблар, ул шу Соломонъ белемнеген эшетергя жир читляреннянюк килгян, аммя мында Соломоннан да Оло бар.

32 Ниневія кешеляре бу тыума белян сораудa тороб, аны айыблармар, алар шу Іона (пагамбяр) сӧйляўеннян тяўбягя килделяр, аммя мында Іонадан да Оло бар.

33 Беряўдя эшямне жандыргач, аны жяшерен урынга куймый, сауыт астына да куймый, аммя кереўчеляр жакты кюрсенняр диб, эшямдялгя утырта, дигян.

Зач. 60.

34 Тян жактырткычы кюз; агяр синенҕ кюзенҕ таза булса, бӧтӧн тяненҕ дя жакты булыр; агяр кюзенҕ начар булса, бӧтӧн тяненҕ дя карангы булыр.

35 Инде айса кара, эченҕдяге жактынҕ карангы тӧгӧл ме?

36 Агяр бӧтӧн тяненҕ жакты булса, бер карангы тӧшӧ дя булмаса, жактырткыч ўз жактысы белян сине жактыртыб торган кюк, буган тӧшӧнҕ дя жакты булыр, дигян.

37 Ул мыны сӧйлягян чагында, бер фарисей Аны ўз ӧйӧня ашка чакырган.

38 Ул барыб, анда утырган. Анын ашар алдыннан кулын жыумаганын кюреб, фарисейнен исе киткян.

39 Әммя Ходай Аңар айткян: сез фарисейляр бу чакта табак-сауытыгызнын тышын тазартасыз, әммя эчегез талаб алган нястя белян, жаманнык белян тулы.

40 Эй акылсызлар! тыштагын булдырыучы, эчтяген дя булдырган тӧгӧл ме?

41 Нейегез бар, шуннан садака бирегез, шунысы жакшырак булыр; шул чакта бар нястялярегез дя таза булыр.

Зач. 61.

42 Айгай сезгя, фарисейляр! сез бӧтнӧктян, тминнан, әр-тӧрлӧ бакча жимешляреннян дя унынчы ӧлӧшӧн бирясез, әммя турылыкны, Алланы сӧйӧүне чиття калдырасыз; быларын да кыларга киряк, тегелярен дя калдырырга кирякмяс.

43 Айгай сезгя, фарисейляр! сез синагогаларда алда утырыуны, калык жыйылган жирдя кешеляр башырганны жаратасыз.

44 Айгай сезгя, княгячеляр, фарисейляр, жумачылар! кюмелгян гроблар ӧстӧннян кешеляр табтаб жӧрӧйляр, ўзляре аны белмейляр, сез дя гел шул гроблар шикелле, дигян.

45 Мыңар карышы законъ белеўче беряў Іисуска айткян: эй Ӧйрятеўче, мыны айтеўең белян Син безне дя кур итясен, дигян.

46 Әммя Іисусъ айткян: сез законъ белеўчеляргя дя читен: сез ке-шеляр ӧстӧня кютяреб жӧрӧй алмаслык жӧкляр саласыз, әммя ўзегез шул жӧкляргя бер бармагыгызны да тейереб карамыйсыз.

Зач. 62.

47 Айгай сезгя! сез аталарыгыз ўтергян пагамбярляргя памятниклар торгозасыз.

48 Шунын белян сез аталарыгыз эшляреня таныклык итясез, алар белян бер уйдаш буласыз: алар пагамбярлярне ўтергянняр, әммя сез аларга памятниклар торгозасыз.

49 Шуңар кюря Алла белемнеге айткян: мин аларга пагамбярляр, апостоллар жибярем, аларнын кайсысын ўтерерляр, кайсысын кыуарлар, дигян.

50 Дӧнья булдырылганнан бирле булган бар пагамбярлярнен тюгелгян каннары шушы тыумадан соралсын;

51 Авель каныннан башлаб, корман урны белян келяў ӧйӧ арасында ўтерелгян Захаріянын канына чаклы, чын айтямен сезгя, шушы тыумадан соралыр.

52 Айгай сезгя законъ белеўчеляргя! сез белемнек ачкычын алдыгыз; ўзегез дя кермядегез, керясе килгяннярне дя кертмядегез, дигян.

53 Ісусь аларга мыны айткян чагында, княгячеляр белян фарисейляр Аңар бик каты жабышыб, кюб сюзляреня жауаб айттерергя тырышканнар;

54 Аны сагалаганнар, Аны айыблар өчөн, ауызыннан чыккан сюзеннян эляктерергя тырышканнар.

12-нче бюлем.

1 Аннары калык меңняб жыйылышыб, бер берсен тыгызлаб торган чагында, Ісусъ иң элеке Ўз өйрянеўчеляреня айтя башлаган: фарисейляр әчеткеченнян, жумалауларыннан сакланыгыз, дигян.

Зач. 63.

2 Жяшергян нястянен ич берсенен кюренмей калганы жук, жяшерендягенен беленмей калганы да жук.

3 Шуңар кюря, сез карангыда айткян сюз, жактыда эшетелер, өй эчендя колакка гна айткянегез, өй тюбясендя сөйлянер.

4 Мин сез дусларыма айтямен: тянне ўтереўчелярдян, әммя суңыннан бер нястя дя кыла алмый торганнардан курыкмагыз.

5 Әммя Мин сезгя кемнян куркырга кирякне айтерем: ўтергяч, тамукка төшөргя кыуаты бардан куркыгыз, чыннаб айтямен сезгя: шундыйдан куркыгыз.

6 Биш чыбчык ике ассарійгя сатыла төгөл ме? алайда Алла аларнын берсен дя онотмый.

7 Әммя сезнен башыгыздагы чячегез дя барысы да санаулы. Инде айса курыкмагыз, сез кюб чыбчыклардан кадерлеряк, дигян.

Зач. 64.

8 Мин сезгя айтямен: кем дя кем Мине кешеляр алдында айтеб белдерся, ӘдямУлы да Алла пяриштяляре алдында аны айтеб белдерер.

9 Әммя кем Мине кешеляр алдында таңса, ул ўзе дя Алла пяриштяляре алдында таңылыр.

10 Әдям Улына (курлык) сюз айтеўче әр-кемгя кичерелер; әммя Святый Тынга курлык айткян кешегя кичерелмяс.

11 Сезне синагогаларга, тюряляр катына, башлыклар жанына китергян чакта, ничек жауаб бирербез, жя ней айтербез диб көйөнмягез.

12 Ней айтясене Святый Тын сезгя шул сагаття өйрятер, дигян.

Зач. 65.

13 Калык арасыннан беряў Ісуска айткян: эй Өйрятеўче, минем агама айтсяня, калган малны миңа айырыб бирсен, дигян.

14 Әммя Ул шул кешегя айткян: сезгя хокөм итеўче итеб, жя сезне айырыучы итеб, Мине кем куйды? дигян.

15 Шунда аларга айткян: карагыз, малга биренеўдян сакланыгыз, кешенен гумере малы кюбкя карамый ич, дигян.

Зач. 66.

16 Аннары аларга мясял айткян: бер бай кешенен басыуда ашлыгы бик унган.

17 Ул ӱз кюнеелендя уйлаган: мин ней эшлейем? ашлыгымны жыйыб салыр урным жук, дигян.

18 Аннары айткян: мына ней эшлярем: амбарларымны уаттырым да зурырак амбарлар салдырыб, шунда бар ашлыгымны да, бар малымны да жыйыб куярым.

19 Аннары ӱз жаныма айтермен: эй жаным, синен инде кюб жылга житярлек жата торган кюб малын бар, инде тынычлан, аша, эч, кыуан дирем, дигян.

20 Тик Анар Алла айткян: эй акылсыз! шушы тӧндюк жанынны синнян алырлар, ӓзерлягянен кемгя калыр сун? дигян.

21 Алла ӧчӧн жыймыйчы, малны ӱзе ӧчӧн гня жыя торган кешегя шулай була, дигян.

22 Аннары ӧйрянеӱчеляреня айткян: шунар кюря сезгя айтямен: ней ашарбыз диб жаныгыз ӧчӧн коймягез, тянегез ӧчӧн дя ней кеярбез диб коймягез.

23 Жан ашамныктан, тян кейемнян кадерле.

24 Каргаларга карагыз: алар чячмейляр дя, урмыйлар да, аларнын клятляре дя, амбарлары да жук, алай да Алла аларны туйдыра; сез кошлардан кюб кадерле тӧгӧл ме?

25 Кем сезнен арадан койӧнӧб, ӱз буйын бер гня терсяк буйы арттыра алыр?

26 Айса азга гна да кӧчӧгӧз житмягяч, бютян нястяляр ӧчӧн ник койӧнясез?

27 Чячяклярга карагыз, алар ничек ӱсяляр: эшлямейляр дя, эрлямейляр дя; Мин сезгя айтямен: Соломонъ бик данныклы булса да, аларнын берсе гня чаклы да кейеня алмаган.

28 Ӓгяр дя бӧгӧн бар, ӓммя иртягя пичкя ташларлык кырдагы ӱлямне Алла шундый кейендергяч, эй аз ышаныучылар, сезне бигряк тя жакшырак кейендермяс меней?

29 Алай булгач, сез ней ашарбыз, жя ней эчярбез диб эзлянмягез, сагышланмагыз.

30 Мындыйнын барын да бу дӧнья кешеляре гня эзлейляр, ӓммя ул нястялярнен сезгя киряк икянен Атагыз белядер.

31 Бигряк Алла Падшалыгын эзлягез, аннары ул нястяляр барда сезгя ӧстяб бирелер.

Зач. 67.

32 Эй кечкеня кӧтӧў, курыкма! Атагыз сезгя падшалык бирергя кюҥел итте шул.

33 Малларыгызны сатыгыз, садака бирегез, Ўзегезгя тузмый торган кабчыклар, кимемей торган мал кюктя ӓзерлягез: анда бур да жакыннашмый, кӧя дя теймей.

34 Малыгыз кайда булса, кюҥелегез дя шунда булыр шул.

35 Билегезгя ээяр бяйляўле булсын, жактырткычларыгыз жаныб торсон.

36 Туйдан кайтасы эяляренн кӧтӧб тора торган кешеляр кюк булыгыз, алар эяляре кайтыб, ишек кагыу белян, аҥар ачарга ӓзер торалар.

37 Эяляре кайтыб, уяу кӧйӧ очраткан кызмятчеляр бахетле; сезгя чыннаб ййтямен: ул билен бяйляб, аларны утыртыб, жакын килеб, аларга кызмят итеб жӧрӧр.

38 Ӓгярдя тӧннӧн икенче бюлемендя, жя ӧчӧнчӧ бюлемендя кайтыб та, аларны шулай (уяу кӧйӧ) очратса, ул кызмятчеляр бахетле.

39 Сез белясез, ӓгяр жорт эясе бурнын кайсы сагаття килерен белся, ул уяу торор ыйы, ўз жортона казыб керергя ирек бирмяс эйе.

40 Сез дя ӓзер булыгыз, Ӓдям Улы сез уйламаган сагаттюк килер шул, дигян.

41 Шул чакта Петръ Аҥар ййткян: эйХодай! Син бу мясялне безгя гня ййтямесеҥ, ӓлля бар кешеляргя дя ме? дигян.

Зач 68.

42 Ходай ййткян: кызмятчеляреня багытында ўлчяб, икмяк бирсен диб, эяляре аларга башлык итеб куйган, акыллы, гадел жорт карауччы кюк кем?

43 Эясе килгян чакта, аҥар шулай кылыб туры килгян кол бахетле.

44 Чыннаб ййтямен сезгя: ул аны бар малына баш итеб куяр.

45 Ӓгяр ул кол ўз кюҥелендя: эям тиз килмяс ӓле диб, кызмятче ирлярне дя, катыннарны да кыйнарга тотоноб, ўзе ашаб, эчеб, эчкелеккя салынса,

46 Ул колнон эясе кол кӧтмягян кӧннӧ, ул уйламаган сагаття килеб, аны уртара чабыб ӧзяр дя аны денсезляр ӧлӧшӧня тӧшӧрӧр.

47 Эясенен иркен беля тороб, ӓзер булыб тормаган, анын иркен кылмаган кол бик каты кыйналыр.

48 Ӓммя белмейчен, кыйынга тейешле эш кылган кол ӓз кыйналыр.

Зач. 69.

Кюб бирелгян äр-бер кешедян кюб соралыр да; кемгя кюб табшырылса, аннан исябе дя артык соралыр.

49 Мин жир öстöня ут тöшöрöйöм диб килдем, инде жана башласын ыйы диб бик телеймен.

50 Мин чумылыу белян чумылдырыласы; ул булгынчы бик интегям.

51 Äлля сез Мине жиргя тынычлык бирергя килгян диб уйлыйсыз мы? Жук, сезгя äйтямен: Мин айырырга килдем:

52 Мыннан былай бер öйдяге биш кеше айырылышыр, öчöсö икесеня карышы, икесе öчöсöня карышы торор:

53 Атасы улына карышы торор, улы атасына карышы торор; анасы кызына карышы торор, кызы анасына карышы торор; бейеме килененя карышы торор, килене бейеменя карышы торор, дигян.

54 Аннары Іисусь калыкка да äйткян: сез кояш байышы жагыннан киля торган болотно кюргяч, шундук äйтясез: жангыр жауар дисез, шулай була да.

55 Тöшлöк жагыннан жил исся, кызыу булыр дисез, була да.

56 Эй жумалаучылар! жирнен, кюкнен тöсöн айыра белясез, äммя шушы багытны ничек танымыйсыз суҥ?

57 Ней буласыны ник ӱзегездян караб белмейсез?

58 Даучыҥ белян бергя башлык жанына барсаҥ, жулда чагындук аннан котолорга тырыш, жугыйса ул сине тюря катына алыб кермясен; тюря сине азаблаучыга табшырыр, äммя азаблаучы сине öтöрмянгя жабар.

59 Сиҥа äйтямен: калдык полушкаҥны биреб бетермейчен, син аннан чыкмассыҥ, дигян.

13-нчö бюлем.

Зач. 70.

1 Шул чакта кайсы кешеляр килеб, Пилатъ Галилея кешеляренен каннарын китергян корманнарына катыштырганны Іисуска äйткянняр.

2 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: бу Галилея кешеляре Галилеянын буган калыгыннан да жазыклырак булганга кюря, шулай азабланганнардыр диб уйлыйсыз мы äлля? дигян.

3 Сезгя äйтямен: жук; äгяр тяӱбя итмясягез, барыгыз да шулай бетярсез.

4 Жя тагы Силоамъ башнясе ауыб, басыб ӱтергян ун сигез кеше Іерусалимда тора торган кешелярнен барысыннан да айыблырак булганнардыр диб уйлыйсыз мы äлля?

5 Мин сезгя äйтямен: жук; äгяр тяӱбя итмясягез, барыгыз да шулай бетярсез, дигян.

6 Аннары бу мясялне айткян: беряўнен жөзөм бакчасында утырткан смоковница агачы бар икян; ул анын жимешен эзляргя килгян, тик табмаган.

7 Аннары бакчачыга айткян: мына мин инде өч жылдан бирле бу смоковница агачыннан жимеш эзляргя килямен, тик табмыймын; аны кис, ул нейгя бушка урын алыб тора? дигян.

8 Бакчачы аңар жауаб биреб айткян: эй эям, аны быйылга да калдырсана, мин анын айлянясендяге балчыгын казыб, тирес салыб карыйым:

9 Жимеш китермяс ме? ăгяр дя китермяся, аны килясе жылны кисярсен, дигян.

Зач. 71.

10 Суббота көннө Іисусъ бер синагогада өйряткян.

11 Анда ун сигез жылдан бирле эчендя ăлсезлек тыны торган бер катын бар икян; ул шуннан тартышкан икян, төз тора алмый икян.

12 Іисусъ аны кюреб, ўз катына дяшеб алыб, аңар айткян: эй катын, син инде ăлсезлегеңнян котоласың, дигян.

13 Аннары анын өстөня кулларын салган, ул шул сяттюк төзлянгян дя Алланы данный башлаган.

14 Шул чакта синагога башлыгы Іисуснын суббота көннө төзяткянен ошатмыйчы, калыкка айткян: эш эшлей торган алты көн бар ич, төзялергя шул көннярдя килегез, ăммя суббота көннө килмягез, дигян.

15 Ходай аңар жауаб биреб айткян: эй жумачы! сезнен ăр кайсыгыз суббота көннө ўз ўгезен, жя ишяген утлыктан чишеб алыб, эчерергя алыб бармый меней?

16 Алай булгач, бу ун сигез жылдан бирле шайтан бяйляб тота торган катынны, Авраамъ кызын шул бяйдян котолдорырга суббота көннө тейеш төгөл эйе меней? дигян.

17 Ул мыны айткяндя. Аңар карышы торган кешеляр барысыда оялганнар; бар калык та Анын данныклы эшляреня бик сөйөнгян.

Зач. 72.

18 Іисусъ айткян: Алла Падшалыгы нейгя ошаулы? Аны нейгя ошатыйым?

19 Ул горчица орлогона ошаулы; ул орлокно бер кеше алыб, ўз бакчасына утырткан; ул ўскян, зур агач булган, ботакларында ауа кошлары жяшенерлек булган, дигян.

20 Тагы айткян: Алла Падшалыгын нейгя ошатыйым?

21 Ул ӓчеткеч апарага ошаулы; аны бер катын алган да ӧч ўлчяў онга катыштырыб, бары бергя ӓчеб житкенче, ӓчетергя куйган, дигян.

22 Аннары Ул калаларда, ауылларда жӧрӧб ӧйрятеб, Іерусалимга таба барган.

23 Беряў Аңар айткян: эй Ходай! котолоучылар ӓз меней? дигян.

24 Іисусъ аларга айткян: Тар кабкадан керергя тырышыгыз; сезгя айтямен: кюбесе керергя эзлярляр, тик керя алмаслар шул.

25 Ӧйнӧн эясе тороб, ишеген жабкач, сез тышта тороб, ишек кагыб айтерсез: эй Ходай! эй Ходай! безгя ач, дирерсез; ӓммя Ул сезгя жауаб биреб айтер: сезнен кайдагы икянегезне белмеймен, дирер.

26 Шул чагында сез айтерсез: без Синең алдында ашадык та эчтек тя, Син безнен урамнарыбызда ӧйряттең, дирерсез.

27 Ӓммя Ул айтер: сезгя айтямен: сезнен кайдагы икянегезне белмеймен; эй дӧрӧссӧзлӧк кылыучылар, барыгыз да Миннян китегез, дирер.

28 Шунда Авраамнын, Исаакнын, Іаковнын, бар пагамбярлярнен дя Алла Падшалыгында икянен, ӓммя ўзегезнен тышка кыуыб чыгарылганыгызны кюрерсез. Шул чакта жылау, теш шыкырдатыу булыр.

29 Шунда кояш чыгышыннан да, кояш байышыннан да, тӧн жагыннан да, тӧшлӧктян дя килеб, Алла Падшалыгында урыннашырлар.

30 Мына алда буласы арттагылар бар, артта буласы алдагылар бар, дигян.

Зач. 73.

31 Шул кӧннӧ фарисейлярнен кайсылары Іисуска килеб айткянняр: чык, мыннан кит, Иродъ Сине ўтермякче була шул, дигянняр.

32 Ул аларга айткян: барыб, ул тӧлкӧгя айтегез: мына Мин бӧгӧн дя, таңда да женнярне кыуыб чыгарам, ауырыуларны тӧзятям, ӧчӧнчӧ кӧннӧ бетерермен.

33 Алай да Миңа бӧгӧн дя, таңда да, бӧрсӧ кӧндя жӧрӧргя тейеш ӓле, пагамбярнен Іерусалимнан бютян жирдя ўлгяне жук шул.

34 Эй пагамбярлярне ўтереб бетереўче, сиңа жибярелгяннярне таш белян атыб ўтереўче Іерусалимъ, Іерусалимъ! тауык ўз чебешлярен канаты астына жыйган кюк, синең балаларыңны ничя табкыр жыясым килгян эйе, ӓммя сез телямядегез.

35 Мына инде жортогоз сезгя буш кала. Мин сезгя ййтямен: мыннан былай Ходай исеменя Килеўче даннаулы диб сез ййтер багыт житкенче, Мине кюрмяссез, дигян.

14-нче бюлем.

Зач. 74.

1 Бер табкыр суббота кӧннӧ Іисуска фарисей башлыкларынын берсенен ӧйӧня кереб, аш ашарга туры килгян; алар Аны сагалаганнар.

2 Шунда Анын алдына водянка белян чирлей торган кеше килгян.

3 Шул сяятлей Іисусь законъ белеўчелярдян, фарисейлярдян сораган: суббота кӧннӧ тӧзятергя тейеш ме? дигян.

4 Алар дяшмягянняр. Аннары тейенеб, аны тӧзятеб жибяргян.

5 Шунда аларга ййткян: ӓгяр берегезнен ишяге, жя ўгезе койога тӧшся, суббота кӧннӧ булса да аны шундук койодан чыгармас мы? дигян.

6 Анын бу сюзеня алар жауаб ййтя алмаганнар.

7 Шунда чакырылган кунаклар тюрдяге урыннарны ничек сайлаганны кюреб, Ул аларга мясял ййткян:

8 Сине беряў туйга чакырса, син тюргя утырма, чакырылганнар арасында синнян кадерлесе булыб,

9 Сине дя, аны да чакырган кеше жаныңа килеб, сиңа: урныңны мыңар бир димясен; ул чакта син оялыб, иң тюбянге урынга утырырга тейеш булырсын.

10 Ӓммя син чакырылгач, килеб иң тюбянге урынга утыр, сине чакырган кеше жаныңа килеб, сиңа: эй дусым, жугарырак утыр дисен; шул чагында синең белян бергя утырыучылар алдында кадерле булырсын:

11 Ўзен ўзе ололаучы ӓр-кем кечелянер, ӓммя ўзен кечеляндереўче ололаныр шул, дигян.

Зач. 75.

12 Тагы Ўзен ашка чакырыучы кешегя дя ййткян: жя кӧндӧз, жя кич аш жасаган чагында, син дусларыңны, ага-энеляреңне, карендяшляреңне, бай кюрешеляреңне чакырма, алар да бер-бер чакта мине чакырыб, миңа кайтарсыннар диб.

13 Ӓммя сый жасаган чагыңда, син жарлыларны, гареблярне, аксакларны, сукырларны чакыр:

14 Алар сиңа кайтара алмаганга кюря, син бахетле булырсың, сиңа гаделляр терелеб торганда кайтарылыр шул, дигян.

15 Мыны эшетеб, Анын белян бергя утырыучыларнын берсе Аңар ййткян: Алла Падшалыгында аш ашасы кеше бахетле, дигян.

Зач. 76.

16 Іисусъ аҥар айткян: бер кеше кич оло аш жасаб, кюб кешелярне өндягян.

17 Аш багыты житкяч, өндялгянняргя: инде барыгыз, барыда äзер диб айтергя колон жибяргян.

18 Барысыда сюз берляшкян кюк, чигеня башлаганнар. Элекегесе аҥар айткян: мин жир алдым, миҥа аны барыб карарга киряк, синҥа ўтенямен, миҥа айыб итя кюрмя, дигян.

19 Икенчесе айткян: мин биш пар ўгез алдым, аларны сынаб карарга барамын, синҥа ўтенямен, миҥа айыб итя кюрмя, дигян.

20 Өчөнчөсө айткян: мин өйляндем, шунныктан бара алмыйым, дигян.

21 Аннары шул кол мыны ўз эясеня кайтыб айткян. Шунда жорт эясе ачыуы килеб, ўз колона айткян: бар тизеряк, кала урамнарыннан да, тыкырыклардан да очраган жарлыларны, гареблярне, аксакларны, сукырларны мында алыб кил, дигян.

22 Кол айткян: эй эям, мин син кушканча кылдым, тагы да урын бар, дигян.

23 Эя колга айткян: син тагы жулларга, киртя буйларына барыб, (очраганнарны) кыстаб алыб кайт, өйөм тулсын.

24 Мин сезгя айтямен: теге өндялгяннярнен берсе дя ашымны ашамас; чакырылганнар кюб, äммя сайланганнар äз шул, дигян.

Зач. 77.

25 Іисусъ белян бик кюб калык барган, Ул боролоб, аларга айткян:

26 Миҥа килеўче кеше атасын, анасын, катынын, балаларын, ага-энелярен, тута-сеҥнелярен, тагы ўз жанын да жаратмас булмаса, Минем өйрянеўчем була алмас.

27 Качын кютяреб, Минем артымнан килмягяне дя Минем өйрянеўчем була алмас.

28 Кем сезнен арадан башня салдырасы булыб, элеке утырыб, ней катле чыгарын, аны торгозоб житкезергя житярлек малы барын санаб карамас?

29 Жугыйса нигезен салгач, аны торгозоб житкезя алмаса, кюргян кешеляр барда аннан көлярляр:

30 Бу кеше торгоза башлаган ыйы, тик бетеря алмады дирерляр.

31 Жя кайсы падша икенче падшага карышы сугышка барасы булгач, элеке утырыб, ўзеня карышы киля торган жегерме меҥ чиреўле падшага ўзенен ун меҥне чиреўе белян карышы торорга көчө житярен, житмясен киҥяшляшмяс?

32 Житмясен белся, теге жыракта чагындук, ул аҥар татыулык турысында ўтенергя илчеляр жибярер.

33 Шулай, сезнен äр-кайсыгыз ӱзенен бар нястясеннян айырылмаса, Минем öйрянеӱчем була алмас.

34 Тоз жакшы нястя; äгяр тоз ӱз кыуатын жугалтса, аны ней белян тöзятерсен?

35 Ул жиргя дя, тирескя дя жарамый, аны тышка чыгарыб ташлыйлар. Эшетергя колагы бар кеше эшетсен! дигян.

15-нче бюлем.

Зач. 78.

1 Іисусъ катына Аны тынңар öчöн мытарлар, жазыклы кешеляр барысы да жакыннашканнар.

2 Фарисейляр белян княгячеляр жаратмыйчы äйткянняр: Ул жазыклыларны кабыл кюреб, алар белян бергя ашый, дигянняр.

3 Äммя Ул аларга шушы мясялне äйткян:

4 Кем сезнен арагыздан жöз сарыгы булыб, аларнын берсен жугалтса, туксан тугызын буш кырда калдырыб, жугалганын табкынчы эзлей бармас?

5 Аны табкач, сöйöнöб, жилкясеня кютяреб алыр да,

6 Öйöня кайтыб, дусларын, кюрешелярен чакырыб, аларга äйтер: минем белян сöйöнöшöгöз, мин жугалган сарыгымны табтым, дирер.

7 Сезгя äйтямен: кюктя дя шулай тяӱбягя килгян бер гня жазыклы кешегя тяӱбя итеӱ кирякле тöгöл туксан тугыз гаделлягя сöйöнгяннян артыгырак сöйöнöшöрляр.

8 Жя кайсы катын ун драхмасы булыб, бер драхмасын жуйса, аны эшям жандырыб, бюлмясен себереб, табкынчы тырышыб эзлямяс?

9 Äммя табкач, ӱзенен дус катыннарын, кюреше катыннарын чакырыб äйтер: минем белян сöйöнöшöгöз, мин жуйган драхмамны табтым, дирер.

10 Сезгя äйтямен: тяӱбя иткян бер гня жазыклы кешегя дя Алла пяриштяляре гел шулай сöйöнöшяляр, дигян.

Зач. 79.

11 Тагы äйткян: бер кешенен ике улы бар икян.

12 Аларнын кечесе атасына äйткян: äтей! малнын минңа теясе öлöшöн айырыб бирче, дигян. Атасы малын аларга öляшеб биргян.

13 Бер-ауык кöн ӱткяч, кече улы бар öлöшöн жыйыб алыб, жырак жиргя киткян; анда азгын тороб, малын таратыб бетергян.

14 Ул бар малын бетергяч, шул жакта бик каты ачлык булган, ул жöдяӱгя калган.

15 Аннары барыб, шул жактагы кешелярнен берсендя тора башлаган; ул кеше аны басыуына дунгызлар кöтяргя жибяргян.

16 Ул шунда дунгызлар ашый торган кузакнын тӧшӧ белян корсагын тутырса да жаратасы икян, äммя аны да аҥар беряӳ дя бирмягян.

17 Аннары уйга тӧшӧб, äйткян: минем атамнын ней чаклы жалчылары икмяккя тук булыб торалар, äммя мин ачлыктан ӳлям, дигян;

18 Кая, торойом да атама кайтыб, аҥар äйтейем: äтей! мин кюккя дя, сиҥа да жазыклы булдым,

19 Инде улыҥ диб äйтелергя дя тормоймын, ичмаса мине жалчыларыҥ исябеня алсана диб.

20 Аннары торган да атасына киткян. Атасы аны жырактын кюреб, бик кызганган да жӧгӧрӧб чыгыб, муйнына асылыныб, аны ӳбеб торган.

21 Улы аҥар äйткян: äтей! мин кюккя дя сиҥа да жазыклы булдым, инде улыҥ диб äйтелергя дя тормоймын, дигян.

22 Äммя атасы ӳз колларына äйткян: иҥ äйбят кейемне китереб, аҥар кейгезегез, кулына жӧзӧк, аякларына башмаклар бирегез:

23 Симерткян бызауны китереб суйыгыз; ашыйык, сӧйӧнӧшӧйӧк,

24 Бу улым ӳлгян эйе, терелде, жугалган ыйы, табылды шул, дигян. Аннары сӧйӧнӧшя башлаганнар.

25 Оло улы басыуда икян; ул кайтышлый, ӧйгя жакыннашарак, жырлаган ауазлар, сӧйӧнӧшкян тауышлар эшеткян;

26 Бер кызмятчене чакырыб китереб, аннан: бу ней хал? диб сораган.

27 Ул аҥар äйткян: энеҥ кайтты, атаҥ аны исян карышы алганы сяятлей симерткян бызауны суйдырды, дигян.

28 Ул ӳпкяляб, кермей жӧргян. Атасы чыгыб, аны чакырган.

29 Äммя ул атасына жауабка äйткян: мына мин ней катле жылдан бирле сиҥа кызмят итямен, ич кайчан кушканыҥны кылмый калдырганым жук; алай да син миҥа дусларым белян бергя сыйланырга бер чакта да кязя бяряне дя бирмядеҥ.

30 Äммя бу бар малын азгын катыннарга таратыб бетергян улыҥ кайткач, анын ӧчӧн син симерткян бызауны суйдырганыҥ, дигян.

31 Атасы аҥар äйткян: эй улым, син жалан минем белян, минеке барда синеке;

32 Äммя бу энеҥ ӳлгян эйе, терелде, жугалган ыйы, табылды, мыҥар сӧйӧнӧшӧб кыуанышырга тейеш эйе, дигян.

16-нчы бюлем.

Зач. 80.

1 Аннары Ул Ўз өйрәнеўчеләреңә дә әйткән: бер кеше бай булган, аның жорт караб тороучысы да бар икән; байга аның турысында малыңны таратыб бетерә диб житкезгәннәр.

2 Ул аны чакырыб алыб, аңар әйткән: мин бу синең турыңда ней эшетәмен? тоткан нәстәң турысында исәб бир, син инде мыннан былай жортомны караб тора алмассын шул, дигән.

3 Шунда жорт караучы ўз эчендә әйткән: мин ней эшлейем икән? эям жорт караулыкны миннән ала; (жир) казый алмыймын, соранырга ояламын.

4 Инде жорт караучылыктан төшкәч, кешеләр мине ўз өйләреңә алыб тотсоннар дисәм, ней эшләргә беләмен, дигән.

5 Аннары эясеңә бурычлы кешеләрне берән-берән чакырыб, элекегесеңә әйткән: синең эямә бирәсең ней катле? дигән.

6 Ул әйткан: жөз ўлчәў май (бирәсем бар), дигән. Ул аңар әйткән: бурыч жазыуыңны ал да утырыб, тизерәк илле диб жаз, дигән.

7 Аннары икенчесеңә әйткән: синең бирәсең ней катле? дигән. Ул жауаб биргән: жөз ўлчәў бодай, дигән. Аңар да әйткән: бурыч жазыуыңны ал да сиксән диб жаз, дигән.

8 Шуннан суң эясе дөрөс төгөл жорт караучыны өннө кылганы өчөн мактаган; бу гумер уллары ўз затларында жакты улларына кюрә өннөрәк.

9 Мин дә сезгә әйтәмен: сез дөрөссөзлөк малы белән ўзегезгә дуслар жасагыз, сез жарлылангач, алар сезне мәнге жортка кабыл алсыннар ыйы.

Зач. 81.

10 Азда дөрөс кеше кюбтә дә дөрөс була, әммә азда дөрөс төгөл кеше кюбтә дә дөрөс булмый.

11 Шулай, сез дөрөссөзлөк малында дөрөс булмагач, чын малны сезгә кем ышаныр?

12 Әгәр сез жат малда дөрөс булмагач, ўзегезнекен сезгә кем бирсен?

13 Ич-бер кызмәтче ике эягә кызмәт итә алмас: жә берсен жаратмас, әммә икенчесен жаратыр; жә берсеңә кюңелдән жөрөр, әммә икенчесеңә кюңелсез гнә жөрөр. Аллага да, байлыкка да кызмәт итә алмассыз, дигән.

14 Мының барысында акча сөйөўчән фарисейләр дә эшеткәннәр, алар Аннан көлөшкәннәр.

Зач. 82.

15 Ул аларга әйткян: сез кешеляр алдында ўзегезне гадел итеб кюрсятясез, әммя Алла сезнен кюӊеллярегезне беля: кешеляргя кадерле нястя Алла алдында жирянгеч.

16 Законъ да, пагамбярляр дя тик Іоаннга чаклы гна; шул багыттан бирле Алла Падшалыгы сӧйляня, әр-кем аӊар тырышыб кна керя.

17 Алайда законнын бер гня сызыгы жугалыуына кюря, кюк белян жир ўзгяреўе жиӊелеряк.

18 Катынын айырыб жибяреб, бютян катын алган кеше әр-берсе уйнашлык итя, ире айырыб жибяргян катынны алыучы да әр-кем уйнашлык итя.

Зач. 83.

19 Бер кеше бай икян, ул порфирдан, виссоннан теккян асыл кейемняр гня кейенгян, кӧн сайын бик шяб сыйлар жасаб кна ўткяргян.

20 Тагы Лазарь атлы бер жарлы бар икян: ул шул байнын кабкасы тӧбӧндя кутырлы тянне кӧйӧ жаткан;

21 Байнын ӧстяленнян тӧшкян уалчыклар белян гня булса да туйынасы килгян; анын кутырларын этляр килеб жалаганнар.

22 Жарлы ўлгян, ўлгяч, пяриштяляр аны Авраамъ кочагына иткянняр; бай да ўлгян, аны кюмгянняр.

23 Ул тамукта азабланган чагында, кюзлярен кютяреб караган, карагач, жырактын Авраамны, анын кочагында Лазарне кюреб,

24 Кычкырыб әйткян: эй Авраамъ әтей! миӊа изгелек кылсана, Лазарне жибярсяня, ул бармагынын очон сыуга чылатыб, телемне салкыннандырсынчы, мин бу жалкында азабланам шул, дигян.

25 Авраамь әйткян: улым! син тормошонда рахатляндеӊ, әммя Лазарь азабланды, шуны исеӊя тӧшӧр; казер инде ул мында сӧйӧнӧб тора, әммя син азабланасыӊ;

26 Аннан былай тагы да безнен белян сезнен арада бик зур тӧбсӧз урын куйылган, шунныктан мыннан сезнен катка кючясе килеўчеляр кючя алмыйлар, сезнен каттан безгя дя кючмейляр, дигян.

27 Аннары бай әйткян: айса синӊа ўтенямен, әтей, аны минем атам ӧйӧня жибярсяня;

28 Минем биш агай-энем бар, (мындагы халне) ул аларга әйтеб кюрсятсен, алар да бу азаб урнына килмясенняр эйе, дигян.

29 Авраамъ аӊар әйткян: аларнын Моисейе бар, пагамбярляре бар, аларны тыӊнасыннар, дигян.

30 Ул әйткян: эй Авраамъ әтей! жук, әгяр беряў-беряў аларга ўлгян жиреннян терелеб кайтса, алар тяўбя итярляр, дигян.

31 Шунда Авраамъ аңар айткян: Моисейне дя, бютян пагамбярлярне дя тыңнамагач, беряў-беряў ўлгян жиреннян терелся дя ышанмаслар, дигян.

17-нче бюлем.

1 Аннары Іисусъ Ўз ӧйрянеўчеляреня айткян: алданыулар булмый калмас, алайда алдандырыучы кешегя читен булыр:

2 Шушы кечкенялярнен берсен алдалаудан ул кешегя муйнына тегермян ташы асыб, дингезгя ташланганы жакшырак булыр ыйы.

Зач. 84.

3 Ўзегезне ўзегез сак тотогоз. Ӓгяр туганың сиңа карышы жазыкланса, аны аңар айтеб оялт; ӓгяр дя ўкенся, аңар кичер;

4 Сиңа карышы кӧнӧндя жиде табкыр жазыкланса да кӧнӧндя жиде табкыр ўкенся, миңа кичеря кюр диб айтся, аңар кичер, дигян.

5 Апостоллар Ходайга айткянняр: бездя ышаныуны арттырсана диб.

6 Ходай айткян: ӓгяр сезнен ышаныуыгыз горчица бӧртӧгӧ кюк кня булса да шушы смоковница агачына: мыннан кубтарылыб, дингезгя барыб утыртыл дисягез, ул сезне тыңнар ыйы.

7 Кем сезнен арадан, сукалый торган, жя кӧтӧў кӧтя торган коло булыб, басыудан кайткач, аңар: кил тизеряк, ӧстял айлянясеня утыр дирер?

8 Алай дейеў урнына аңар былай айтмяс ме: миңа кичке ашны ӓзерляб куй да биленгя эзяр бяйляб, мин ашаганда, эчкяндя, миңа кызмят итеб жӧр, аннары ўзең дя ашарсың, эчярсең? диб.

9 Кушканны кылганы ӧчӧн, ул шул колга тау итяр ме? итмяс диб уйлыймын.

10 Сез дя шулай, ўзегезгя кушканны барысын да кылыб бетергяч, айтегез: без жараусыз коллар, без тик кыларга тейешлене гня кылдык шул, дигез.

11 Іерусалимга барышлый Іисусъ Галилея белян Самарія арасыннан ўткян.

Зач. 85.

12 Ул бер ауылга кергян чагында, Аны кутырлы тянне ун кеше очратканнар; алар жырактынук туктаб тороб,

13 Каты ауаз белян кычкырганнар: эй Ӧйрятеўче Іисусъ, безне жарлыка диб.

14 Ул аларны кюргяч, аларга айткян: барыгыз, священникляргя кюренегез, дигян. Барган чагында, алар тазарганнар.

15 Аларнын берсесе ўзенен тӧзялгянен кюреб, зур тауыш белян Алланы даннаб, кире кайткан да Іисуснын аягы астына жыгылыб,

16 Аңар тау иткян; ул Самарія кешесе икян.

17 Шунда Іисусъ айткян: ун кеше тазарган ыйыгыз тӧгӧл ме? тугызы кая суӈ?

18 Алар Аллага дан китерергя ничек кире килмяделяр, тик бу жат затныкы гна килгян? дигян.

19 Аннары аӈар айткян: тор да кайт, ышаныуыӈ сине коткарды, дигян.

Зач. 86.

20 Фарисейляр Іисустан Алла Падшалыгы кайчан килер диб сорагач, Ул аларга жауаб биргян: Алла Падшалыгы кюренеб килмяс;

21 Мына ул мында, жя ана тегендя диб айтмясляр; Алла Падшалыгы сезнен эчегездя шул, дигян.

22 Тагы ӧйрянеўчеляреня айткян: мына кӧнняр килер, ул чакта Ӓдям Улынын кӧнняренен бер гня кӧнӧн булса да кюрясегез килер, тик кюрмяссез.

23 Сезгя айтерляр: мына Ул мында, жя ана тегендя дирерлер; сез бармагыз, эзлямягез.

24 Жяшен кюкнен бер кырыйыннан икенче кырыйына чаклы жалтраб, жяшняб киткян кюк, Ӓдям Улы да Ӱз кӧнӧндя шулай булыр.

25 Тик элгяре Ул бик кюб азабланырга тейеш, шушы тыума Аны кабыл алмас.

Зач. 87.

26 Ной кӧннярендя ничек булган, Ӓдям Улынын кӧннярендя дя гел шулай булыр:

27 Ной кимягя керер кӧнгя чаклы, кешеляр ашаганнар, эчкянняр, ӧйлянгянняр, кеяўгя киткянняр, аннары сыу килеб, барысын да ӱтереб бетергян.

28 Лотъ кӧннярендя дя шулай булган: ашаганнар, эчкянняр, сатыу-алыу иткянняр, агачлар утыртканнар, каралды житкереб торганнар,

29 Ӓммя Лотъ Содомъ каласыннан чыккан кӧннӧ кюктян ут белян кюкерт жауыб, барысын да жукка чыгарган.

30 Ӓдям Улы килгян кӧннӧ дя гел шулай булыр.

31 Ул кӧннӧ беряў ӱзе ой тюбясендя булыб, айберляре ӧй эчендя булса, ул аларны алыб китейем диб тӧшмясен; басыуда булганы да ӧйӧня таба боролоб карамасын.

32 Лотъ катынын исегезгя тӧшӧрӧгӧз.

33 Ӱз жанын саклаган кеше, аны жуяр, ӓммя жанын жугалткан кеше, аны терелтер.

34 Сезгя айтямен: ул тӧннӧ ике кеше бер тюшяктя булса, берсесе алыныр, икенчесе калдырылыр.

35 Ике катын бергя (кул) тегермяне тартсалар, берсесе алыныр, икенчесе калдырылыр.

36 Ике кеше басыуда булсалар, берсесе алыныр, икенчесе калдырылыр, дигян.

37 Мыңар карышы Іисуска айткянняр: эй Ходай, бу кайда булыр? дигянняр. Ул аларга айткян: ўлякся жаткан тӧшкя бӧркӧтляр жыйылыр, дигян.

18-нче бюлем.

1 Ул тагы аларга жалан теляк итяргя, моңаймый торорга киряклене мясял китереб айткян.

Зач. 88.

2 Бер калада Алладан да курыкмаган, кешедян дя оялмаган тюря бар икян.

3 Шул каладук бер тол катын бар икян; ул тюрягя барыб, син мине даучымнан жакласана диб онгай айтя икян.

4 Тик тюря озакка чаклы жакласы килмягян. Суңыннан ўзеня ўзе айткян: мин Алладан да курыкмасам да, кешедян дя оялмасам да,

5 Бу тол катын миңа тынгы бирмягянгя кюря, аны жаклыйымчы, мыннан былай ул килеб, мине абтратмасын, дигян.

6 Аннары Ходай айткян: дӧрӧс тӧгӧл тюрянен ней айткянен эшетясез ме?

7 Алла Ўзеня кӧнӧ, тӧнӧ тилмеря торган Ўзе сайлаган кешелярен, озак жакламаган кюк тейся дя жакламас меней?

8 Мин сезгя айтямен: аларны тиз жаклар. Тик Ӓдям Улы килеб, жир ӧстӧндя ышаныуны табар микян? дигян.

9 Тагы ўзлярен ўзляре дӧрӧскя куйыб, ӓммя бютяннярне кимгя куя торган кешеляргя шушы мясялне айткян.

Зач. 89.

10 Ике кеше чиркяўгя теляк итяргя кергянняр: берсесе фарисей, икенчесе мытарь.

11 Фарисей тороб, ўз эченнян былай диб телягян: эй Алла! Сиңа тау итямен, мин бютян кешеляр кюк тӧгӧл: алар талаучылар, рянжетеўчеляр, уйнашлык итеўчеляр; бу мытарь кюк тя тӧгӧл:

12 Атнасында ике табкыр ураза тотам, бар эшляб табканымнан унынчы ӧлӧшӧн бирямен шул, дигян.

13 Ӓммя мытарь жырактын тороб, кюккя таба кюзен кютяреб карарга да кыймаган, тик ўз кюкрягеня ўзе суга-суга айтеб торган: эй Алла, мин жазыклыга изгелекле бул диб.

14 Сезгя айтямен: шушысы ўз ойоня тегесеннян артыгырак дöрöскя чыгарылыб кайткан; ўзен ўзе ололаучы ар-кем кечегя калдырылыр, äммя ўзен ўзе кечеляўче ололаныр шул, дигян.

Зач. 90.

15 Іисусъ тейенсен диб, Аҥар балаларны да китергянняр; öйрянеўчеляре мыны кюреб, аларны туктатыб торганнар.

16 Äммя Іисусъ, аларны чакырыб алыб, айткян: балаларга Миҥа килергя ирек бирегез, аларны туктатыб тормагыз, Алла Падшалыгы шундыйларныкы шул.

17 Чыннаб айтямен сезгя: Алла Падшалыгын бала кюк кабыл алмаган кеше, аҥар керя алмас, дигян.

Зач. 91.

18 Башлыкларнын берсе Іисустан сораган: эй изге Ойрятеўче, мянге тормошка урыннашыр öчöн, мин ней кылыйым? дигян.

19 Іисусъ аҥар айткян: ник син Мине изге диб айтясен? беряў дя изге тöгöл, тик бер Алла гна (изге).

20 Бойорокларны белясен: уйнашлык итмя, ўтермя, урлама, жалган таныклык итмя, атаҥны, анаҥны саннаб тор, дигян.

21 Ул айткян: мин быларнын барысын да жяштянюк тоттом, дигян.

22 Мыны эшеткяч, Іисусъ аҥар айткян: сиҥа тагы бер гня нястя житмей; нейеҥ бар барысын да сат та жарлыларга öляш, синеҥ малыҥ кюктя булыр, аннары килеб, Миҥа эяреб жöр, дигян.

23 Äммя ул мыны эшетеўе белян, кайгыга тöшкян, ул бик бай икян шул.

24 Іисусъ анын кайгыга тöшкянен кюреб, айткян: байларга Алла Падшалыгына кереўе ничек читен!

25 Бай кешегя Алла Падшалыгына кереўдян дöягя иня кюзеннян ўтеўе асатрак, дигян.

26 Мыны эшеткян кешеляр айткянняр: кем котола алыр суҥ? дигянняр.

27 Іисусъ айткян: кешеляр булдыра алмаганны Алла булдыра ала, дигян.

28 Шунда Петръ айткян: мына без барын да калдырыб, Сиҥа эярдек, дигян.

29 Іисусъ аларга айткян: чыннаб айтямен сезгя: Алла Падшалыгы öчöн, öйöн, жя атасын, анасын, жя ага-энелярен, жя тута-сеҥнелярен, жя катынын, жя балаларын калдырган кеше беряў дя,

30 Äле шушы багытта да артыгы белян алмый калганы жук, äммя буласы гумердя мянге тормошно алыр, дигян.

Зач. 92.

31 Ун ике (ӧйрянеӱчесен) читкя чакырыб алыб, аларга ӓйткян: мына без Іерусалимга менеб барабыз; Ӓдям Улы турысында пагамбярляр жазган сюз барда шунда жиреня килер:

32 Аны жалган деннеляргя тотоб бирерляр, Аннан мыскыл итярляр, Аны курларлар, Аҥар тӧкӧрӧб тутырырлар;

33 Аны кыйнарлар, ӱтерерляр, Ул ӧчӧнчӧ кӧннӧ терелеб торор, дигян.

34 Тик ӧйрянеӱчеляре мыннан бер нястя дя аҥнамаганнар; бу сюз аларга жяшерен булгаи, ней ӓйтелгянне аҥыша алмаганнар.

Зач. 93.

35 Іисусъ Іерихонъ каласына жакыннашкан чагында, бер сукыр кеше жул буйында сораныб утыра икян.

36 Ӱзенен жаныннан ӱтеб барган калыкны эшетеб, ул: бу ней? диб сораган.

37 Аҥар: Назорей Іисусъ киля дигянняр.

38 Аннары ул: эй Давидъ Улы Іисусъ, мине жарлыка диб кычкыра башлаган.

39 Алдан бара торган кешеляр аҥар дяшяргя кушмаганнар, ӓммя ул: эй Давидъ Улы, мине жарлыка диб, бигеряк тя нык кычкырган.

40 Іисусъ туктаб, сукырны Ӱз жанына китерергя кушкан; ул Анын катына килгяч, Іисусъ аннан сораган:

41 Мин сиҥа ней кылганны телейсен? дигян. Ул ӓйткян: эй Ходай! кюря торган булсам ыйы, дигян.

42 Іисусъ аҥар ӓйткян: кюря торган бул, ышаныуыҥ сине коткарды, дигян.

43 Ул шул сяттюк кюря торган булган, аннары Аҥар эяреб, Алланы даннаб жӧргян. Бар калык та мыны кюреб, Алланы мактаган.

19-нчы бюлем.

Зач. 94.

1 Аннары Іисусъ Іерихонга кереб, кала эченнян барган.

2 Шунда мытарлар башлыгы Закхей атлы бай кеше

3 Іисусны кюрергя тырышкан, тик ӱзе тябяняк булганга кюря, калык артында тороб, кюря алмаган;

4 Алга жӧгӧрӧб узыб, Іисусны кюрер ӧчӧн, смоковница агачына менгян, Іисусъ шул агачнын жаныннан узасы икян.

5 Іисусъ шул урынга житкяч, кюзе тӧшӧб Закхейне кюргян, кюргяч, аҥар ӓйткян: Закхей, тизеряк тӧш, Миҥа бӧгӧн синеҥ ӧйӧҥя керергя киряк, дигян.

6 Ул ашыгыб тӧшкян дя Аны сӧйӧнӧб кабыл алган.

7 Мыны кюреб, бар кешеляр дя зарланганнар, Ул жазыклы кешегя керде дейешкянняр.

8 Äммя Закхей тороб, Іисуска äйткян: эй Ходай, малымнын жартысын жарлыларга бирермен, äгяр беряўне-беряўне бер-бер туры белян рянжеткян булсам, дюрт öлöш кайтарырмын, дигян.

9 Іисусъ аңар äйткян: бöгöн бу жортка котолоу килде, ул да Авраамъ улы шул,

10 Äдям Улы жугалганны эзляб табыб, коткарырга килде, дигян.

11 Алар мыны тыңнаб торган чакта, Іисусъ шуңар öстяб мясял äйткян; Ул Іерусалимга жакын булганга кюря, алар Алла Падшалыгы тиз ачыласы диб уйлаганнар икян.

Зач. 95.

12 Іисусъ äйткян: оло затлы беряў ўзеня падшалык алыб кайтырга жырак жиргя китясе булган.

13 Ул ўзенен ун колон чакырыб алыб, аларга ун мина биреб äйткян: мин кайткынчы былар белян сатыу итеб табышланыгыз, дигян.

14 Тик кала кешеляре аны кюрялмыйлар икян, алар анын артыннанук илчеляр жибяреб, анын безгя падша булыуын телямейбез диб äйттергянняр.

15 Ул кеше падша булыб кайткач, кöмöш биргян коллары äр-берсе ней чаклы табыш иткянне белер öчöн, аларны чакырткан.

16 Элекесе килеб äйткян: эй эям, синең бер минаң ун мина табыш китерде, дигян.

17 Эясе аңар äйткян: жакшы, арыу колом; äздя дöрöс булганыңа кюря ун каланы башкарыб тор, дигян.

18 Аннары икенчесе килеб äйткян: эй эям, синең бер минаң биш мина табыш китерде, дигян.

19 Мынысына да äйткян: син дя биш калага баш бул, дигян.

20 Аннары öчöнчöсö килеб äйткян: эй эям, мына синең минаң, мин аны жаулыкка тöрöб, саклаб тоттом;

21 Мин сиднян куркыб тордом, син каты кеше шул: ўзең салмаганны аласын, ўзең чячмягянне урасын, дигян.

22 Эясе аңар äйткян: эй жаман кол, сине ауызыңнан чыккан сюзляреңбелян айыбларым: минем каты кеше икянемне, салмаганны алганымны, чячмягянне урганымны син белгян,

23 Белгяч, ник суң кöмöшöмнö табыш биреўчеляргя биреб тормадың? мин кайткач, аны табышы белян алган булыр ыйым, дигян.

24 Аннары шунда тороучыларга äйткян: аннан минаны алыгыз да ун минасы барга бирегез, дигян.

25 Аңар айткянняр: эй башкарыучы, анын ун минасы барла баса, дигянняр.

26 Сезгя айтямен: барга бирелер, әммя жуктан нейе бар, анысы да алыныр.

27 Мин падшалык итеўне телямягян дошманнарымны мында китерегез дя минем алдымда ўтерегез, дигян.

Зач. 96.

28 Мыны айтеб бетергяч, Іисусъ алга таба Іерусалимга менеб барган.

29 Виѳсфагія белян Виѳанія дигян ауылларга, Елеонъ исемне тауга жакыннашкач, ике өйрянеўчесен жибяреб,

30 Айткян: алдагы ауылга барыгыз; шунда кергяч, өстөня бер чакта да беряў дя атланмаган, бяйляб куйган, жяш ишякне очратырсыз, аны чишеб, алыб килегез;

31 Әгяр беряў-беряў сездян: аны ник чишеб аласыз? диб сораса, аңар былай айтегез: Ходайга киряк булды, дигез.

32 Жибярелгянняр барыб, Ул айткянчя очратканнар.

33 Алар жяш ишякне чишеб алган чагында, анын эяляре аларга айткянняр: ишяк колонон ник чишеб аласыз? дигянняр.

34 Алар жауаб биргянняр: ул Ходайга киряк булды диб.

35 Аннары аны Іисуска китергянняр; ишяк колоно өстөня кейемнярен салыб, Іисусны анын өстөня атландырганнар.

36 Ул атланыб барган чагында, (кешеляр) кейемнярен жул өстөня жяйеб барганнар.

Зач. 97.

37 Аннары Іисусъ Елеонъ тауыннан төшя башлагач, Анын кюб өйрянеўчеляре барысыда бар кюргян кодрятляре өчөн, сөйөнөб, зур тауыш белян Алланы даннаб,

38 Айткянняр: Ходай исеменя килеўче Падша даннаулы! кюктя тынычлык, жугарыда даннау.

39 Шунда калык арасыннан кайсы фарисейляр Аңар айткянняр: эй Өйрятеўче, өйрянеўчеляреңне тый, дигянняр.

40 Әммя Ул аларга жауаб биреб айткян: Мин сезгя айтямен: әгяр былар туктаса, ташлар кычкырырлар, дигян.

41 Калага жакыннашкач, аңар караб, анын өчөн жылый башлаб,

42 Айткян: эй (Іерусалимъ), ичмаса син шушы көнөндя гня булса да сиңа тынычлык китерер өчөн кылынганны белсяңче, тик әле ул синең кюзляреңнян жяшеренеўле.

43 Сиңа көнняр килер, ул чакта дошманнарың синең әйляняңнян жир казыб өйөб, чырмаб алырлар, сине әр-бер жагыңнан кысарлар;

44 Сине жимерерляр, Синеӈ балаларыӈны эчеӈдя ўтерерляр, синеӈ эчеӈдя таш öстöндя таш та калдырмаслар, син ўзеӈя котолоу килгян багытны белмядеӈ шул, дигян.

Зач. 98.

45 Аннары чиркяўгя кереб, анда сатыу итеўчелярне, алыучыларны кыуыб чыгара башлаган;

46 Аларга äйткян: жазылган ич: Минем öйöм теляк öйö, äммя сез аны талаучылар оясы иткянегез диб.

47 Аннары кöн сайын чиркяўдя öйряткян. Архіерейляр, княгячеляр, калык башлыклары Аны бетерергя кöй эзлягянняр,

48 Тик Аӈар ней кыларга äмял табмаганнар, бар калык та жаныннан китмейчен Аны тыӈнаб торган шул.

20-нче бюлем.

Зач. 99.

1 Шул кöннярнен берсендя, Іисусъ чиркяўдя калыкны öйрятеб, изге хабяр сöйлягян чагында, архіерейляр, княгячеляр, калык башлыклары Анын жанына килеб,

2 Аӈар äйткянняр: äйтче безгя: Син мыны кем бойороуы белян кыласын? жя мындый кыуатны Сиӈа кем бирде? дигянняр.

3 Ул аларга жауаб биреб äйткян: Мин дя сездян бер турыда соройом,

4 Миӈа äйтегез: Іоаннъ чумылдырыуы кюктян булды мы, äлля кешелярдян ме? дигян.

5 Алар ўз араларында уйлашканнар: кюктян дисяк, Ул äйтер: ник суӈ аӈар ышанмадыгыз? дирер.

6 Äгяр кешелярдян дисяк, бар калык безне таш атыб ўтерерляр, алар Іоанны пагамбяр диб ышаналар шул, дигянняр.

7 Аннары жауаб биреб äйткянняр: кайдан икянен белмейбез, дигянняр.

8 Іисусъ аларга äйткян: Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны äйтмямен, дигян.

Зач. 100.

9 Аннары Іисусъ калыкка шушы мясялне äйтя башлаган: бер кеше жöзöм агачлары утыртыб, аны бакчачыларга табшырыб, ўзе озак багытка читкя киткян.

10 Багыт житкяч, бакчамнан жимешляр бирсенняр диб, бакчачыларга кызмятчесен жибяргян; äммя бакчачылар аны кыйнаб, буш кайтарыб жибяргянняр.

11 Тагы икенче кызмятчесен жибяргян икян, алар мынысын да кыйнаб, мыскыл итеб, буш кайтарыб жибяргянняр.

12 Аннары тагы өчөнчөнө жибяргян, әммя алар анысын да жаралаб, кыуыб чыгарыб жибяргянняр.

13 Шул чакта жөзөм бакчасынын эясе әйткян: инде ней эшлейем икян? сөйгян улымны жибярейем, аны кюреб, оялырлар әлля, дигян.

14 Әммя бакчачылар аны кюреб, ўз араларында уйлашыб әйтешкянняр: бу атасы урнына каласы, әйдягез, аны ўтерейек, аңар каласы мал безнеке булыр, дигянняр.

15 Аны бакчадан чыгарыб, ўтергянняр. Бакча эясе инде аларга ней кылар?

16 Ул килеб, бу бакчачыларны ўтертер дя бакчасын бютянняргя бирер, дигян. Мыны эшеткян кешеляр әйткянняр: алай булмасын ыйы! дигянняр.

17 Әммя Ул, аларга караб, әйткян: өй салыучылар жараусыз кюреб ташлаган таш почмак астына нигез булган диб жазылган сюз нейне белдеря?

18 Шул таш өстөня жыгылган кеше уатылыр, әммя кем өстөня шул таш төшся, аны сытар, дигян.

Зач. 101.

19 Шул чакта архіерейляр белян книгячеляр Іисусъ бу мясялне алар турысында әйткянне белеб, Аны тотоб алырга көй эзлягянняр, тик калыктан курыкканнар.

20 Ўзляре Аны сагалаб тороб, Аңар хайляле кешелярне жибяргянняр, алар ўзлярен изге торган кюк кюрсятеб, Аны башлыкларга, оло тюря кулына тотоб бирер өчөн, бер-бер сюзеннян эляктерсенняр диб.

21 Былар Аннан сораганнар: эй Өйрятеўче, без Синең дөрөс әйткяненңне, дөрөс өйряткяненңне белябез, Син беряўгя дя кешесеня караб кылмыйсын, әммя Алла жулына дөрөс өйрятясен.

22 Без кесаргя имана бирергя тейеш ме, әлля жук мы? дигянняр.

23 Ул аларнын хайлялярен белеб, аларга әйткян: ник сез Мине сыныйсыз?

24 Миңа динарій кюрсятегез: мында кем төсө, кем исеме жазылган? дигян. Алар: кесарнеке дигянняр.

25 Ул аларга әйткян: айса кесарнекен кесаргя бирегез, әммя Алланыкын Аллага (бирегез), дигян.

26 Шулай итеб алар калык алдында Аны сюзгя эляктеря алмаганнар, Анын жауабына исляре китеб, дяшмяс булганнар.

Зач. 102.

27 Аннары терелеб тороу булмас диб әйтеўче саддукейляр арасыннан кайсылары килеб, Іисустан сораганнар:

28 Эй Ӧйрятеўче! Моисей жазган безгя: беряўнен агасы катынны булыб, балалары жук кӧйӧ ўлся, анын катынын энесе алыб, агасына нясел булдырсын диб.

29 Жиде ага-эне бар ыйы, элекегесе катын алгач, баласыз ўлде;

30 Ул катынны икенчесе алды, ул да баласыз ўлде;

31 Аннары аны ӧчӧнчӧсӧ алды, шулай жидесе дя алдылар; алыб, балалар калдырмыйчын ўлделяр.

32 Барысыннан да суӈ катын да ўлде.

33 Терелеб торгач, ул кайсына катын булыр? ул жидесенен дя катыны булган ыйы шул, дигянняр.

34 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: бу дӧнья кешеляре ӧйляняляр дя, кеяўгя дя китяляр,

35 Ӓммя ўлгян жирляреннян терелеб тороб, теге дӧньядя булырга тейешле булганнар ӧйлянмейляр дя, кеяўгя дя китмейляр,

36 Ўляр халляре дя жук, алар пяриштяляргя тиӈ, алар Алла уллары, терелеў уллары шул.

37 Ӓммя ўлгянняр терелеб торасын кыуак жанында Моисей дя кюрсяткян, ул Ходайны Авраамъ Алласы, Исаакъ Алласы, Іаковъ Алласы диб айткян.

38 Алла ўлгянняр Алласы тӧгӧл, ӓммя тереляр Алласы; Аллага барда тере шул, дигян.

39 Мыӈар жауаб биреб, княгячелярнен кайсылары айткянняр: эй Ӧйрятеўче, син жакшы айттеӈ, дигянняр.

40 Шуннан суӈ ич-бер нястя турысында Аннан сорарга кыймаганнар.

41 Ул аларга айткян: Христосны ник Давидъ Улы диб айтяляр?

42 Давидъ ўзе псаломнар княгясендя айтя:

43 Ходай минем Ходайыма айткян: дошманнарыӈны аягыӈ астына салгынчы, Минем уӈ жагымда утыр диб.

44 Айса Давидъ Аны Ходайым диб айткяч, Ул суӈ ничек анын улы була? дигян.

Зач. 103.

45 Бар калык тыӈнаб торган чагында, Ул Ўз ӧйрянеўчеляреня айткян:

46 Княгячелярдян сакланыгыз: алар озон кейем кейеб жӧрӧўне, калык жыйынында кеше башырганны, синагогаларда алда утырыуны, ашка жыйылган жирдя тюргя утырыуны жараталар;

47 Тол катыннарнын жортларын ашаб бетеряляр, кюренер ӧчӧн гня озаклаб теляк итяляр; алар анын ӧчӧн артыгырак айыбланырлар.

21-нче бюлем.

1 Іисусъ кюзен кютяреб карагач, чиркяў тартмасына акча салыб торган байларны кюргян;

2 Шулай тагы ике лепта салган бер жарлы тол катынны кюргян;

3 Кюргяч, айткян: чыннаб айтямен сезгя: бу жарлы тол катын барысыннан да кюберяк салды;

4 Тегеляр барда Аллага бюлякне артыклары бардан салдылар шул, äммя бу катын жарлы кöйö бар барлыгын, бар тормошон салды, дигян.

Зач. 104.

5 Аннары кайсы кешеляр чиркяў турысында, ул бик асыл ташлар белян, китергян бюлякляр белян äйбятлягян диб сöйляшкян чагында,

6 Іисусъ айткян: мына кöнняр килер, мында сез кюря торган нястялярдян таш öстöндя таш та калмас, барысы да жимерелеб бетерелер, дигян.

7 Шунда Аннан сораганнар: эй Öйрятеўче, бу кайчан булыр? былар буласы багытнын билгеляре ничек? дигянняр.

Зач. 105.

8 Ул айткян: сак булыгыз, сезне жангыштырмасыннар; кюбесе Минем исемем белян килерляр, мин (Христосъ) дирерляр. Ул багыт инде жакын: сез аларга эяреб жöрмягез.

9 Сугышлар булганны, калык болганышканны эшеткяч, курыкмагыз, былар элеке булырга тейеш шул, алайда ул äле бетеў тöгöл, дигян.

10 Аларга тагы айткян: калык калыкка, падшалык падшалыкка карышы торор;

11 Урны-урны белян жир бик каты титряр, ачлык булыр, ўлят булыр, кот чыгаргыч нястяляр кюренер, кюктян зур билгеляр беленер.

Зач. 106.

12 Быларнын барысыннан да элгяре Минем исемем öчöн сезне тотоб алырлар, сезне кыуарлар, сезне синагогаларга, жя öтöрмянняргя итеб табшырырлар, сезне падшалар алдына, тюряляр алдына алыб барырлар.

13 Былар сезгя (Минем турда) таныклык итяр öчöн булыр.

14 Сез айтясе жауабыгызны алдан уйлаб тороуны кюнелегездя тотмагыз,

15 Мин Ўзем сезгя сюз дя, белемнек тя бирем, сезгя карышы тороучылар барысы да ул белемнеккя карышы бер сюз дя айтя алмаслар, анар карышы тора алмаслар.

16 Ўз аталарыгыз, ага-энелярегез, туганнарыгыз, дусларыгыз да сезне тотоб бирерляр, кайсыларыгызны ўтерерляр дя.

17 Минем исемем öчöн сезне барысыда кюрялмаслар.

18 Алайда башыгыздагы чячегезнен бöртöгö дя жугалмас.

19 Жаннарыгызны тюземнек белян саклаб торогоз.

20 Іерусалимны дошман чиреўляр чырмаб алганны кюргяч, анын бöлöб бетяре житте диб белегез.

21 Шул чакта Іудеядагылар тауларга качсыннар; кала эчендягеляр аннан чыксыннар: кала тирясендягеляр калага кермясенняр,

22 Ул кöнняр, жазылган барыда жиреня килер öчöн, (Іерусалимга) кайтарасы кöнняр шул.

23 Ул кöннярдя ауырлы катыннарга, имчяк имезеўчеляргя читен булыр. Ул чакта жир öстöндя бик зур ауырлык булыр, бу калыкка каты азаб булыр:

24 Кылыч жöзö белян чабылыб ўтерелерляр, тоткон итеб бар калыкларга да тотконнокка таратылырлар; жалган деннеляр багыты узгынчы, Іерусалимны жалган деннеляр табтарлар.

25 Кояшта, айда, жондозларда билгеляр булырлар, äммя жирдя калыклар жöдяшерляр, кöйöнöшöрляр; дингез дя шаулар, болганыр;

26 Курыкканныктан, дöньягя киля торган бяляларне кöткяннектян, кешелярнен тыннары бетяр, кюктяге чиреўляр кузгалышырлар шул.

27 Шуннан суҥ болотлар öстöндя зур кыуат белян, ололок белян килеўче Äдям Улын кюрерляр.

Зач. 107.

28 Сез шул эшляр була башлагач, тöзлянеб, башыгызны кютярегез, сезнен котолоуыгыз жакыннаша шул, дигян.

29 Аннары аларга ошаш китереб äйткян: смоковница агачына да, бар агачларга да карагыз.

30 Алар жапрак жара башлагач, аны кюреб, жяй жакынны ўзегез белясез.

31Шунын кюк бу билгеляр була башлаганны кюргяч тя, Алла Падшалыгы жакын диб белегез.

32 Чыннаб äйтямен сезгя: шушы тыума беткенче, былар барысы да булыр.

33 Кюк белян жир бетярляр, äммя Минем сюзлярем торор.

34 Ўзегезне ўзегез сак тотогоз, кюб ашаб-эчеб, исереб, дöнья сагышларына биренеб, кюҥеллярегезне ауырайтмагыз, ул кöн сезгя тоймастын килеб житмясен,

35 Ул кöн бöтöн жир жöзöндя тороучыларны барысын да ау кюк килеб каблар.

36 Шуҥар кюря шушы буласы бяляллярдян котолоб, Äдям Улы алдына килергя тейешле булыр öчöн, жалан уяу тороб, теляк итегез, дигян.

Зач. 108.

37 Іисусъ кӧндӧз чиркяӱдя ӧйряткян, аннан чыгыб, тӧннӧ Елеонъ исемне тау ӧстӧндя ӱткязгян.

38 Бар калык та Анын катына иртядянюк чиркяӱгя Аны тыннарга жӧргянняр.

22-нче бюлем.

1Тӧчӧ кюмячляр бяйряме, Пасха дигян бяйрям жакыннашкан.

2 Шунда архіерейляр белян княгячеляр Аны ничек итеб ӱтерергя кӧй эзлягянняр, тик калыктан курыкканнар.

3 Ун икенен берсе, Искаріотъ дигян Іуданын эченя шайтан кергян.

4 Іисусны ничек итеб тотоб бирясесен ул архіерейляргя, башлык кешеляргя барыб сӧйляшкян.

5 Алар сӧйӧнӧшкянняр, аӈар акча да бирмякче булганнар.

6 Ул аларга сюз биргян, Аны калык жук жирдя аларга тотоб бирергя кӧйлӧ багыт эзлягян.

7 Пасха бярянен суя торган тӧчӧ кюмяч кӧнӧ житкян.

8 Іисусъ Петръ белян Іоанны жибяреб айткян: барыгыз, безгя ашарга пасха ӓзерлягез, дигян.

9 Алар Аӈар айткянняр: безгя кайда ӓзерляргя кушасын? дигянняр.

10 Ул аларга айткян: мына сез калага кергян чагында, сезгя комган белян сыу алыб бара торган кеше очорар; анын артыннан барыб, ул кергян ӧйгя керегез,

11 Кергяч, ӧйнӧн эясеня айтегез: Ӧйрятеӱче сиӈа: Мин ӧйрянеӱчелярем белян пасха ашасы бюлмя кайда? диб айтя дигез.

12 Ул сезгя идяненя жяйгян зур бюлмя кюрсятер, шунда ӓзерлягез, дигян.

13 Алар барыб, Ул аларга айткянчя туры китереб, шунда пасха ӓзерлягянняр.

14 Сагат житкяч, Ул шунда кереб утырган, Анын белян ун ике апостоллары да (булганнар).

15 Іисусъ аларга айткян: азабланыр алдымнан шушы пасханы сезнен белян ашасым бик килгян эйе;

16 Сезгя айтямен: мыннан былай Мин аны инде Алла Падшалыгында пасха иткенче ашамам, дигян.

17 Аннары сауытны алыб, тау итеб, айткян: мыны алыгыз да ӱз арагызда соногоз;

18 Сезгя айтямен: Алла Падшалыгы килгенче, жӧзӧм жимешенен сыуын инде эчмямен, дигян.

19 Аннары икмяк алыб, тау итеб, сындырыб, аларга биреб айткян: Бу Минем сезнен өчөн биря торган Тянем; мыны Мине исегезгя төшөрөр өчөн кылыгыз, дигян.

20 Ашаганнан суң, тагы шулай сауытны биреб, айткян: бу сауыт Минем сезнен өчөн агыза торган Каным белян куйган жаңа законъ .

21 Мына инде Мине тотоб биреўченен кулы Минем белян бер өстялдя.

22 Алайда Ӓдям Улы электен жазылганча бара, тик Аны тотоб биреўчегя жаман булыр, дигян.

23 Аннары өйрянеўчеляре бер берсеннян: мыны кайсыбыз кыласы икян диб сорой башлаганнар.

24 Шунда алар арабызда кайсыбыз олога саналырга тейеш диб жиңешя башлаганнар.

25 Іисусъ аларга айткян: падшалар калыкларны тотоб торалар, калыкларны кул астларында тотоучылар жакшылык кылыучылар диб айтеляляр;

26 Ӓммя сез алай төгөл: сезнен арада ологоз иң кече кюк булсын, башлык булыб тороучыгыз кызмятче кюк булсын.

27 Кем оло суң: утыра торганы мы, ӓлля кызмят итя торганы мы? Утыра торганы төгөл ме? Ӓммя Мин сезнен арагызда кызмятче кюк булыб торамын.

28 Миңа ауырлык булган чагында, сез Минем белян бергя булдыгыз.

29 Миңа Атам багадя куйганча, Мин дя сезгя падшалык бирергя багадя куямын,

30 Падшалыгымдагы ашымны сез дя ашасагыз ыйы, эчсягез эйе диб,аннары престолларга утырыб, Израилнен ун ике рыуына хокөм итсягез эйе диб, дигян.

31 Аннары Ходай айткян: эй Симонъ, Симонъ! мына шайтан сезне бодай илягян кюк иляргя сораган ыйы,

32 Тик Мин синең турында, ышаныуың кимемясен эйе диб телядем, син дя бер багытны ўзең ўкенеб, туганнарыңны ныгайт, дигян.

33 Ул Аңар жауаб биргян: Эй Ходай, мин Синең белян бергя өтөрмянгя дя, ўлемгя дя барырга ӓзер, дигян.

34 Іисусъ аңар айткян: эй Петръ, Мин сиңа айтямен: бөгөн ӓтяч кычкыргынчы, син Миннян өч табкыр Аны белмеймен диб таңарсын, дигян.

35 Аннары тагы аларга айткян: Мин сезне кабчыксыз, жанчыксыз, башмаксыз жибяргян чагында, сез бер-бер нястя киряксендегез ме? дигян. Алар: бер нястя дя киряксенмядек диб жауаб биргянняр.

36 Аннары Ул аларга айткян: äммя казер кабчыгы бары, аны да алсын, жанчыгын да алсын; кылычы жугы, кейемен сатыб, кылыч алсын;

37 Сезгя äйтямен: Жазыуда Минем турда äйтелгян сюзнен: усаллар белян тингя саналган дигяне жиреня килясе; Минем турда äйтелгян инде булыб бетя шул, дигян.

38 Алар äйткянняр: эй Ходай, мына мында ике кылыч бар, дигяннр. Ул аларга: житяр, дигян.

Зач. 109.

39 Аннары Іисусъ аннан чыгыб, Ӳз гадятенчя Елеонъ тауына киткян. Анын белян öйрянеӳчеляре дя барганнар.

40 Урнына барыб житкяч, Ул аларга äйткян: алданмас öчöн, теляк итегез, дигян.

41 Ӳзе алардан таш атымы жиргя китеб, тезлянеб тороб, инялгян:

42 Эй Äтей! Син бу сауытны Миннян уздырасы итсяӊ эйе! тик Мин телягянчя тöгöл, äммя Син телягянчя булсын, дигян.

43 Шунда Аӊар кюктян пяриштя тöшöб, Аны ныкландырган.

44 Аннары кюӊеле интеккян чагында бигеряк тырышыб инялгян, Анын тире кан тамчылары жиргя тамган кюк булган.

45 Теляк итеӳеннян тороб, öйрянеӳчеляре катына кайтыб, аларнын кайгыдан жоклауларын очоратыб,

46 Аларга äйткян: ник сез жоклойсыз? алданмыйык дисягез, торогоз, теляк итегез, дигян.

47 Ул мыны äйткян чагында, калык килгян, калык алдыннан ун икенен берсе, Іуда атлысы килгян; ул Іисусны ӳбяргя диб, Аӊар жакыннашкан. Ул аларга былай äйтеб билге куйган икян: мин кемне ӳбсям, шул Ӳзе дигян икян.

48 Іисусъ аӊар äйткян: эй Іуда, син Äдям Улын ӳбеӳ белян тотоб бирясен меней? дигян.

49 Іисусъ жанындагылар, эш нейгя ауышканны кюреб, Аӊар äйткянняр: эй Ходай! кылыч белян чабмыйык мы? дигянняр.

50 Аларнын берсе архіерей кызмятчесенен уӊ колагын чабыб öзгян.

51 Шунда Іисусъ äйткян: теймягез, житяр, дигян; аннары колагына тейенеб, аны тöзяткян.

52 Іисусъ Ӳзеня карышы жыйылыб торган архіерейляргя, чиркяӳ башлыкларына, калык башлыкларына äйткян: талаучыны тотарга чыккандый, сез Мине тотарга кылычлар, казыклар алыб чыкканыгыз.

53 Мин сезнен белян кöн сайын чиркяӳдя булдым, сез миӊа кул кютярмядегез; инде багыт сезнеке, карангылык ирке житте, дигян.

54 Аннары Аны алыб, житякляб архіерей ойөня китергянняр. Петръ жырактын барган.

55 Алар ишек алды уртасында ут жагыб, бары бергя утыргач, Петръ да алар арасына утырган.

56 Бер кызмятче катын анын ут жанында утырганын кюреб, аңар тегяляб караб айткян: бу да Анын белян бергя эйе, дигян.

57 Äммя Петрь Іисусны таныб, катынга айткян: мин Аны белмеймен, дигян.

58 Бер-ауык торгач, икенчесе Петрны кюреб, айткян: син дя тегелярнен берсе, дигян. Петръ ул кешегя: жук, дигян.

59 Бер сагатляб ўткяч, тагы беряў туктаусыз айтеб торган: чыннаб бу да Анын белян эйе, ул Галилея кешесе шул, дигян.

60 Äммя Петръ ул кешегя айткян: син ней айткянне белмеймен, дигян. Шул сяттюк, ул мыны айткян чакта, ӓтяч кычкырган.

61 Шул чакта Ходай боролоб, Петрга караган, карагач, Петръ Ходайнын аңар: ӓтяч кычкыргынчы син Мине өч табкыр таңарсын дигян сюзен исеня төшөргян.

62 Аннары чыгыб китеб, бик тилмереб жылаган.

63 Іисусны тотоб торган кешеляр Аннан мыскыл иткянняр, Аны кыйнаганнар;

64 Аны бөркяб, Анын битеня сугыб, Аннан сораганнар: Сиңа кем сукканны белеб айт, дигянняр.

65 Аннан бютян дя Аңар кюб курлык айткянняр.

66 Көн булгач, калык башлыклары, архіерейляр, княгячеляр жыйылыб, Аны ўзляренен синедріоннарына алыб кергянняр,

67 Кергяч айткянняр: Христосъ Син ме? айт безгя, дигянняр. Ул аларга айткян; сезгя айтсям, сез ышанмассыз,

68 Äгяр сездян сорасам, сез Миңа жауаб бирмяссез, Мине жибярмяссез дя.

69 Мыннан былай Äдям Улы кодрятле Алланын уң жагына утырыр, дигян.

70 Шунда барысы да айткянняр: алай булгач, Син Алла Улы? дигянняр. Ул аларга жауаб биргян: Мин икянне (дөрөс) айтясез, дигян.

71 Алар айткянняр: безгя тагы ничек таныклык киряк? Без Ўз ауызыннан эшеттек инде, дигянняр.

23-нчө бюлем.

Зач. 110.

1 Аннары бөтөн жыйын кузгалышыб, Іисусны Пилатка алыб барганнар.

2 Аны былай диб айыблый башлаганнар: без Анын безнен калыкны котортканын белдек, Ул кесаргя имана бирергя кушмый, Ўзен Падша Христосъ дей, дигянняр.

3 Пилатъ Аннан сораган: Син Іудей Падшасы мы? дигян. Ул аңар жауаб биреб айткян: (дӧрӧс) айтясен, дигян.

4 Пилатъ архіерейляр белян калыкка айткян: мин бу Кешедя бер айыб та табмыймын, дигян.

5 Äммя алар туктаусыз айтеб торганнар: Ул Галилеядан башлаб бу жиргя чаклы, бӧтӧн Іудеядя ӧйрятеб жӧрӧб, калыкны болгата дигянняр.

6 Пилатъ Галилея дигянне эшеткяч, сораган: Ул Галилеянеке меней? дигян.

7 Ул Иродъ жиренен кешесе икянен белгяч, Пилатъ Аны Иродка жибяргян, Иродъ ул кӧннярдя Іерусалимдя икян.

8 Иродъ, Іисусны кюреб, бик сӧйӧнгян, Аны кюбтяннян бирле кюрясе килеб торган икян, Анын турысында кюбне эшеткян икян шул, Аннан бер-бер кодрят кюрем диб торган.

9 Ул Іисустан кюб нястя турысында сораган, тик Ул аңар ич тя жауаб бирмягян.

10 Архіерейляр белян князячеляр Аны бик каты айыблаб торганнар.

11 Äммя Иродъ ўз салдатлары белян Аны кимсетеб, Аннан мыскыл итеб туктагач, Аңар жакты кейем кейгезеб, Аны Пилатка кире жибяргян.

12 Шул кӧннӧ Иродъ белян Пилатъ дусланышканнар, алар элеке бер берсеня дошман икян.

13 Аннары Пилатъ, архіерейлярне, башлыкларны, калыкны жыйдырыб,

14 Аларга айткян: сез миңа бу Кешене калыкны котортa диб китердегез; мына мин сезнен алдыгызда тикшердем, Анда сез кюрсятя торган айыбларнын берсен дя табмадым.

15 Иродъ та шулай табмаган, мин Аны аңар жибяргян эйем, анда да Аны ўтертерлек бер айыбы да табылмаган;

16 Айса Аны кыйнатыб, жибярермен, дигян.

17 Бяйрям какына ул аларга тотконда тороучы беряўне иркенгя жибярергя тейеш икян.

18 Äммя бар калык кычкыра башлаган: Ул ўтерелсен, äммя безгя Варавваны жибяр, дигянняр.

19 Варавва калада (калыкны) болгатканы ӧчӧн, кеше ўтергяне ӧчӧн, ӧтӧрмянгя жабылган икян.

20 Пилатъ, Іисусны жибярясе килеб, жаңадан тауыш кютяргян.

21 Äммя алар: Аны кадаклат! кадаклат! диб кычкырганнар.

22 Ул аларга өчөнчө табкыр айткян: суң Ул нейдей усаллык кылды? Мин Аны ўтерерлек бер айыб та табмадым; инде Аны кыйнатыб, жибярермен, дигян.

23 Äммя алар: Ул кадакланылсын диб бик каты кычкырыб торганнар; архіерейляр белян калык кычкырыб жингянняр.

24 Пилатъ алар дигянчя булсын диб хокөм кылган:

25 Калыкны болгатканы өчөн, кеше ўтергяне өчөн өтөрмянгя жабылган кешене, ўзляре сораганны аларга биргян, äммя Іисусны алар иркеня табшырган.

26 Аны алыб барган чакта, Киринеянын бер Симонъ атлы кешене басыуыннан кайтышлый туктатыб, аңар качны кютяртеб, Іисусъ артыннан бардырганнар.

27 Іисусъ артыннан бик кюб калык барган, тагы кюб катыннар да Анын өчөн ўкереб, жылашыб барганнар.

28 Іисусъ аларга боролоб айткян: эй Іерусалимъ кызлары! Минем өчөн жылашмагыз, бигеряк ўзегез өчөн, балаларыгыз өчөн жылашыгыз:

29 Бала китермей торган катыннар, бала тыудырмаган корсаклар, бала туйдырмаган имчякляр бахетле диб айтер көнняр житяляр.

30 Шул чакта тауларга айтерляр: безнен өсткя ауыгыз! тюбя жирляргя: безне каблагыз! дирерляр.

31 Жяшяреб торган агачка мындыйны кылгач, коро агачка ней булыр? дигян.

Зач. 111.

32 Іисусъ белян бергя ике усалны ўтерергя алыб барганнар.

33 Маңгай урны дигян урынга барыб житкяч, шунда Іисусны да, усалларны да берсен уң жакка, икенчесен сул жакка кадаклаганнар.

34 Іисусъ айткян: эй Äтей! Быларга кичер, алар ней кылганнарын ўзляре дя белмейляр шул, дигян. Аннары Анын кейемнярен жирябя салыб өляшкянняр.

35 Калык караб торган; калык белян бергя башлыклар да мыскыл итеб айткянняр: бютяннярне коткарган, инде ул Алланын сайлаган Христосы булса, Ўзен Ўзе коткарсын, дигянняр.

36 Салдатлар да шулай Анын катына килеб, Аңар серкя сузыб, Аннан мыскыл итеб,

37 Äйткянняр: äгяр Син Іудей Падшасы булсаң, Ўзеңне Ўзең коткар, дигянняр.

38 Аннан жугары качта Грекчя, Римчя, Еврейчя тел белян жазган жазыу булган: бу Іудей Падшасы диб.

39 Кадакланган усалларнын берсе Іисусны курлаб, айткян: Син Христосъ булсаҥ, Ўзеҥне дя, безне дя коткар, дигян.

40 Äммя икенчесе аны тыйыб айткян: ўзеҥя дя азабка бирелергя хокöм ителгяч, äлля син Алладан курыкмыйсын мы?

41 Без дöрöс айыбландык, кылган эшляребезгя тейешлене алдык, äммя Ул ич-бер начар эш кылмаган, дигян.

42 Аннары Іисуска айткян: эй Ходай (Падшалыгыҥа) кергяч, Падшалыгыҥда мине исеҥя ал, дигян.

43 Іисусъ аҥар айткян: чыннаб айтямен сиҥа: бöгöнўк Минем белян жомакта булырсын, дигян.

44 Алтынчы сагат тирясе икян; тугызынчы сагаткя чаклы бöтöн жир карангы булыб торган.

45 Кояш карангыланган, чиркяўдяге чаршау урталый жыртылган.

46 Іисусъ каты тауыш белян кычкырыб айткян: эй Äтей, тынымны Синеҥ кулыҥа табшырамын дигян дя тынын чыгарган.

47 Сотникъ шунда булган эшлярне кюреб, Алланы даннаб, айткян: чыннаб Бу äўлея кеше икян, дигян.

48 Мыны кюрергя жыйылышкан калык барысыда шунда булган эшлярне кюреб, кюкрякляреня суга-суга кайтканнар.

49 Іисусны белгян кешеляр барысыда, Анын артыннан Галилеядан килгян катыннар да мыны жырактын караб торганнар.

50 Шул чакта беряў, киҥяш кешесе, арыу, гадел кеше,

51 Алар киҥяшеня, алар эшеня керешмягян кеше, Іудея жирендяге Аримаѳея каласынын кешесе, Алла Падшалыгын кöтöб тороучы Іосифъ атлы кеше,

52 Пилатка барыб, Іисуснын тянен сораган, Сорагач,

53 Аны качтан алыб, киндергя тöрöб, таш тауга тишеб жасаган кабергя куйган, анда ангынчы беряў дя куйылмаган икян.

54 Ул кöн пятница кöн икян, суббота житеб киля икян.

55 Галилеядан Іисуска эяреб килгян катыннар да шунда барыб кабергя караб, Іисуснын тянен куйганны кюреб торганнар.

56 Аннары кайтыб, мvро да, эйесле нястяляр дя äзерлягянняр. Суббота кöннö, бойорок кушканча, тыныч ўткяргянняр.

24-нче бюлем.

Зач. 112.

1 Атнанын элекенче кöнöндя иртюк шул катыннар, äзерлягян эйесле майларын алыб, кабер жанына килгянняр, алар белян бергя тагы бютян бер-ауык катыннар да килгянняр;

2 Килгяч, кабер ауызындагы таш аударылыб жатканны кюргянняр.

3 Алар кабергя кергяч, Ходай Іисуснын тянен табмаганнар.

4 Алар мыңар абтырашыб торган чакта, кинят аларга жалтраб торган кейем кейенгян ике ир кюренгянняр.

5 Катыннар куркышыб, жӧзлярен жиргя таба каратыб торган чагында, (шул ирляр) аларга айткянняр: ник сез терене ӱлгянняр арасыннан эзлейсез?

6 Ул мында жук: Ул терелеб тордо; Анын сезгя Галилеядя чагында айткянен:

7 Ӓдям Улы жазыклы кешеляр кулына табшырыласы, кадакланыласы, ӧчӧнчӧ кӧнӧндя терелеб торасы дигянен исегезгя тӧшӧрӧгӧз, дигянняр.

8 Катыннар Анын сюзлярен исляреня тӧшӧргянняр дя

9 Кабер жаныннан кайтыб, ун бер (ӧйрянеӱчегя) дя, бютянняренен барысына да мынын барысын да белдергянняр.

10 Былар Магдалина Марiя, Iоанна, Iаковъ анасы Марiя, алар белян тагы бютян катыннар булганнар, апостолларга да мыны алар айткянняр.

11 Апостоллар аларнын сюзлярен жалганга куйганнар, аларга ышанмаганнар.

Зач. 113.

12 Ӓммя Петръ тороб, кабер, жанына жӧгӧрӧб килеб, эйелеб карагач, анда жаткан кипеннярне гня кюреб, шул эшкя ӱз кюӊелендя исе китеб кайткан.

13 Шул кӧннюк алар арасыннан икяӱ Iерусалимнян алтмыш стадiя чамасы жирдяге Эммаусъ дигян ауылга баралар икян.

14 Шунда бар булган эшляр турысында алар ӱз аралый сӧйляшеб барганнар.

15 Алар ӱз аралый сӧйляшеб, уйлашыб барган чагында, Iисусъ Ӱзе аларга жакыннашыб, алар белян бергя бара башлаган.

16 Аларнын кюзляре тотлоккан, шунныктан алар Аны танымаганнар.

17 Ул аларга айткян: сез ӱз арагызда ней турысында сӧйляшеб барасыз? сез нейлектян кайгылы? дигян.

18 Аларнын берсе Клеопа атлысы Аӊар жауаб биреб айткян: Iерусалимдя шушы кӧннярдя ней булганны анда килгян кешеляр арасыннан ӓлля бер Син гня белмейсеӊ ме? дигян. Ул аларга: нейне? дигян.

19 Алар Аӊар айткянняр: Назорей Iисуска ней булганны: Ул Алла алдында, бӧтӧн калык алдында сюзе белян дя, эше белян дя кыуатлы пагамбяр эйе,

20 Безнен архіерейляр, башлыклар Аны ӱтерергя тейешле итеб айыбларга тотоб биргянне. Аны кадаклатканны, дигянняр.

21 Ӓммя без Израилне коткарасы кеше Улдыр диб ӧмӧтлянгян эйек, алай булса да шул эш булганга инде ӧчӧнчӧ кӧн.

22 Безнен арадагы катыннарнын кайсылары безнен исебезне китерделяр: алар иртюк кабер жанына барганнар ыйы,

23 Анда Анын тянен табмыйчы кайтыб, аларга Іисусъ тере диб айтеӱче пяриштяляр кюренгянне айттеляр.

24 Аннары кайсыларыбыз кабер жанына барыб, катыннар айткянчя гел шулай очоратканнар, тик Ӱзен кюрмягянняр, дигянняр.

25 Шунда Іисусъ аларга айткян: эй аҥсызлар, пагамбярляр алдан айткяннен барысына да ышанырга озаклаучы кюҥеллеляр!

26 Христосъ гел шулай азабланыб, Ӱз ололыгына керергя тейеш эйе тӧгӧл ме? дигян.

27 Моисейдян, бар пагамбярлярдян башлаб, бар жазыуда Христосъ турысында айтелгянне аларга аҥнаткан.

28 Аннары алар бара торган ауылларына жакыннашканнар; Іисусъ тагы да арырак барасы кюк булыб торган.

29 Ӓммя алар безнен белян калсана диб, Аны туктатыб торганнар, кӧн дя инде кичкя ауышты дигянняр. Ул кереб, алар белян калган.

30 Алар белян бергя утырган чагында, Ул икмяк алыб, аны бахиллягян дя сындырыб, аларга биргян.

31 Шунда алар кюзляре ачылыб, Аны таныганнар; ӓммя Ул аларга кюренмяс булган.

32 Алар бер-берсеня айткянняр: Ул безнен белян сӧйляшеб, жазыудагы сюзлярне безгя аҥнатыб килгян чагында, эчебездя кюҥелебез эреб барды тӧгӧл ме? дигянняр дя

33 Шул сяттюк тороб, Іерусалимгя кайтыб, ун бер апостолны, алар белян бергя булганнарны да бергя очоратканнар.

34 Апостоллар аларга: Ходай чыннаб терелеб торган, Симонга да кюренгян, дигянняр.

35 Былар да аларга жулда ней булганны да, Іисусны икмяк сындырган чагында таныганнарын да айткянняр.

Зач. 114.

36 Алар бу турыда сӧйляшеб торган чагында, Іисусъ Ӱзе (кинят) алар уртасында тороб, аларга айткян: тынычлык сезгя, дигян.

37 Алар каушаб китеб, куркынышыб, тын кюря торганбыз диб уйлаганнар;

38 Ӓммя Ул аларга айткян: ник куркасыз? шундый уйларны кюҥелегезгя ник кертясез?

39 Минем кулларыма, аякларыма карагыз; бу Мин Ӱзем; Мине кул тейереб караб, жакшылаб кюрегез, тыннын Миндя кюргянегез кюк, ите, сёякляре булмый ич, дигян.

40 Мыны айткяч, аларга кулларын да аякларын да кюрсяткян.

41 Алар сёйӧнӧчляреннян äле дя ышанмыйчын, исляре китеб торганда, Ул аларга айткян: сезнен мында бер-бер ашамныгыгыз бар мы? дигян.

42 Алар Аңар бер кисяк пешергян балык, бер кисяк кярязле бал китереб биргянняр.

43 Ул алыб, алар алдында ашаган.

44 Аннары аларга айткян: Мин сезнен белян бергя чагында, Моисей законында, пагамбярляр жазыуларында, псаломнарда Минем турыда жазылган барысы да жиреня килер диб сезгя айткянемнен дӧрӧс булыуы шушы, дигян.

45 Шул чакта Ул жазыудагын аңнарга аларнын уйларын ачылдырган.

46 Аннары аларга айткян: шушлай жазылган, Христосъ шулай азабланыб, ӱлгян жиреннян ӧчӧнчӧ кӧнӧндя терелеб торорга тейеш эйе,

47 Аннары Іерусалимнян башлаб, бар калыкларга да Минем исемемя тяӱбя итеб, жазыклар кичерелеӱе сӧйлянергя тейеш эйе, дигян.

48 Сез шуңар таныкчылар.

49 Мына сезгя Атам бирясе булганны жибярермен, äммя сез жугартын кыуатка кейенгенче, Іерусалимъ каласында тора торогоз, дигян.

50 Аннары аларны каладан Виѳаніяга чаклы алыб чыккан; шунда кулларын кютяреб, аларны бахиллягян.

51 Аларны бахиллягян чагында, алардан китя-китя, кюккя кютяреля башлаган.

52 Алар Аңар башырганнар, аннары бик сӧйӧнӧшӧб, Іерусалимгя кайтканнар.

53 Кайткач, жалан чиркяӱдя Алланы даннаб, ололаб торганнар. Аминь.

# Іоаннъ жазган арыу Евангеліе.

1-нче бюлем.

Зач. 1.

1 Сюз äўäлтенюк булган, Сюз Аллада булган, Сюз Алла булган.

2 Ул äўäлтенюк Аллада булган.

3 Бар нястя дя Анын арткылы булган, ней гня булса да, Аннан башка ич нястя булынмаган.

4 Анда терелек булган, ул терелек кешеляргя жакты булган.

5 Жакты карангыда жактырыб тора, карангы аны каблаб бетермей.

6 Алладан жибярелгян бер кеше булган, анын исеме Іоаннъ .

7 Ул таныклык итяргя килгян, анын арткылы барысы да ышансыннар диб, ул Жактыны таныкларга килгян.

8 Ул ўзе жакты булмаган, тик Жактыны таныкларга жибярелгян.

9 Дöньягя килеўче äр-бер кешене жактырта торган чын Жакты булган.

10 Ул дöньядя булган, дöнья Анын арткылы булынган, тик дöнья Аны танымаган.

11 Ўзенекеляргя килгян, Ўзенекеляр дя Аны кабыл алмаганнар.

12 Äммя Ўзен кабыл алганнарга, Анын исеменя ышанганнарга, Алла оланнары булырга кыуат биргян;

13 Алар каннан тöгöл, тян няпесеннян дя тöгöл, ир няпесеннян дя тöгöл, äммя Алладан тыуганнар.

14 Сюз тяннянде, дяўляткя, чынныкка тулы кöйö, безнен белян тордо; без Анын ололоґон кюрдек, Атадан жангыз Тыуганнын ололоґодый ололоґон (кюрдек).

15 Іоаннъ Аны таныклаб, кычкырыб äйтя: миннян арттан Килеўче миннян алда булды диб äйткянем Ўзе шушы, Ул миннян алданук бар ыйы шул дей.

16 Анын тулылыгыннан без барыбыз да дяўлят öстöня дяўлят алдык;

17 Законъ Моисей арткылы бирелгян, äммя дяўлят белян чынныык Іисусъ Христосъ аркылы булдылар шул.

Зач. 2.

18 Алланы беряў дя бер чакта да кюргяне жук; Аны тик Атанын куйынындагы жангыз тыуган Улы гна белдерткян.

19 Іудейляр Іерусалимнян  священниклярне, левитлярне Іоаннга: син кем диб сорарга жибяргяч, ул мына былай таныклаган:

20 Ул äйтеб биргян, тангмаган; мин Христосъ тöгöл дигян.

21 Аннары аннан сораганнар: кем суҥ син? Син Илія ме? дигянняр; ул: жук дигян. Пагамбяр ме? дигянняр; ул: жук диб жауаб биргян.

22 Аҥар тагы айткянняр: кем суҥ син? безгя безне жибяргянняргя жауаб бирергя киряк: син ўз турында ней айтерсен? дигянняр.

23 Ул айткян: Исаія пагамбяр айткянчя, Ходайга жулны тöзятегез диб, буш кырда кычкырыучынын ауазы мин, дигян.

24 Жибярелгян кешеляр фарисейляр икян.

25 Алар аннан тагы сораганнар: син Христосъ та булмагач, Илія да булмагач, пагамбяр дя булмагач, суҥ ник чумылдырасын? дигянняр.

26 Іоаннъ аларга жауабка айткян: мин сыуда чумылдырам, äммя сезнен уртагызда сез белмей торган Беряў тора.

27 Ул минем артымнан Килеўче, äммя Ўзе миннян алда булды. Мин Анын башмагынын кайышын чишяргя дя тормоймын, дигян.

28 Бу эш Іоаннъ чумылдырган жирдя, Іорданъ жаныннагы Виѳаварда булган.

Зач. 3.

29 Иртягесен Іоаннъ, ўзеня таба килгян Іисусны кюреб, айткян: мына Алланын дöнья жазыгын Ўз öстöня алыучы Бяряне шушы.

30 Миннян арттан бер Кеше киля,Ул миннян алда булды, Ул миннян элеке бар ыйы дигянем Ўзе шушы.

31 Мин Аны белмейдер эйем, äммя Аны Израилгя кюрсятер öчöн, сыуда чумылдырырга килдем, дигян.

32 Іоаннъ тагы таныклаб айткян: кюктян Тын кюгярчен ряўешле булыб ингянне, Анын öстöндя торганны кюрдем.

33 Мин Аны белмейдер эйем, äммя сыуда чумылдырырга мине Жибяреўче миҥа айтте: Кем öстöня Тын ингянне, Анын öстöндя торганны кюрсяҥ, Святый Тын белян чумылдырыучы шул Ўзе диде.

34 Мин кюрдем, Алла Улы шушы икянне таныклаб айттем, дигян.

Зач. 4.

35 Иртягесен тагы Іоаннъ ике öйрянеўчесе белян тора икян.

36 Ул, киля торган Іисусны кюреб, айткян: мына Алла Бяряне, дигян.

37 Аннан шушы сюзлярне эшеткяч, öйрянеўчеляре икесе дя Іисуска эяреб киткянняр.

38 Іисусь боролоб, аларнын килгянен кюреб, аларга: ней киряк сезгя? дигян. Алар Аҥар айткянняр: эй Равви! Равви дигяне öйрятеўче дигян сюз була: Син кайда торасын? дигянняр.

39 Ул аларга айткян: айдягез, кюрерсез, дигян. Алар барыб, Ул торган жирне кюргянняр, ул кöннö Анын катында ўткяргянняр.

40 Унынчы сагат тирясе икян. Іоаннан Іисусъ турысында эшетеб, Аңар эяргян ике ӧйрянеӳченен берсе Симонъ Петрнын энесе Андрей икян.

41 Ул агасы Симонны элеке очоратыб, аңар айткян: без Мессіяны очораттык, дигян; Мессія дигяне-Христосъ.

42 Аннары аны Іисусъ катына алыб килгян. Іисусъ Симонга таба караб айткян: син Симонъ, Іона улы, син кифа диб аталырсын дигян. Кифа дигяне, (Петръ дигяне) таш дигян сюз.

Зач. 5.

43 Иртягесен Іисусъ Галилеяга бармакчы булгач, Филиппны очоратыб, аңар айткян: миңа эяреб бар, дигян.

44 Филиппъ Андрей белян, Петръ белян бер каланыкы, Виѳсаиданыкы икян.

45 Филиппъ Наѳанаилны очоратыб, аңар айткян: без Моисей законда жазганны, Назаретнын Іосифъ улы Іисусны очораттык, дигян.

46 Äммя Наѳанаилъ аңар айткян: Назареттан бер-бер арыу нястя чыга алыр меней? дигян. Филиппъ аңар айткян: бар, кюр, дигян.

47 Іисусъ, Ӳзеня таба килгян Наѳанаилны кюреб, анын турында айткян: мына, Израилнен чын кешесе, анда жумалаулык жук, дигян.

48 Наѳанаилъ Аңар айткан: Син мине кайдан белясен? дигян. Іисусъ аңар жауабка айткян: Филиппъ сине чакырмастан элеке, син смоковница тӧбӧндя чагында, мин сине кюрдем, дигян.

49 Наѳанаилъ Аңар айткян: эй Ӧйрятеӳче! Син Алла Улы, Син Израиль Падшасы, дигян.

50 Іисусъ аңар жауабка айткян: Мин сиңа сине смоковница тӧбӧндя кюрдем дигянемя кюря, син ышанасын; мыннан кюбне дя кюрерсен, дигян.

51 Аңар тагы айткян: чын, чын сезгя айтямен: мыннан былай ачылган кюкне, Алла пяриштяляре Äдям Улына тӧшӧб, менеб жӧргянне кюрерсез, дигян.

2-нче бюлем.

Зач. 6.

1 Ӧчӧнчӧ кӧннӧ Галилеянын Кана дигян каласында туй булган; Іисуснын анасы да шунда булган.

2 Іисусны да ӧйрянеӳчеляре белян шул туйга чакырганнар.

3 Анда аракы житмягяч, Іисуснын анасы Аңар айткян: аларнын аракылары жук, дигян.

4 Іисусъ аңар айткян: эй äней, (анда) синең белян Минем ней эшебез бар? äле Минем сятем житмягян, дигян.

5 Анасы кызмятчеляргя айткян: Ул сезгя ней кушса, шуны кылыгыз, дигян.

6 Шунда Іудейляр жоласынча тазарыныр өчөн куйган, икешяр, өчяр ўлчяў сыу керешле алты таш чюлмяк бар икян.

7 Іисусъ аларга айткян: сауытларга сыу тутырыгыз, дигян. Алар тулук тутырганнар.

8 (Іисусъ) жяня айткян: инде чайпыб алыгыз да туйда башкарыб жөрөўчегя итеб бирегез, дигян. Алар итеб биргянняр.

9 Башкарыб жөрөўче шул аракыга алмашкан сыуны татыб караган, әммя бу аракыны кайдан алганны белмягян, тик сыуны чайпыб алган кызмятчеляр гня белгянняр; башкарыб жөрөўче шунда кеяўне чакырыб,

10 Аңар айткян: әр-бер кеше элеке жакшы аракыны сона, аннары житярлек эчкяч, чагырагын сона, әммя син аракынын жакшысын мынгынчы саклаган, дигян.

11 Шулай итеб Іисусъ Галилеянын Кана дигян каласында элеке кодрятен кылыб, Ўз ологон кюрсяткян; шунныктан өйрянеўчеляре Аңар ышанганнар.

Зач. 7.

12 Шуннан суң Іисусъ Ўзе дя, Анасы да, агалары да, өйрянеўчеляре дя Капернаумга барыб, анда бер-әз көн торганнар.

13 Іудейлярнен пасхасы жакыннаша башлагач, Іисусъ Іерусалимга килгян.

14 Анда чиркяўдя ўгезляр, сарыклар, кюгярченняр сатыб тороучыларны, акча алыштырыб утырыучыларны очораткан,

15 Очораткач, баудан суккыч жасаб, чиркяўдян барысын да кыуыб чыгарган; сарыкларны да, ўгезлярне дя (кыуыб чыгарган); акча алыштырыучыларнын акчаларын чячкян, өстяллярен дя аударган.

16 Аннары кюгярчен сатыучыларга айткян: быларны мыннан алыгыз, Атамнын өйөн сатыу өйө итмягез, дигян.

17 Шул чагында өйрянеўчеляре: өйөңя кюңел биреўлек мине алыб узды диб жазылган сюзне исляреня төшөргянняр.

18 Іудейляр шуңар карышы Аңар айткянняр: Син былай кыларга кыуатың барны безгя ничек билге белян кюрсятерсен? дигянняр.

19 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: шушы чиркяўне жимерегез, Мин аны өч көндя торгозормын, дигян.

20 Мыңар Іудейляр айткянняр: бу чиркяўне кырык алты жыл торгозганнар, әлля Син аны өч көндя торгозорсон? дигянняр.

21 Әммя Ул чиркяў диб Ўз тянен айткян.

22 Ул ўлгяненнян терелеб торгач, ӧйрянеўчеляре Анын бу айткянен исляреня тӧшӧрӧб, жазылганга да, Іисусъ айткян сюзгя дя ышанганнар.

23 Іисусъ пасха бяйрямендя Іерусалимда чагында, кюб кеше Ул кылган кодрятлярне кюреб, Анын исеменя ышанганнар.

24 Алай да Іисусъ, аларнын барын да белгяне буйынча, аларнын ышаныуына биренебюк бетмягян;

25 Кешене кеше таныклаб тороуны киряксенмягян, кешенен эчендяген Ўзе белгян шул.

3-нчӧ бюлем.

Зач. 8.

1 Фарисейляр арасында Іудея башлыкларынын берсе Никодимъ атлысы бар икян.

2 Ул Іисуска тӧння килеб айткян: эй Ӧйрятеўче, без Синеӊ Алладан килгян Ӧйрятеўче икяненӊне белябез, беряў дя, ӓгяр Алла анын белян булмаса, Син кылган кодрятляр кюк кодрятлярне кыла алмас шул, дигян.

3 Іисусъ аӊар жауаб биреб айткян: чын, чын синӊа айтямен: кем дя кем жаӊадан тыумаса, Алла Падшалыгын кюря алмас, дигян.

4 Никодимъ Аӊар айткян: кеше карт булгач, ничек тыусын? ул анасы эченя икенче табкыр кереб, тыуа алыр меней? дигян.

5 Іисусъ жауаб биргян: чын, чын синӊа айтямен: кем дя кем сыудан, Тыннан тыумаса, Алла Падшалыгына керя алмас.

6 Тяннян тыуган ўзе дя тян, ӓммя Тыннан тыуган, ўзе дя тын.

7 Минем синӊа: сезгя жаӊадан тыуарга тейеш диб айткянемя исеӊ китмясен.

8 Жил теляся кайда ися, анын тауышын да эшетясен,тик анын кайдан килеб, кайда киткянен белмейсен; Тыннан тыуган ӓр-кем шулай була, дигян.

9 Никодимъ Іисуска жауабка айткян: бу ничек булсын? дигян.

10 Іисусъ жауаб биреб, аӊар айткян: син Израиль ӧйрятеўчесе, мыны да белмейсен ме? чын, чын синӊа айтямен:

11 Без белгянне сӧйлӧйбез, кюргянне таныклыйбыз; ӓммя сез безнен таныклауыбызны кабыл алмыйсыз.

12 Мин сезгя жирдягене айткяч тя, сез ышанмыйсыз, сезгя кюктягене сӧйлясям, ничек ышанырсыз? дигян.

Зач. 9.

13 Кюктя тороучы, кюктян ингян Ӓдям Улыннан башка беряўнен дя кюккя менгяне жук.

14 Моисей буш кырда жыланны кютяреб куйган кюк, Ӓдям Улы да шулай кютяреб куйылырга тейеш,

15 Аңар ышаныучы äр-кем мянге тормошло булсын, äммя жугалмасын диб.

Зач. 10.

16 Алла дöньяне шул катле сöйдö, Ӱзенен жангыз тыуган Улын да бирде, Аңар ышаныучы äр-кем мянге тормошло булсын, äммя жугалмасын диб.

17 Алла Ӱзенен Улын дöньягя дöньяне айыблар öчöн жибярмяде, äммя дöнья Анын арткылы котолсон диб (жибярде).

18 Аңар ышаныучы айыбланмый, äммя ышанмаганы äлюк айыблы, ул Алланын жангыз тыуган Улынын исеменя ышанмады шул.

19 Айыбланыу мынын öчöн: дöньягя жакты килде, тик кешеляр, эшляре жаман булганга кюря, жактыдан бигеряк карангыны сöйдöляр.

20 Жаманны кылыучы äр-кем жактыны жаратмыйдыр, эшляре жаманга кюря, жаман эшляре кюренмясен диб, жактыга таба бармый.

21 Äммя дöрöслöк кылыучы кеше, эшлярен Алла кушканча кылганга кюря, эшлярем кюренсен диб, жактыга таба барадыр.

Зач. 11.

22 Шуннан суң Іисусъ öйрянеӱчеляре белян Іудея жиреня килгян, алар белян шунда торган: чумылдырган.

23 Іоаннъ да шулай Салимъ жанындагы Енонда чумылдырган, анда сыу бик кюб икян; кешеляр шунда килгянняр, чумылдырылганнар.

24 Іоаннъ ул чакта öтöрмянгя жабылмаган икян.

25 Шул чакта Іоаннъ öйрянеӱчеляре Іудейляр белян тазарыныу турысында жиңешкянняр.

26 Шунныктан алар Іоаннга килеб äйткянняр: эй öйрятеӱче, синең белян бергя Іорданъ жанында булган Кеше, син таныклаган Кеше, мына Ул чумылдыра, бар да Аңар киляляр, дигянняр.

27 Іоаннъ жауаб биреб äйткян: кешегя кюктян бирелмяся, ул ӱзе ӱз öстöня ич нястя дя ала алмас.

28 Мин Христосъ тöгöл, äммя тик Анын алдыннан жибярелгян гня дигянемя сез ӱзегез миңа таныкчы.

29 Кыз жяряшелгян кеше кеяӱ дейеля, кеяӱ жанында тороб, аңар аң салыб тороучы дусы, кеяӱнен тауышын эшетеб, сöйöня-сöйöня тора.

30 Инде мин шул сöйöнöчкя тулыландым: Аңар артырга, äммя миңа кимергя тейеш.

31 Жугартын Килеӱче барыннан да жугары; жирдян булган ӱзе дя жир, жирнеке кюк сöйляшя дя; кюктян Килеӱче барыннан да жугары.

32 Ул кюргянен, эшеткянен таныклый, тик Анын таныклауын беряӱ дя кабыл алмый.

33 Анын таныклауын кабыл алган кеше, Алла чын икянне кюрсятя.

34 Алладан жибярелгян Алла сюзен айтя шул; Алла Тынны ӱлчяб бирмей.

35 Ата Улны сӧя, барын да Анын кулына биргян.

36 Улга ышаныучы мянге тормошло, Улга ышанмаган кеше ул тормошно кюрмяс, äммя Алланын ачыуы анын öстöндя тора, дигян.

4-нче бюлем.

1 Іисусъ Ӱз турысында: Ул ӧйрянеӱчелярне дя Іоаннан кюберяк таба, аннан кюберяк чумылдыра да дигянне фарисейляр эшеткянне белгян.

2 Тик Іисусь Ӱзе чумылдырмаган, ӧйрянеӱчеляре чумылдырганнар.

3 (Шул хабярне белгяч), Ул Іудеяны калдырыб, тагы Галилеяга киткян.

4 Аҥар Самарiя арткылы ӱтяргя киряк булган.

Зач. 12.

5 Шулай Іисусъ Самарiянын Сихарь дигян каласына, Іаковъ ӱз улы Іосифка öлöш итеб биргян жирнен жанындагы калага кергян.

6 Шунда Іаковъ койосо бар икян. Іисусъ жул барыудан талыгыб, шул койо жанына утырган.

7 Алтынчы сагат тирясе икян. Шунда Самарiя катыны сыу алырга диб килгян. Іисусъ аҥар айткян: Миҥа эчяргя бирче, дигян.

8 Ӧйрянеӱчеляре ашамнык сатыб алырга калага киткянняр икян.

9 Самарiя катыны Аҥар айткян: ничек Син Іудей булыб тороб, мин Самарiя катынынная эчяргя соройсон? Іудейляр Самарiя кешеляре белян катышмыйлар ич, дигян.

10 Іисусъ аҥар жауаб биреб айткян: äгяр дя син Алла дяӱлятен белсяҥ, аннары Миҥа эчяргя бирче диб сиҥа айтеӱченен Кем икянен (белсяҥ), син ӱзеҥ Аннан сорар ыйыҥ, Ул сиҥа тере сыу бирер эйе, дигян.

11 Катын Аҥар айткян: эй Кадерле! Синеҥ сыу алыр нястяҥ дя жук, койо тирян, Син суҥ тере сыуны кайдан алырсын?

12 Син äлля бу койоно биргян Іаковъ атабыздан да олорак мы? мыннан ул ӱзе дя эчкян, балалары да, тыуарлары да (эчкянняр), дигян.

13 Іисусъ аҥар жауаб биреб айткян: бу сыуны эчеӱче äр-кем тагы эчясе килер;

14 Äммя кем дя кем Мин биргян сыуны эчся, анын гумергя эчясе килмяс; Мин аҥар биргян сыу анда мянге тормошка ага торган сыунын чишмясе булыр, дигян.

15 Катын Аҥар айткян: эй Кадерле! миҥа шул сыуны бирче, минем эчясем килмясен эйе, мында сыу алырга да жӧрӧсӧ булмасам ыйы, дигян.

16 Іисусъ аҥар айткян: бар, мында ирен҄не чакырыб кил, дигян.

17 Катын жауаб биреб айткян: минем ирем жук, дигян. Іисусъ аҥар айткян: ирем жук диб син дӧрӧс айттеҥ:

18 Синеҥ биш ирен бар ыйы, ӓлеге ирен дя синҥа ир тӧгӧл, анысын син дӧрӧс айттеҥ, дигян.

19 Катын аҥар айткян: эй Кадерлем! инде мин синеҥ пагамбяр икяненгне кюрямен, дигян.

20 Безнен аталарыбыз (Аллага) шушы тау ӧстӧндя табынганнар, ӓммя сез табына торган урын Іерусалимда дейсез, дигян.

21 Іисусъ аҥар айткян: син Минҥа ышан, багыт килеб житя, ул чакта Атага бу тау ӧстӧндя гня, Іерусалимда гна табынмассыз.

22 Сез нейгя табынганыгызны белмейсез, ӓммя без нейгя табынганыбызны белябез, котолоу Іудейлярдян шул.

23 Мына багыт житяр, инде житте дя, ул чакта дӧрӧс табыныучылар Атага тын белян, чыннык белян табынырлар. Ата Ӱзеня шулай табыныучыларны эзлей шул.

24 Алла тын, Аҥар табыныучылар да тын белян, чынных белян табынырга тейеш, дигян.

25 Катын Аҥар айткян: Христосъ дигян Мессія килясене белямен; Ул килгяч, безгя барын да белдерер, дигян.

26 Іисусъ аҥар айткян: Ул Мин Ӱзем, синеҥ белян сӧйляшеӱче, дигян.

27 Шул чактук Анын ӧйрянеӱчеляре килгянняр, аларнын Анын катын белян сӧйляшеӱеня исляре киткян, алайда ней соройсон Син? диб, жя анын белян ней турысында сӧйляшясен? диб берсе дя айтмягян.

28 Аннары катын чиляген калдырыб, калага кайтыб, кешеляргя айткян:

29 Барыгыз, мин ней кылганны барын да минҥа айтеб биргян кешене кюрегез, Ул Христосъ тӧгӧл микян? дигян.

30 Алар каладан чыгыб, Іисусъ катына килгянняр.

31 Шул арада ӧйрянеӱчеляре Аҥар: эй Ӧйрятеӱче, аша инде дигянняр.

32 Ӓммя Ул аларга айткян: Минем сез белмей торган ашамныгым бар, дигян.

33 Шул сяятлей ӧйрянеӱчеляре ӱз араларында айтешкянняр: ӓлля Аҥар бер-бер кеше ашарга китерде микян? диб.

34 Іисусъ аларга айткян: Минем ашамныгым Мине Жибяреӱченен иркен кылыу, Анын эшен булдырыб житкезеӱ.

35 Сез : тагы дюрт айдан суҥ урак житяр дейсез тӧгӧл ме? Ӓммя Мин сезгя ӓйтямен: кюзлярегезне кютяреб, ашлыкларга карагыз, алар ничек агарганнар инде, урырга житкянняр.

36 Урыучы сауабын аладыр, мянге тормошка жимешляр жыядыр; шулай итеб, чячеўче дя урыучы да бергя сӧйӧнӧшӧрляр.

37 Берсе чячя, икенчесе ура дигян сюз мынҥар бик туры киля.

38 Мин сезне ўзегез эшлямягянне, бютянняр эшлягянне урырга жибярдем, ӓммя сез аларнын эшеня керештегез, дигян.

39 Ул минҥа ней кылганымны барын да ӓйтте диб катын таныклаган буйынча, шул каладагы Самарія кешеляренен кюбесе Іисуска ышанганнар.

40 Шунҥар кюря, самаряннар Анын катына килгяч, бездя бер ауык торсана диб, Анҥар ўтенгянняр. Ул анда ике кӧн торган.

41 Анын Ўз сюзен эшеткяч, Анҥар тагы да кюберяк ышанганнар.

42 Ӓммя катынга ӓйткянняр: инде без синеҥ сюзеҥ буйынча гна ышанмыйбыз, ӓммя ўзебез эшетеб, Ул чыннаб дӧньяне коткарыучы Христосъ икянне белдек, дигянняр.

43 Ике кӧн ўткяч, Іисусъ аннан чыгыб, Галилеяга киткян.

44 Іисусъ Ўзе таныклаб ӓйткян икян: пагамбяргя ўскян жирендя кадер булмый диб.

45 Ул Галилеяга килгяч, Галилея кешеляре, Анын Іерусалимда бяйрямдя бар кылган эшлярен кюргяннектян, Аны кабыл алганнар, бяйрямгя алар да барганнар икян шул.

46 Шулай Іисусъ тагы Галилеянын Кана дигян каласына, сыуны аракыга алмаштырган жиреня килгян.

Зач. 13.

Падша жортонда тороучы бер тюря Капернаумда булган, анын улы чирлей икян.

47 Ул, Іисуснын Іудеядан Галилеяга кайтканын эшетеб, Анын катына килгян дя Анҥар: ўляр халгя житкян улымны барыб тӧзятсяня диб ўтенгян.

48 Іисусъ анҥар ӓйткян:сез, кодрятляр, билгеляр кюрмясягез, ышанмассыз, дигян.

49 Падша жортонда тороучы Анҥар ӓйткян: эй Ходай, улым ўлгенче, барсана дигян.

50 Іисусь анҥар ӓйткян: бар кайт, улыҥ сау инде, дигян. Ул, Іисусъ ӓйткян сюзгя ышаныб, кайтыб киткян.

51 Кайтыб барганда, жулда кызмятчеляре анҥар карышы очораганнар, улыҥ сауыкты дигянняр.

52 Ул алардан сораган: ул кайсы сагаття жиҥеляйде? дигян. Алар аҥар айткянняр: княген жиденче сагаття тир кастасы аны ташлады, дигянняр.

53 Атасы шуннан Іисусъ аҥар: улыҥ сау инде дигян сагат шул сагат булганын белгян. Шуннан суҥ ул ўзе дя, ӧйӧндягеляре дя барысы да (Аҥар) ышанганнар.

54 Бу икенче кодрятне Іисусъ Іудеядан Галилеяга кайткач кылган.

5-нче бюлем.

Зач. 14.

1 Шуннан суҥ Іудейлярнен бяйряме булган, шунда Іисусъ Іерусалимгя килгян.

2 Іерусалимда сарык кабкасы дигян кабка жанында чумына торган урын бар икян, анын жанында ӧстӧн жабкан биш бюлмяле каралды булган, ул Еврейчя Виѳезда дейелгян.

3 Шул бюлмялярдя бик кюб чирлеляр, сукырлар, аксаклар, короган кешеляр сыу кузгалыуын кӧтӧб жатканнар.

4 Шул чумына торган сыуга Ходай пяриштясе багыты-багыты белян тӧшӧб, сыуны болгата икян; болганыу белян сыуга иҥ элеке кергян кеше, нейдей чир белян чирле булса да, сауыга икян.

5 Шунда бер кеше бар икян, ул утыз сигез жыл чирлей икян.

6 Іисусъ анын жатканын кюреб, кюб багыттан бирле чирле икянен белеб, аҥар айткян:сау буласыҥ киля ме? дигян.

7 Чирле Аҥар айткян: киля, эй Ходай, тик сыу болганган чагында, мине сыуга итеб кертер кешем жук, мин барыб житкенче, миннян алдан бютян кеше кереб житя, дигян.

8 Іисусъ аҥар айткян: тор, урныҥны ал да жӧр, дигян.

9 Ул кеше шул сяттюк сауыккан; аннары урнын алган да китя башлаган.

10 Бу кӧн суббота кӧн икян. Шул сяятлей Іудейляр сауыккан кешегя айткянняр: бӧгӧн суббота ич, сиҥа урныҥны кютяреб жӧрӧргя тейеш тӧгӧл, дигянняр.

11 Ул аларга жауаб биргян: мине сауыктырыучы миҥа айтте: урныҥны ал да жӧр диде, дигян.

12 Аннары аннан: сиҥа урныҥны ал да жӧр диб айткян кеше кем? диб сораганнар.

13 Тӧзялгян кеше Ул кем икянне белмягян; Іисусъ шунда булган калык арасына кергян икян.

14 Аннан ары Іисусъ аны чиркяўдя очоратыб, аҥар айткян: мына син сауыктыҥ, инде жазыкланма, сиҥа бигеряк тя жаман булмасын, дигян.

15 Шул кеше Іудейлярргя барыб белдергян: мине сауыктырыучы Іисусъ икян, дигян.

16 Іисусъ шундый эшлярне суббота кӧннӧ кылганы ӧчӧн, Іудейляр Аны кыса башлаганнар, Аны ўтерергя кӧй эзлягянняр.

17 Іисусъ аларга айткян:

Зач. 15.

Атам ӓлегя чаклы кыла, Мин дя кыламын, дигян.

18 Шуҥар кюря Іудейлярнен Аны бигеряк тя ўтеряселяре килгян, Ул субботаны бозоу гна тӧгӧл, Алланы да Атам диб айтеб, Ўзен Аллага тиҥ иткян шул.

19 Мыҥар карышы Іисусъ аларга айткян: чын, чын сезгя айтямен: Атасы кылганны кюрмяся, Улы Ўз Ўзеннян ич ней кыла алмас: Атасы ней кылса, Улы да шулай шуны кыладыр шул.

20 Ата Улны сӧя, Ўзе ней кылганны барын да Аҥар кюрсятя шул; Аҥар былардан да артык эшлярне кюрсятер, сезнен исегез дя китяр.

21 Ата ўлгяннярне терелткян кюк, тере тоткан кюк, Улы да теляся кемне терелтя.

22 Ата беряўгя дя хокӧм итмей, ӓммя бар хокӧмнӧ Улына табшырды,

23 Барысы да Улны, Атаны кадерлягянчя, кадерлясенняр диб. Улны кадерлямей торган кеше, Аны жибяргян Атаны да кадерлямей, дигян.

Зач. 16.

24 Чын, чын сезгя айтямен: Минем сюземне тыҥнаучы, Мине Жибяреўчегя ышаныучы мянге тормошло була, ул хокӧмгя тӧшмӧй, ӓммя ўлемнян терелеккя кючя.

25 Чын, чын сезгя айтямен: багыт житя, инде житте дя, ўлгянняр ул чакта Алла Улынын ауазын эшетерляр, эшеткяч тя терелеб тороорлар.

26 Ата ничек Ўзендя терелекле, шулай Улга да Ўзендя терелекле булыуны бирде .

27 Аннары Аҥар хокӧм итяргя дя кыуат бирде, Ул Ӓдям Улы шул.

28 Мыҥар исегез китмясен: кабердягеляр барысы да Алла Улынын ауазын эшетер багыт житя инде;

29 Жакшылык кылганнары (мянге) торорга терелерляр, ӓммя усаллык иткянняре айыбланырга терелерляр.

30 Мин Ўз иркемнян ич ней кыла алмыймын, дигян.

Зач. 17.

Эшеткянемчя хоком итям, хокомом дорос, Мин шул Мине жибяргян Атам ирке булсын ыйы дим, äммя Ӳз иркем тӧгӧл.

31 Ӓгяр Мин Ӳз турымда Ӳзем гня таныкласам, Минем таныклауым чын тӧгӧл.

32 Минем турымда таныклаучы бютян бар; анын Минем турымда таныклаган таныклыгы чын икянне белямен.

33 Сез Іоаннга жибярдегез, ул чынны таныклады.

34 Алайда Мин кеше таныклауын киряксенмейем, тик мыны сез котолсон диб айтямен.

35 Іоаннъ жана торган, жактырта торган жактырткыч ыйы; сез анын жактысында бер-аз багыт кна сӧйӧнясӧгӧз килгян эйе.

36 Минем Іоаннъ (таныклауыннан) оло таныклыгым бар: Ата Минга кылыб житкезергя биргян эшляр, шушы Мин кыла торган эшляр ӱзляре Минем турыда Мине Ата жибяргянне таныклаб торалар шул.

37 Мине жибяргян Атам Минем турда тагы Ӳзе дя таныклык итте. Ӓммя сез Анын тауышын да эшеткянегез жук, жӧзӧн дя кюргянегез жук.

38 Анын сюзе дя сездя тормой, Аннан жибярелгянгя ышанмыйсыз шул.

39 Жазыуларны тикшерегез, сез алар арткылы мянге тормошло булырбыз диб уйлыйсыз шул. Алар Мине таныклаб торалар.

40 Ӓммя сез тормошло булыр ӧчӧн, Минга килясегез килмей.

41 Мин кеше даннауын киряксенмейем,

42 Ӓммя Мин сезне белям: сездя Алланы сӧйӧӱлек жук.

43 Мин Атам исеменя килдем, äммя сез Мине кабыл алмыйсыз; ӓгяр дя бютян ӱз исеменя кился, аны кабыл алырсыз.

44 Бер Алладан данналыуны эзлямейче, бер берегездян данналыуны гна кабыл алгач, сез ничек ышана алырсыз?

45 Мин Ата алдында сезне айыблар диб уйламагыз: сезне айыблаучы, сез ышаныб тора торган Моисей бар.

46 Ӓгяр сез Моисейгя ышансагыз, Минга да ышаныр ыйыгыз. Моисей Минем турыда жазган шул.

47 Сез анын жазыуларына ышанмагач, Минем сюзляремя ничек ышанырсыз? дигян.

6-нчы бюлем.

1 Шуннан сунг Іисусъ Галилея-Тиверіада дингезенен ары жагына киткян.

2 Анын ауырыуларга кылган кодрятлярен кюргянгя кюря, артыннан кюб калык барган.

3 Іисусъ бер тау őстőня менгян дя шунда őйрянеўчеляре белян утырган.

4 Іудейлярнен пасха бяйряме жакыннашыб киля икян.

Зач.18.

5 Іисусъ кюз кютяреб караб, Аҥар таба кюб калык килгянне кюргяч, Филиппка äйткян: аларны туйдырырга икмяк кайдан сатыб алыйык? дигян.

6 Ул мыны Филиппны сынаб äйткян, äммя Ўзе ней кыларын белгян.

7 Филиппъ Аҥар жауаб биргян: быларнын äр-берсеня аз-аз гна теярлек бирергя дя, ике жőз динарійлек икмяк тя житмяс, дигян.

8 Őйрянеўчеляренен берсе, Симонъ Петрнын энесе Андрей Аҥар äйткян:

9 Мында бер малайнын биш арпа икмяге белян ике кечкеня балыгы бар; тик бу хатле кюб калыкка ул жук кна нястя, дигян.

10 Іисусъ äйткян: аларга утырырга кушыгыз, дигян. Ул тőштя ўлям бик шяб икян. Шулай итеб биш меҥ кешеляб утырганнар.

11 Іисусъ икмяклярне алыб, (Аллага) тау итеб, őйрянеўчеляреня биргян, őйрянеўчеляре утырган кешеляргя(őляшкянняр), шулай балыкларны да äр-берсеня телягянчя биргянняр.

12 Алар туйгач, Ул Ўз őйрянеўчеляреня äйткян: калган сыныкларны жыйыгыз, бер нястясе дя жугалмасын, дигян.

13 Биш арпа икмягенен ашаган кешелярдян калган сыныкларын жыйыб, ун ике карнаша тутырганнар.

Зач. 19.

14 Шул чакта Іисусъ кылган кодрятне кюргян кешеляр äйткянняр: дőньягя килясе пагамбяр чыннаб шушы, дигянняр.

15 Іисусъ, алар килеб, Аны кинят алыб, падша итмякче булганны белеб, жангызы гна тагы тау őстőня менеб киткян.

16 Кич булгач, őйрянеўчеляре дингез жанына тőшкянняр дя

17 Кимягя кереб, дингезнен ары жагына, Капернаумга киткянняр. Карангы була башлаган, äммя Іисусъ алар катына килмей торган.

18 Каты жил чыккан, дингез тулкыннаныб торган.

19 Жегерме биш, жя утыз стадія киткяч, алар дингез őстőннян жяяўляб килеб, кимягя таба жакыннашкан Іисусны кюреб, куркышканнар.

20 Äммя Ул аларга äйткян: бу Мин, курыкмагыз, дигян.

21 Алар Аны кимягя алмакчы булганнар; шул сяттюк кимя алар бара торган жарга килеб туктаган.

22 Дингезнен ары жагында тора калган калык, Іисуснын őйрянеўчеляре кереб утырган кимядян башка, анда бютян кимя

булмаганны, Іисусъ кимягя ӧйрянеӱчеляре белян кермягянне, тик ӧйрянеӱчеляре ӱзляре гня утырыб киткянне иртягесен белгян.

23 Шул арада Ходай бахиллягян икмякне ашаган тӧшкя Тиверіададан бютян кимяляр жакынук килгянняр.

24 Шулай Іисуснын да ӧйрянеӱчеляренен дя анда жугын кюргяч, калык кимяляргя кереб, Іисусны эзлей Капернаумга барган.

25 Аны дингезнен ары жагында очоратыб, Аңар айткянняр: эй Ӧйрятеӱче, Син мында кай арада килдеӊ? дигянняр.

26 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: чын, чын сезгя айтямен: сез икмяк ашаб туйынганыгызга кюря, Мине эзлейсез, ӓммя кодрятляр кюргянегез ӧчӧн тӧгӧл, дигян.

Зач. 20.

27 Сез черей торган ашамнык ӧчӧн тырышмагыз, ӓммя мянге тормошка тора торган ашамнык ӧчӧн (тырышыгыз); аны сезгя Ӓдям Улы бирер; Алла Ата Анын ӧстӧня Ӱз билгесен салды шул, дигян.

28 Шунда Аңар айткянняр: Алла эшлярен кылыйык дисяк, без ней эшлейек суӊ? дигянняр.

29 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: мына Алла эше : Ул Кемне жибярде, сез Шуңар ышаныгыз, дигян.

30 Алар Аңар айткянняр: без кюреб, Сиңа ышанырлык ничек билге кюрсятерсен? Син ней кыларсын?

31 Аларга ашарга икмяк кюктян биргян диб жазганча, безнен аталарыбыз буш кырда манна ашаганнар, дигянняр.

32 Іисусъ аларга айткян: чын, чын сезгя айтямен: сезгя кюктян икмякне Моисей бирмяде, ӓммя Минем Атам сезгя кюктян чын икмякне биря.

33 Кюктян иңеб, дӧньягя терелек биреӱче Ӱзе Алла икмяге, дигян.

34 Аңар айткянняр: эй Ходай! безгя шундый икмякне жалан бир, дигянняр.

Зач. 21.

35 Іисусъ аларга айткян: терелек икмяге Мин Ӱзем: Миңа килеӱче ачыкмас, Миңа ышаныучы бер чакта да сыусамас.

36 Ӓммя Мин сезгя айттем: сез Мине кюреб тя ышанмыйсыз, дидем.

37 Ата Миңа биргяне барысы да Миңа килер, Миңа килеӱчене тышка кыуыб чыгармам,

38 Мин шу Мине жибяргян Ата иркен кылыйым диб кюктян иңдем, ӓммя Ӱз иркемне тӧгӧл.

39 Мине жибяргян Атанын ирке шушы: Ул Минга биргяннен Мин берсен дя жугалтмасын, äммя калдык кöннö барысын да терелтеб торгозсон диб.

Зач. 22.

40 Мине Жибяреўченен ирке шушы: Улны кюреўче, Аңар ышаныучы äр-кем мянге тормошло булсын диб; Мин аны калдык кöннö терелтеб торгозормын, дигян.

41 Анын: кюктян ингян икмяк Мин Ўзем дигян сюзеня Iудейляр ачыулары килеб, зарланганнар.

42 Бу Iосифъ улы Iисусъ тöгöл ме? без Анын атасын да, анасын да белябез ич. Ничек Ул: Мин кюктян иңдем диб äйтя? дейешкянняр.

43 Iисусъ аларга жауаб биреб äйткян: ўз аралый зарланышмагыз.

44 Мине жибяргян Ата тартмаса, Минга беряў дя киля алмас; (Минга килгянне) калдык кöннö терелтеб торгозормын.

45 Пагамбярляр жазганнар: барысын да Алла öйрятер диб. Атадан эшетеб öйрянгян äр-кем Минга киля.

46 Атаны беряў-беряў кюргян дейеў тöгöл бу; тик Алладан Килгян гня Атаны кюрде.

47 Чын, чын сезгя äйтямен: Минга ышанган кеше мянге тормошло, дигян.

Зач. 23.

48 Терелек икмяге Мин Ўзем.

49 Сезнен буш кырда манна ашаган аталарыгыз ўлгянняр.

50 Äммя кюктян иңя торган икмяк шундый: аны ашаучы ўлмяс.

51 Мин кюктян ингян тере икмяк: шушы икмякне ашаучы мянгегя торор. Мин бирясе икмяк Минем тянем; аны Мин дöнья тере торор öчöн бирем, дигян.

52 Шул чакта Iудейляр ўз аралый жиңешя башлаганнар: Ул безгя Ўз тянен ашарга ничек биря алыр? дейешкянняр.

53 Iисусъ аларга äйткян: чын, чын сезгя äйтямен: äгяр сез Äдям Улынын тянен ашамасагыз, канын эчмясягез, сездя терелек булмас.

54 Минем тянемне ашаучы, канымны эчеўче мянге тормошло була; калдык кöннö Мин аны терелтеб торгозормын.

55 Минем тянем чын ашамнык, Минем каным чын эчемнек шул, дигян.

Зач. 24.

56 Минем тянемне ашаучы, канымны эчеўче Миндя тора, Мин дя анда (торам).

57 Мине тере тороучы Ата жибярде, Мин дя Атадан тере торам, Мине ашаучы да Миннян тере торор.

58 Мына кюктян ингян икмяк шушы; ул аталарыгыз ашаган манна кюк тӧгӧл: алар ўлгянняр, äммя бу икмякне ашаучы мянгегя торор, дигян.

59 Быларны Ул Капернаумда, синагогада ӧйряткяндя äйткян.

60 Ӧйрянеўчеляренен кюбесе мыны эшетеб, äйткянняр: бу сюзляр бик сяйер, мыны кем тынгный алыр? дигянняр.

61 Іисусъ ӧйрянеўчеляренен мынгар зарланганын Ўз эченнян белеб, аларга äйткян: сезне шушы шикляндеря ме?

62 Äгяр Äдям Улынын элгяре торган урнына кютярелгянен кюрсягез, ней булыр? Тын тере итя, тян ич тя пайда итмей.

63 Мин сезгя äйтя торган сюзляр тын белян терелек.

64 Тик сезнен арада кайсылары ышанмый торганнары бар, дигян. Ышанмый торганнар кем икянне, Ўзен кем тотоб бирясен дя Іисусъ элгяртенюк белеб,

65 Äйткян: шунын ӧчӧн Мин сезгя äйттем дя: äгяр Атамнан бирелмяся, Минга беряў дя киля алмас диб, дигян.

66 Шуннан сунг ӧйрянеўчеляренен кюбесе Аннан айырылыб киткянняр, Анын белян жӧрмягянняр.

67 Шул чакта Іисусъ ун икесеня äйткян: сезнен дя айырылыб китясегез килмей ме? дигян.

68 Симонъ Петръ Ангар жауаб биргян: эй Ходай, без кемгя барыбыз сунг? Синенг мянге тормош сюзлярен бар.

69 Без Синга ышандык та, Син тере Алланын Улы Христосъ икянне белдек тя, дигян.

70 Іисусъ ангар äйткян: Мин сезне ун икене сайлаб алдым тӧгӧл ме? алайда берегез шайтан, дигян.

71 Ул мыны Симонъ улы Искаріотъ Іудасы турысында äйткян; ул Іисуснын ун ике (ӧйрянеўчесенен) берсе булган кӧйӧ, Аны тотоб бирергя жӧргян шул.

7-нче бюлем.

Зач. 25.

1 Шуннан сунг Іисусъ Галилеядя жӧргян;Іудейляр Аны ўтерергя эзлягянгя кюря, Іудеядя жӧрӧсӧ килмягян.

2 Іудейлярнен чатыр кора торган бяйряме жакыннашкан.

3 Шул чакта Іисуснын агалары Ангар äйткянняр: Син мыннан чык та Іудеягя бар, ӧйрянеўчелярен дя Син кыла торган эшлярне кюрсенняр.

4 Беряў дя бер эшен дя жяшертен кылмый, äммя ўзен билгеле итяргя тырыша ич; Син шундый эшлярне кылгач, инде Ўзенгне дӧньягя кюрсят, дигянняр.

5 Анын агалары да Ангар ышанмыйлар икян.

6 Мыҥар карышы Іисусъ аларга әйткән: әле Минем багытым житмей, әммә сезнен өчөн әр-кайчан багыт.

7 Сезгә дөнья күремсезлек итә алмас, әммә Миҥа күремсезлек итә, Мин анын эшләре жаманныгын таныклыйым шул.

8 Сез шушы бәйрәмгә барыгыз, әммә Мин бу бәйрәмгә бармам, әле Минем багытым килеб житмәгән шул, дигән.

9 Аларга шушыны әйткәч, Галилеяда калган.

10 Тик агалары барыб житкәч, Ул да күренмейче килгән күк кнә бәйрәмгә жәшерен килгән.

11 Бәйрәмдә Іудейләр Аны эзләгәннәр, Ул кайда икән? дигәннәр.

12 Калык арасында Анын турысында төрлөчә сөйләшеү булган; кайсылары: Ул арыу дигәннәр, әммә кайсылары: жук, тик калыкны гна алдандыра дигәннәр.

13 Алайда Іудейләрдән куркыб, берәү дә Анын турысында калык алдында сөйләшмәгән.

Зач. 26.

14 Бәйрәмнен жартысында Іисусъ чиркәүгә кереб өйрәткән.

15 Ул өйрәнмәгән көйө, жазыудагыларны ничек белә диб, Іудейләр исләре китеб сөйләшкәннәр.

16 Іисусъ аларга жауаб биреб әйткән: Минем өйрәткәнем Минеке төгөл, әммә Мине Жибәреүченеке.

17 Анын иркен кыласы килгән кеше бу өйрәтеүне Алладан мы, әллә Ӱземнән гнә сөйлөйөм ме, белер.

18 Ӱз үзеннән сөйләүче үзенә дан эзлей; әммә данны Ӱзен Жибәреүчегә эзләүче чын, Анда дөрөссөзлөк жук.

19 Сезгә законъ Моисей биргән төгөл ме? Алай булса да сезнен берегез дә законча кыйланмый. Ней өчөн сез Мине үтерергә жөрөйсөз? дигән.

20 Калык жауаб биреб әйткән: Синдә жен бардыр, Сине кем үтерергә жөрөй? дигәннәр.

21 Іисусъ мыҥар карышы аларга әйткән: Мин бер эш кылдым, аҥар барыгызнын да исегез китә.

22 Моисей сезгә кистереү куйган, тик ул Моисейдән төгөл, әммә аталардан калган, сез кешене суббота көннө дә кистерәсез;

23 Моисей законы бозолмас өчөн, кеше суббота көннө дә кистерелгәч, Мин бөтөн кешене суббота көннө сауыктырган өчөн, Миҥа ник ачыуыгыз килә?

24 Тыштан тикшермәгез, әммә дөрөс тикшереү белән тикшерегез, дигән.

25 Шунда Іерусалимъ кешеляренен кайсылары айткянняр: äлля Шушыны ÿтерергя жöрöйляр микян?

26 Мына, Ул кеше алдында сöйлöй, Аңар бер сюз дя айтмейляр, äлля Анын Христосъ икяненен чынын башлыклар белделяр микян?

27 Без Анын кайдан икянен белябез, äммя Христосъ килгяч, Анын кайдан икянен беряÿ дя белмяс, дигянняр.

28 Шунда Іисусъ чиркяÿдя öйрятя тороб, кычкырыб äйткян: сез Мине дя белясез, Мин кайдан икянне дя белясез, Мин Ÿз Ÿземнян килмядем, äммя Мине Жибяреÿче чын, Аны сез белмейсез.

29 Мин Аны белямен, Мин Аннан шул, Мине Ул жибярде дя дигян.

30 Шунда Іисусны тотоб алырга келягянняр, тик беряÿ дя Аңар кул тейермягян, Анын сяте житмягян икян шул.

31 Калык арасыннан кюбесе Аңар ышанганнар: Христосъ килгяч, Бу кылган кодрятлярдян дя артык кодрятляр кылар меней? дигянняр.

32 Фарисейляр калык арасында Анын турысында шулай сöйляшкянне эшеткянняр. Шуннан ары фарисейляр белян архіерейляр кызмятчелярне Аны тотарга жибяргянняр.

33 Іисусъ айткян: Миңа сезнен белян торорга кюб калмады, Мин инде Жибяреÿчемя китярмен.

34 Мине эзлярсез, тик табмассыз; Мин барасы тöшкя сез бара алмассыз, дигян.

35 Шул чакта Іудейляр ÿз араларында äйтешкянняр: Ул без таба алмаслык жиргя кайда барырга келей? Äлля Ул Еллиннар арасына таралган (Іудейляр) тора торган тöшкя барыб, Еллиннарны öйрятергя келей микян?

36 Мине эзлярсез, тик табмассыз, Мин барасы тöшкя сез бара алмассыз дигян сюзляре ней икян суң? дигянняр.

Зач. 27.

37 Бяйрямнен калдык кöнö, оло кöнöндя Іисусъ тороб, кычкырыб äйткян: эчясе килгян кеше Миңа килеб эчсен.

38 Миңа ышанган кешенен, Жазыуда äйтелгянчя, эченнян тере сыу иңешляре агыб чыгарлар.

39 Мыны Ул Ÿзеня ышаныучылар аласы Тын турында äйткян; аларга äле, Іисусь данналмаганга кюря, Святый Тын иңмягян икян шул.

40 Калык арасыннан кюбесе шул сюзлярне эшетеб, äйткянняр: чыннаб Ул пагамбяр икян, дигянняр.

41 Кайсылары: Бу Христосъ дигянняр. Äммя кайсылары äйткянняр: Христосъ Галилеядан килер меней?

42 Жазыуда äйтелгян ич: Христосъ Давидъ няселеннян, Виѳлеемнан, Давидъ тыуган жирдян килер диб.

43 Шулай итеб, калык арасында Анын сяятлей жиӊешкянняр.

44 Аларнын кайсылары Аны тотоб алырга келягянняр, алайда беряӳ дя Аӊар кул тейермягян.

45 Кызмятчеляр, архіерейляр белян фарисейляр жанына кайткач, былар аларга айткянняр: сез Аны ник алыб кайтмадыгыз? дигянняр.

46 Кызмятчеляр жауаб биргянняр: бу кеше сойлягян кюк бер чакта да сойлягян кеше жук, дигянняр.

47 Фарисейляр аларга айткянняр: әлля сез дя алдандыгыз мы?

48 Башлыклар арасында, жя фарисейляр арасында беряӳ-беряӳ Аӊар ышанды мы суӊ?

49 Әммя бу калык законны белмей, каргаулы ул, дигянняр.

50 Аларнын берсе, Іисуска тоння килгян Никодимъ, аларга айткян:

51 Безнен законъ, кешенен сюзен элеке тыӊнаб алмаган койо, анын ней кылганын белмягян койо, кешене айыблый мы? дигян.

52 Мыӊар карышы аӊар айткянняр: әлля син дя Галилеянеке ме? тикшереб кара, Галилеядян пагамбяр килгяне жукны кюрерсен, дигянняр.

53 Аннары барысы да ойляреня таралышканнар.

8-нче бюлем.

1 Іисусъ Елеонъ тауына киткян.

2 Иртягесен тагы чиркяӳгя килгян, бар калык та Анын катына килгян. Ул утырыб, аларны ойряткян.

Зач. 28.

3 Шунда княгячеляр, фарисейляр уйнашлыкта тотолган бер катынны алыб килеб, аны уртага торгозоб,

4 Іисуска айткянняр: эй Ойрятеӳче! бу катынны уйнашлыкта тоттолар;

5 Моисей законда шушындыйларны таш белян атыб ӳтерергя кушкан, әммя Син ней айтерсен? дигянняр.

6 Аны айыблар очон бер-бер нястя табарбыз әлля диб, шулай Аны сынаб айткянняр икян. Әммя Іисусъ тюбян эйелеб, аларга карамыйчын, бармагы белян жиргя жазыб торган.

7 Аннары алар Іисустан тагы да сораб торгач, Ул кютярелеб, аларга айткян: сезнен кайсыгыз жазыксыз, шул иӊ элеке аӊар таш атсын, дигян.

8 Тагы тюбян эйелеб, жиргя жазыб торган.

9 Алар мыны эшеткяч, ӳз айыбларын кюӊелляре сиздеря торгач, ололары да, кечеляре дя барда, берсе артыннан берсе чыга башлаганнар. Тик бер Іисусъ кна, тагы уртада тора торган катын гна калганнар.

10 Іисусъ кютярелеб, катыннан бютян беряўне дя кюрмягяч, аңар айткян: эй катын! сине айыблаучылар кая? сине берсе дя айыбламады мы? дигян.

11 Ул жауаб биргян: эй Ходай, берсе дя (айыбламады) дигян. Іисусъ аңар айткян: Мин дя сине айыбламыйым; бар кайт, инде жазыкланма, дигян.

Зач. 29.

12 Іисусъ тагы калыкка сӧйляб айткян: Мин дӧньягя жакты; Миңа эяргян кеше карангыда жӧрмяс, ӓммя анын терелек жактысы булыр, дигян.

13 Шул чакта фарисейляр Аңар айткянняр: Син Ўз турыңда Ўзең таныклык итясен, Синең таныклыгың чын тӧгӧл, дигянняр.

14 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: Мин Ўз турымда Ўзем таныклык итсям дя, Минем таныклыгым чын; Мин кайдан килеб, кая барыуымны белямен шул, ӓммя сез Минем кайдан икянемне, кая барыуымны белмейсез.

15 Сез тянчя тикшерясез, Мин беряўне дя (алай) тикшермеймен.

16 Мин тикшерсям дя Минем тикшереўем чын, Мин жангыз тӧгӧл, Мин Мине жибяргян Ата белян бергя шул;

17 Сезнен законыгызда да: ике кешенен иткян таныклыгы дӧрӧс диб жазылган ич.

18 Мин Ўз турымда Ўзем таныклык итям, Минем турда Мине жибяргян Ата да таныклык итя, дигян.

19 Шул чакта Аңар айткянняр: Атаң кая? дигянняр. Іисусъ жауаб биргян: сез Мине дя, Минем Атамны да белмейсез; ӓгяр сез Мине белсягез, Минем Атамны да белер эйегез, дигян.

20 Бу сюзлярне Іисусъ чиркяўдя ӧйряткяндя, чиркяў казнасы саклана торган тӧштя сӧйлягян. Анын сяте ӓле житмягянгя кюря, Аны беряў дя тотоб алмаган.

Зач. 30.

21 Іисусъ аларга тагы айткян: Мин китям, сез Мине эзлярсез, аннары жазыклы кӧйӧ ўлярсез; Мин барасы тӧшкя сез бара алмассыз, дигян.

22 Шунда Іудейляр айтешкянняр: ӓлля Ул Ўзен Ўзе ўтерясе була мы? Мин барасы тӧшкя сез бара алмассыз диб айтя, дигянняр.

23 Ул аларга айткян: сез тюбянгелярдян, Мин жугарыгылардан; сез шушы дӧньядян, Мин бу дӧньядян тӧгӧл.

24 Шуңар кюря Мин сезгя: жазыклы кӧйӧ ўлярсез диб айттем дя; ӓгяр сез бу Мин икянгя ышанмасагыз, жазыклы кӧйӧ ўлярсез шул, дигян.

25 Шул чакта Аңар: Син кем суң? дигянняр. Іисусъ аларга айткян: äле сезгя айтеўемчя, Мин баштанук тороучы.

26 Минем сезнен турда сöйлясем, тикшерясем кюб, äммя Мине Жибяреўче чын, Мин Аннан ней эшеттем, шуны дöньягя сöйлöймен дя дигян.

27 Алар Ул аларга Ата турында айткянне аңнамаганнар.

28 Іисусъ аларга тагы айткян: Äдям Улын кютяреб куйгач, бу Мин икянне белерсез, Ўземнян ич-ней кылмаганымны да, äммя Мин Атам Мине öйряткянчя сöйлягянне дя белерсез.

29 Мине Жибяреўче Минем белян бергя; Ата Мине жангыз калдырмады, Мин жалан Аңар жараганны кыламын шул, дигян.

30 Ул мыны сöйлягян чакта, кюб кеше Аңар ышанганнар.

Зач. 31.

31 Шул чакта Іисусъ Ўзеня ышанган Іудейляргя айткян: Минем сюземдя торсагыз, сез Минем чын öйрянеўчелярем булырсыз,

32 Сез чыннықны белерсез, чыннык сезне иркен итяр, дигян.

33 Аңар жауаб биргянняр: без Авраамъ няселе, бер чакта да беряўгя дя кол булыб торганыбыз жук; ник иркен булырсыз диб айтясен? дигянняр.

34 Іисусъ аларга айткян: чын, чын сезгя айтямен: жазык кыла торган äр-кем жазыкка кол;

35 Тик кол öйдя гумергя тормой, äммя ул гумергя тора.

36 Айса Ул сезне иркен ится, сез чыннаб иркен булырсыз.

37 Сез Авраамъ няселе икянне белямен, алайда сез Мине ўтерергя жöрöйсöз, Минем сюзем сезгя сыймый шул.

38 Мин Атамнан кюргянемне айтямен, сез дя атагыздан кюргянне кыласыз, дигян.

39 Аңар жауабка айткянняр: безнен атабыз Авраамъ, дигянняр. Іисусъ аларга айткян: сез Авраамъ оланнары булсагыз, Авраамъ эшлярен кылар ыйыгыз.

40 Äммя Мин Алладан эшеткян чынны айткян кешене сез казер ўтерергя жöрöйсöз; Авраамъ мыны кылмаган.

41 Сез атагызнын эшлярен кыласыз, дигян. Мыңар карышы Аңар айткянняр: без уйнашлыктан тыумаган, безнен Атабыз бер, Алла, дигянняр.

Зач. 32.

42 Іисусь аларга айткян: äгяр Алла сезнен Атагыз булса, сез Мине жаратыр ыйыгыз, Мин Алладан чыгыб килдем шул; Мин Ўз Ўземнян килмядем, Мине Ул жибярде.

43 Сөйляүемне аҥнамаганнығығыз нейлектян? Сюземне тыҥный алмаганнығығыздан.

44 Сезнен атагыз шайтан, сез атагыз телягянне кыларга келейсез; ул баштанук кеше үтереүче булган, чынныкта тора алмаган, анда чынныk жук шул; жалганны сөйлягян чагында, ул үзеннян сөйлөй, ул жалганчы, жалганнын атасы шул.

45 Äммя Мин чынны äйткянгя кюря, сез Миҥа ышанмыйсыз.

46 Сезнен арадан кем Миндя жазык барын кюрсятер? Мин чынны äйткяч, сез ник Миҥа ышанмыйсыз?

47 Алла кешесе Алла сюзлярен тыҥный; сез Алланыкы төгөлгя кюря, тыҥнамыйсыз, дигян.

48 Мыҥар карышы Іудейляр жауаб биреб, Аҥар äйткянняр: Сине Самарія кешесе диб, Синдя жен бар диб без дөрөс äйтябез төгөл ме? дигянняр.

49 Іисусъ äйткян: Миндя жен жук; äммя Мин Атамны кадерлеймен, сез Мине кадерсез итясез.

50 Алайда Мин Үземя дан эзлямеймен, Эзляүче, хокөм Итеүче бар.

Зач. 33.

51 Чын, чын сезгя äйтямен: кем дя кем Минем сюземне тотса, ул үлмяс гумергя, дигян.

52 Іудейляр Аҥар äйткянняр: инде Синдя жен барны белдек. Авраамъ да, пагамбярляр дя үлгянняр, äммя Син: кем дя кем минем сюземне тотса, ул үлмяс гумергя диб äйтясен.

53 Син безнен Авраамъ атабыздан оло меней? ул үлгян, пагамбярляр дя үлгянняр, Син Үзеҥне кемгя куясын? дигянняр.

54 Іисусъ жауаб биргян: Мин Үземне Үзем даннасам, Минем даннауым буш; сез Аллабыз диб äйтя торган Атам Мине данналдыра.

55 Сез Аны белмядегез, äммя Мин Аны белямен; äгяр дя Аны белмейем дисям, Үзем сезгя ошаулы жалганчы булыр ыйым. Äммя Мин Аны белям, сюзен дя тотам.

56 Атагыз Авраамъ Минем көнөмне кюрергя кюнелдян тордо: кюрде дя, сөйөндө дя дигян.

57 Іудейляр Аҥар äйткянняр: Сиҥа äле илле жяш тя жук; Авраамны кюрдеҥ меней? дигянняр.

58 Іисусъ аларга äйткян: чын, чын сезгя äйтямен: Авраамъ булмастан элекюк Мин бар, дигян.

59 Шул чакта Аҥар атар өчөн ташлар алганнар; тик Іисусъ кюренмяс булыб, урталарыннан үтеб, чиркяүдян чыгыб, алга таба киткян.

9-нчы бюлем.

Зач 31.

1 Бара торгач, Іисусъ тыумыштанук сукыр кешене кюргян.

2 Ӧйрянеўчеляре Аннан сораганнар: эй Ӧйрятеўче! кем жазыкланган: ўзе ме,äлля тыудырыучылары мы? ул ник сукыр тыуган? дигянняр.

3 Іисусъ жауаб биргян: ўзе дя, тыудырыучылары да жазыкланмаганнар, äммя анда Алла эшляре кюренергя (шулай тыуган).

4 Мин Мине Жибяреўченен эшлярен кӧн беткенче эшляргя тейеш; тӧн килеб житяр, ул чакта беряў дя эшлей алмас.

5 Мин дӧньядя чагында, Мин дӧньягя жакты, дигян.

6 Шулай дигяч, жиргя тӧкӧрӧб, тӧкӧрӧгӧ белян балчык сыйыклаб, балчыкны сукырнын кюзеня жаккан да

7 Аңар äйткян: бар, Силоамъ сыуында жыуын, Силоамъ дигяне жибярелгян дейеў. Ул барыб жыуынгач, кюря торган булыб кайткан.

8 Шул чакта кюрешеляре дя анын элеке сукыр икянен кюргян кешеляр дя äйтешкянняр: сораныб утырыучы кеше тӧгӧл ме бу? дигянняр.

9 Кайсылары: бу ул дигянняр; кайсылары: аңар ошой дигянняр; ул ўзе дя: ул мин дигян.

10 Шунда аннан сораганнар: кюзлярең ничек ачылды? диб.

11 Ул жауаб биреб äйткян: Іисусъ дигян кеше балчык сыйыклаб, кюзляремя жакты да миңа äйтте: Силоамъ сыуына барыб жыуын диде. Мин, барыб жыуынгач, кюря торган булдым, дигян.

12 Аңар: Ул кайда? дигянняр. Ул: белмейем дигян.

13 Аннары шул элгяре сукыр булган кешене фарисейляргя алыб барганнар,

14 Іисусъ балчык сыйыклаб, анын кюзлярен ачылдырган кӧн суббота икян.

15 Шул кешедян: ничек кюря торган булдың? диб фарисейляр дя сораганнар. Ул аларга äйткян: Ул минем кюзляремя сыйык балчык жакты, аннары мин жыуындым да инде кюрям, дигян.

16 Шул чакта фарисейляр арасыннан кайсылары äйткянняр: бу Кеше Алладан тӧгӧлдӧр, субботаны кадер итмей, дигянняр. Бютянняре äйткянняр: жазыклы кеше шундый кодрятлярне ничек кыла алсын? дигянняр. Шулай итеб, ўз араларында жиңешкянняр.

17 Сукырга тагы äйткянняр: Анын турысында син ней äйтерсен? синең кюзляреңне Ул ачкан ич, дигянняр. Ул äйткян: Ул пагамбяр, дигян.

18 Іудейляр анын элеке сукыр икяненя дя, аннары кюзляре ачылганга да, шул кюзляре ачылган кешенен тыудырыучыларын чакырыб китергенче, ышанмаганнар.

19 Алардан сораганнар: сукыр тыуды диб айтя торган улыгыз шушы мы? ул суң инде ничек кюря? дигянняр.

20 Анын тыудырыучылары аларга жауаб биреб айткянняр: мынын улыбыз икянен дя, сукыр тыуганын да белябез;

21 Ӓммя казер ничек кюря торган булганын белмейбез, анын кюзлярен кем ачканны да без белмейбез: ӳзенен жяше житкян, ӳзеннян соргыз, ӳз турысында ӳзе айтсен, дигянняр.

22 Аны тыудырыучылар Іудейлярдян куркыб, шулай диб айткянняр; кем дя кем Іисусны Христось диб белся, ул кешене синагогадан айырырбыз диб Іудейляр сюз куйышканнар икян шул.

23 Ӳзенен жяше житкян, ӳзеннян сорагыз диб тыудырыучылары шунныктан айткянняр.

24 Шул сяятлей элеке сукыр булган кешене чакырыб, аңар айткянняр: Аллага дан китер; ӓммя без ул Кешене жазыклы диб белябез, дигянняр.

25 Ул аларга жауаб биреб айткян: жазыклы мы Ул, анысын белмеймен, тик элгяре сукыр икянемне, ӓммя казер кюря торган булганымны гна белямен, дигян.

26 Аннан жяня сораганнар: Ул сиңа ней кылды, кюзляреңне ничек ачты? дигянняр.

27 Аларга жауаб биргян: мин инде сезгя айттем, сез тыңнамадыгыз; тагы ней эшетясегез киля? сез дя Анын ӧйрянеӳчеляре буласыгыз киля меней? дигян.

28 Алар аны курлаб айткянняр: син Анын ӧйрянеӳчесе, ӓммя без Моисей ӧйрянеӳчеляре.

29 Моисейгя Алла сӧйлягянне без белябез, ӓммя Бу кайдан икянне белмейбез, дигянняр.

30 Кюзе ачылган кеше аларга жауаб биреб айткян: Ул кайдан икянне белмягянегез, мына шунысы ис китярлек, ӓммя Ул минем кюзляремне ачты.

31 Без белябез: жазыклыларны Алла тыңнамый, тик Алланы кадерляӳчене, Анын иркен кылыучыны гна Алла тыңный.

32 Беряӳ-беряӳ сукыр тыуган кешенен кюзлярен ачканны гумердян бирле эшеткян жук;

33 Ул Алладан булмаса, ич-ней кыла алмас ыйы, дигян.

34 Аңар жауабка айткянняр: син бӧтӧнняй жазык эчендя тыуганың, син безне ӧйрятясен ме? дигянняр дя аны тышка кыуыб чыгарганнар.

35 Іисусъ, аны тышка кыуыб чыгарганны эшеткяч, аны табыб, аӊар айткян: син Алла Улына ышанасын мы? дигян.

36 Ул жауаб биреб айткян: эй Ходай, Ул кем суӊ? мин Аӊар ышаныр ыйым, дигян.

37 Іисусъ аӊар айткян: син Аны кюрдеӊ, Ул синеӊ белян сойляшя, дигян.

38 Ул айткян: эй Ходай, ышанамын дигян дя Аӊар жыгылыб башырган.

39 Іисусъ айткян: Мин бу доньягя хоком итяргя килдем, кюрмей торганнар кюрсенняр диб, әммя кюря торганнар сукырайсыннар диб, дигян.

40 Мыны эшеткяч, Анын катында булган фарисейлярнен кайсылары Аӊар айткянняр: әлля без дя сукыр мы? дигянняр.

41 Іисусъ аларга айткян: сез сукыр булсагыз, жазыгыгыз булмас ыйы, әммя кюрябез дигянегезгя кюря, жазыгыгыз остогоздя кала, дигян.

10-нчы бюлем.

Зач. 35.

1 Чын, чын сезгя айтямен: сарык абзарына ишектян кермейче, бютян жирдян менеб кереўче бур да, талаучы да,

2 Әммя ишектян кереўче сарыкларнын котоўчесе.

3 Ишек саклаучы аӊар ишекне ача, сарыклар анын тауышын тыӊныйлар, ул ўз сарыкларын аты-аты белян чакырыб, алыб чыга.

4 Ўз сарыкларын алыб чыккач, аларнын алдыннан бара, әммя сарыклар, анын тауышын белгянгя кюря, артыннан киляляр.

5 Жат кеше артыннан бармыйлар, әммя аннан качалар, жат кешенен тауышын белмейляр шул, дигян.

6 Іисусъ аларга шушы мясялне айткян; тик алар Ул аларга ней айткянне аӊнамаганнар.

7 Шуӊар кюря Іисусъ аларга тагы айткян: чын, чын сезгя айтямен: Мин сарыкларга ишек;

8 Миннян элгяре килеўчеляр ней катле булса да барысы да бурлар, талаучылар, әммя сарыклар аларны тыӊнамадылар, дигян.

Зач. 36.

9 Мин ишек: кем дя кем Минем арткылы керся, ул котолор, керер дя, чыгар да, котолор жир дя табар.

10 Бур урлар очон, ўтерер очон, харяб итяр очон гня киля. Мин кешеляр артыгы белян терелекле булсыннар диб килдем.

11 Мин арыу котоўче: арыу котоўче сарыклары очон ўз жанын биря.

12 Äммя жалчы, ўзе кӧтӧўче булмаганныктан, сарыклары да ўзенеке тӧгӧллӧктян, киля торган бюрене кюреб, сарыкларны ташлаб кача; шунда бюре сарыкларны талаб тарата.

13 Жалчы кеше жалчы булганныктан кача, сарыклары ӧчӧн дя коймӧй.

14 Мин арыу кӧтӧўче: Мин Ўземнекелярне белямен, Ўзенекеляр дя Мине беляляр.

15 Мине Ата белгянчя, Мин дя Атаны белямен; сарыклар ӧчӧн жанымны да бирямен.

16 Минем тагы бютян сарыкларым да бар, алар бу абзарныкы тӧгӧл; Мин аларны да китерергя тейеш, алар да Минем тауышымны эшетерляр; аннары бер кӧтӧў, бер кӧтӧўче булыр, дигян.

Зач. 37.

17 Ата Мине шушынын ӧчӧн сӧя: Мин жанымны бирямен, аны тагы алыр ӧчӧн.

18 Миннян аны беряў дя (кӧчляб) алмый, äммя Мин аны Ўзем бирямен: Аны бирергя дя кыуатым бар, аны тагы алырга да кыуатым бар. Бу бойорокно Мин Атамнан алдым.

19 Шушы сюзляр сяятлей, Іудейляр ўз араларында тагы жинҕешкянняр.

20 Аларнын кюбесе äйткянняр: Ул женнедер, акылсызлана Ул, Аны ник тынҕныйсыз? дигянняр.

21 Кайсылары äйткянняр: бу сюзляр женне кешенеке тӧгӧл, сукырларнын кюзлярен жен ача алыр меней дигянняр.

22 Іерусалимдя (чиркяўне) жанҕарткан бяйрям житкян, ул чакта кыш икян.

23 Іисусъ чиркяўдя, Соломонныкы дейелгян ал бюлемдя жӧргян.

24 Шунда Іудейляр Анын äйлянясеня жыйылышыб, Анҕар äйткянняр: Син безне озак жӧдятеб торорсон мы? Син Христосъ мы, безгя туры äйт, дигянняр.

25 Іисусъ аларга жауаб биргян: Мин сезгя äйттем, сез ышанмыйсыз; Атам исеменя кыла торган эшлярем, шулар Мине таныклыйлар.

26 Алайда Мин сезгя äйткянчя, сез ышанмыйсыз, сез Минем сарыкларым арасыннан тӧгӧл шул, дигян.

Зач. 38.

27 Сарыкларым Минем тауышымны тынҕныйлар, Мин дя аларны белямен, алар да Минем артымнан киляляр.

28 Мин аларга мянге терелек бирямен, алар жугалмаслар гумергя; Минем кулымнан аларны ич-кем талаб ала алмас.

29 Аларны Минга биргян Атам äр кемнян дя оло; аларны Атамнын кулыннан беряӳ дя талаб ала алмас.

30 Мин дя, Ата да-Без бер, дигян.

31 Шунда Іудейляр Аны ӳтерейек диб, тагы ташлар алганнар.

32 Іисусъ аларга äйткян: Мин Атамнан сезгя кюб жакшы эшляр кюрсяттем; кайсысы öчöн Мине таш белян атыб ӳтерергя келейсез? дигян.

33 Іудейляр Ангар жауаб биреб äйткянняр: Сине таш атыб ӳтерергя келяӳебез арыу эш öчöн тöгöл, äммя Алланы курлауын öчöн, Син Ӳзен кеше кöйö, Ӳзенне Алла итясен, дигянняр.

34 Іисусъ аларга äйткян: сезнен законыгызда жазылган тöгöл ме: Мин äйттем: сез аллалар диб.

35 Алла сюзе äйтелгяннярне Ул аллалар диб äйтеб тя, жазылган бозолмагач,

36 Ата Ӳзе арыулаб, дöньягя жибяргянгя, Мин Алла Улы диб äйткянем öчöн, Алланы курлыйсын диб ник äйтясез?

37 Äгяр Мин Атам эшлярен кылмыйым икян, Минга ышанмагыз;

38 Äгяр кылам икян, Ӳземя ышанмасагыз, Ата Миндя, Мин Атада икянне белеб ышаныр öчöн, эшляремя ышаныгыз.

39 Шул чакта алар Аны тагы тотарга келягянняр, äммя Ул аларнын кулларына тоттормый киткян.

40 Аннары тагы Іорданнын ары жагына, элгяре Іоаннъ чумылдырган тöшкя барган да, шунда калган.

41 Анын катына кюб кеше килгян; алар: Іоаннъ бер тöрлö кодрят тя кылмаган ыйы, äммя Іоаннын Мынын турында äйткяне барысы да чын икян диб, сöйляшкянняр.

42 Шунда кюб кеше Ангар ышанганнар.

11-нче бюлем.

Зач. 39.

1 Виѳанія ауылынын Лазарь атлы беряӳ чирлей икян; Марія ӳз тутасы Марѳа белян шунда торалар икян.

2 Бу агасы Лазарь чирлягян Марія Ходайны мѵро белян майлаб, Анын аякларын чяче белян сöрткян Марія.

3 Алар туталы сеңнеле (икесе дя) Іисуска: эй Ходай! мына Син сöйгян кеше чирлей диб äйтергя кеше жибяргянняр.

4 Іисусъ, мыны эшеткяч, äйткян: бу чир ӳляргя тöгöл, äммя Алла данналыр öчöн, бу чир сябяблей Алла Улы данналыр öчöн, дигян.

5 Іисусъ Марѳаны да, анын сеңнесен дя, Лазарне дя сöя икян.

6 Ул, Лазарнен чирлягянен эшеткяч, шул тора торган урнында ике кöн торган.

7 Шуннан суҥ өйрянеўчеляреня әйткян: тагы Іудеягя барыйык, дигян.

8 Өйрянеўчеляре Аҥар әйткянняр: эй Өйрятеўче, іудейляр Сине таш атыб ўтерергя кляўляре кюбтян ме әле? Син тагы анда барасыҥ, дигянняр.

9 Іисусь аларга жауаб биргян: көн ун ике сагат төгөл ме? көндөз жөргян кеше, бу дөньянен жактысын кюргянгя кюря, сөртөнмөй.

10 Әммя төння жөргян кеше, жактысы жукка кюря, сөртөня, дигян.

11 Мыны әйткяннян суҥ, аларга тагы әйткян: дусыбыз Лазарь жокога китте, Мин аны уятырга барамын, дигян.

12 Өйрянеўчеляре әйткянняр: эй Ходай, жокога киткян булса, айса сауыгыр, дигянняр.

13 Іисусъ анын ўлгянен әйткян икян; әммя алар Ул гадятчя жоклау турысында әйтя диб уйлаганнар.

14 Шунда Іисусъ аларга туры әйткян: Лазарь ўлде;

15 Мин анда булмаганыма сезнен өчөн, сез ышанасыга кюря сөйөням; әйдягез, инде аҥар барыйык, дигян.

16 Шунда игез дигян Өома өйрянеўчеляргя әйткян: әйдягез, без дя Анын белян бергя ўлейек, дигян.

17 Іисусъ килгяндя Лазарнен кабердя жатыуына дюрт көн ўткян икян.

18 Виөанія Іерусалимнан жакын гна, ун биш стадія чамасы гна икян.

19 Іудейлярнен кюбесе Марөа белян Марія катына аларны агалары кайгысыннан жыуатырга килгянняр.

20 Іисусъ киля диб эшеткяч, Марөа Аҥар карышы чыккан, Марія өйдя утыра калган.

21 Шунда Марөа Іисуска әйткян: эй Ходай! Син мында булган булсаҥ, агам ўлмяс эйе;

22 Әммя әле дя белямен: Син Алладан ней гня сорасаҥ да, Алла Сиҥа бирер, дигян.

23 Іисусъ аҥар әйткян: агаҥ терелеб торор, дигян.

24 Марөа Аҥар әйткян: калдык көннө, терелеў багытында анын терелеб тороронбелямен, дигян.

25 Іисусъ аҥар әйткян: терелтеўче, тере тотоучы Мин Ўзем; Миҥа ышаныучы ўлся дя терелеб торор;

26 Миҥа ышаныучы әр-бер кеше ўлмяс гумергя. Мыҥар ышанасын мы? дигян.

27 Марөа Аҥар әйткян: дөрөс, эй Ходай! Алланын дөньягя килеўче Улы Христосъ икяненя ышанамын, дигян.

28 Мыны әйткяч, ул кайтыб, жяшерен гня ўз сеӈнесе Маріяны чакырыб, аӈар: Ӧйрятеўче мында, Ул сине чакыра, дигян.

29 Марія эшетеў белян, тизеряк тороб, Анын катына киткян.

30 Іисусъ әле ауылга кермягян икян, Ул Аны Марѳа очораткан тӧштя тора икян.

31 Аны жыуатырга килгян, анын ӧйӧндя булган іудейляр, Маріянын ашыгыб тороб, чыгыб киткянен кюргяч, ул кабергя жыларга бара торгандыр диб уйлаб, анын артыннан барганнар.

32 Марія Іисусъ туктаб торган урынга килгяч, Аны кюреб, Анын аягы астына жыгылыб, Аӈар әйткян: эй Ходай! әгяр Син мында булган булсаӈ, агам ўлмяс эйе, дигян.

33 Іисусъ, ул жылаганны, анын белян бергя килгян Іудейлярнен дя жылауларын кюргяч, Ўзе дя жаны белян кӧйӧнӧб, кюӈеле тулыб,

34 Әйткян: аны кайда куйдыгыз? дигян. Аӈар әйткяннар: эй Ходай! барыб кюр, дигянняр.

35 Іисуснын кюзляре жяшлянгян.

36 Шул чагында Іудейляр әйтканняр: кара, Ул аны ничек сӧйгян, дигянняр.

37 Кайсылары әйткянняр: сукырнын кюзен ачыучы Бу мыны да ўлмягян кӧйӧ калдыра алмады микян ней? дигянняр.

38 Іисусъ тагы эченнян кайгырыб, кабер жанына килгян. Кабер тау кыуышында икян, ауызына таш каблаган икян.

39 Іисусъ әйткян: ташын алыгыз, дигян. Ўлекнен сеӈнесе Марѳа Іисуска әйткян: эй Ходай! ул инде сасыган, анын кабердя жатыуына инде дюрт кӧн, дигян.

40 Іисусъ аӈар әйткян: әгяр син ышансаӈ, Алланын ололоѓон кюрерсен диб Мин сиӈа әйттем тӧгӧл ме? дигян.

41 Аннары ўлек жаткан кабер ауызыннан ташны алганнар. Іисусъ кюзлярен кюккя таба кютяреб, әйткян: эй Әтей! Мине тыӈнаганыӈа Сиӈа тау итямен.

42 Мине жалан тыӈнасыӈны Мин белядер эйем, тик мыны мында тора торган калык ӧчӧн, Мине Син жибяргянгя ышансыннар диб әйттем, дигян.

43 Мыны әйткяч, Ул шяб тауыш белян кычкырган: эй Лазарь! чык тышка, дигян.

44 Шундук ўлек куллары, аяклары кипеннягя тӧргян кӧйӧ, бите жаулык белян бяйлягян кӧйӧ чыккан. Іисусъ аларга әйткян: аны чишегез, жӧрсӧн, дигян.

45 Марія катына килгян Іудейлярнен кюбесе шул чагында Іисуснын кылган эшлярен кюреб, Аӈар ышанганнар.

46 Кайсылары фарисейляр катына барыб, Іисусъ ней кылганны аларга айткянняр.

Зач. 40.

47 Аннары архіерейляр белян фарисейляр синедріонны жыйыб, без ней эшлейек, бу кеше кюб кодрят кыла? дигянняр.

48 Ӓгяр дя Аны шул койӧ калдырсак, барысы да Аңар ышаныб бетярляр; аннары Римъ калкы килеб, жиребезне дя, калыгыбызны да ӱз кулына алыр, дигянняр.

49 Аларнын берсе, шул жылны архіерей булыб тороучы Каіафа аларга айткян: сез бер нястя дя белмейсез,

50 Бӧтӧн калык ӓрям булгынчы, кешеляр ӧчӧн бер гня кешенен ӱлгяне безгя жакшырак булырын да уйламыйсыз, дигян.

51 Ул мыны ӱзлегеннян айтмягян, ӓммя шул жылны архіерей булганныгыннан, Іисуснын калык ӧчӧн ӱлясесен алдан айткян.

52 Калык ӧчӧн гня тӧгӧл, ӓммя Алланын таралган оланнарын бергя жыяр ӧчӧн дя ӱлясе.

53 Шул кӧннян суң Аны ӱтерергя куйганнар.

54 Шуңар кюря Іисусъ Іудейляр арасында шуннан суң кюренеб жӧрмягян, ӓммя аннан буш кырга жакын жакка, Ефраимъ дигян калага барыб, ӧйрянеӱчеляре белян шунда торган.

55 Іудейлярнен пасхасы жакыннашкан; бӧтӧн жирдян кюб кеше, тазарыныр ӧчӧн, пасха алдыннан Іерусалимгя килгянняр.

56 Алар Іисусны эзлягянняр, чиркяӱдя торган чакларында берсеня берсе айтешкянняр: сез ничек уйлыйсыз? Ул бяйрямгя килмяс микян? дейешкянняр.

57 Ӓммя архіерейляр белян фарисейляр, Аны тотоб алыр ӧчӧн, кем дя кем Анын кайда икянен белся, килеб айтергя кушканнар.

12-нче бюлем.

Зач. 41.

1 Пасха бяйряменнян алты кӧн алдан, Іисусъ, ӱлгян Лазарне тергезгян ауылына Виѳаніягя килгян.

2 Анда Іисуска аш жасаганнар, Марѳа кызмят иткян; Іисусъ белян бергя утырыучылар арасында Лазарь дя булган.

3 Ӓммя Марія бер грябянкя ич-ней катыштырмаган нардъ дигян кыйбатлы мѵро алыб килеб, Іисуснын аякларын майлаган да Анын аякларын чяче белян сӧрткян; мѵронын тямне исе белян бӧтӧн ӧй тулган.

4 Шул чагында ӧйрянеӱчеляренен берсе, Симонъ улы, Іуда Искаріотъ дигяне, Іисусны тотоб бирясе булганы айткян:

5 Ник бу мvроны öч жöз динарійгя сатыб, (акчасын) сораныучыларга бирмяскя? дигян.

6 Ул мыны сораныучылар öчöн сагышланыуыннан айтмягян, äммя ÿзе бурга кюря айткян: акча тартмасын ул тоткан, анда салганны ул алыб жöргян.

7 Іисусъ айткян: аҥар теймягез, ул мыны Минем кюмелер кöнöмя саклаб тоткан;

8 Сораныучылар жалан сезнен белян ич, äммя Мин жалан сезнен белян булмам, дигян.

9 Іудейлярнен кюбесе Іисуснын шунда икянен белеб, Анын öчöн гня тöгöл, äммя Ул ÿлгян жиреннян терелтеб торгозган Лазарне дя кюрейек диб килгянняр.

10 Архіерейляр Лазарне дя ÿтерергя куйганнар,

11 Анын сяятлей іудейлярнен кюбесе килеб, Іисуска ышанганнар шул.

12 Бяйрямгя килгян кюб калык икенче кöннö Іисусъ Іерусалимгя киля диб эшетеб,

13 пальма чыбыклары тотоб, Аҥар карышы чыкканнар да: Осанна! Ходай исеменя килеÿче даннаулы, эй Израиль Падшасы! диб кычкырганнар.

14 Äммя Іисусъ жяш ишеккя таб килеб, аҥар атланган, былай диб жазылганча:

15 Эй Сіонъ кызы, курыкма! мына синеҥ Падшаҥ жяш ишяккя атланыб киля дигянчя.

16 Анын öйрянеÿчеляре мыны элеке аҥнамаганнар икян, äммя суҥыннан Іисусъ данналгач, бу Анын турында жазылганны да, Аҥар мыны жазылганча кылганны да исляреня тöшöргянняр.

17 Элеке Іисусъ белян булган кешеляр: Ул Лазарне кабердян дяшеб чыгарды, аны ÿлгяненнян тергезеб торгоздо диб таныклаганнар.

18 Іисуснын бу кылган кодрятен эшеткян буйынча, калык Аны карышы алган.

Зач. 42.

19 Фарисейляр ÿз араларында айтешкянняр: бер нястя дя кылыб булмаганны кюрясез ме? кара, бöтöн дöнья Аҥар эяреб бетя, дигянняр.

20 Табыныр öчöн бяйрямгя килгян кешелярнен кайсылары Еллиннаръ икян.

21 Алар Галилеядагы Виѳсаиданын Филиппъ катына килеб, аннан сораганнар: эй кадерле! безнен Іисусны кюрясебез киля, дигянняр.

22 Филиппъ барыб, мыны Андрейгя айткян; аннары Андрей белян Филиппъ мыны Іисуска айткянняр.

23 Іисусъ аларга жауабка айткян: Ӓдям Улынын данналыр сагате житте.

24 Чын, чын сезгя айтямен: бодай бӧртӧгӧ жиргя тӧшӧб ӱлмяся, ӱзе гня тора; ӓгяр дя ӱлся, кюб жимеш китеря.

25 Жанын сӧйгян кеше- аны жугалтыр, ӓммя бу дӧньядя жанын жаратмас булган кеше- аны мянге тормошка саклар.

26 Миңа кызмят итеӱче Миңа эярсен; Мин кайда, кызмятчем дя шунда булыр. Миңа кызмят итеӱчене Минем Атам кадерляр.

27 Казер Минем жаным кӧяляня башлады; ней айтейем Мин? эй Ӓтей, бу сагаттян Мине коткар! Алайда Мин шушы сагат ӧчӧн килдем.

Зач.

28 Эй Ӓтей! исемеңне даннат, дигян. Шул чагында кюктян ауаз килгян: даннаттым, тагы да даннатырмын диб.

29 Шунда тороб, мыны эшеткян калык айткян: кюк кюкеряӱдер бу диб, кайсылары айткянняр: Аңар пяриштя дяшкяндер, дигянняр.

30 Іисусъ мыңар карышы айткян: бу ауаз Минем ӧчӧн булмады, ӓммя калык ӧчӧн булды.

31 Казер бу дӧньягя хокӧм булды; казер бу дӧньянен князе тышка кыуылыб чыгарылыр.

32 Мин жирдян кютярелгяч, барын да Ӱземя тартыб алырмын, дигян.

33 Былай диб айтеб, Ул ничек ӱлясесен кюрсяткян.

34 Калык Аңар айткян: без законнан эшеттек, Христосъ гумергя тора диб; Син суң Ӓдям Улы кютярелергя тейеш диб ничек айтясен? Ул Ӓдям Улы кем суң? дигянняр.

35 Шунда Іисусъ айткян: сезнен арада жакты тагы аз гна багыт торор; жакты бар чагында жӧрӧгӧз, сезне карангы каблаб бетермясен; карангыда жӧрӧӱче кайда барганын белмей, дигян.

Зач. 43.

36 Жакты оланнары булыр ӧчӧн, жакты сезнен белян торган чагында, жактыга ышаныгыз, дигян. Мыны айткяч, Іисусъ читкя китеб, алардан жяшеренгян.

37 Іисусъ алар алдында шул катле кодрятляр кылса да алар Аңар ышанмаганнар.

38 Шулай итеб, Исаія пагамбярнен: эй Ходай, бездян эшеткянгя кем ышанды? Ходайнын кыуаты кемгя кюренде? дигян сюзе жиреня килгян.

39 Аларнын ышана алмаганнары, Исаія пагамбяр тагы айткянчя, шушы сяятлей булган:

40 Аларнын кюзляре кюрмяс булган, кюнелляре таш кюк катыланган, кюзляре белян кюрмяс ӧчӧн, кюнелляре белян аннамас ӧчӧн, (Минга) кайтмас ӧчӧн, ӓммя Мин аларны тӧзятер эйем, дигянчя.

41 Исаія мыны, Ходайнын олологан кюргяч, Анын турысында сӧйлягян чагында, айткян.

42 Алайда башлыкларнын да кюбесе Іисуска ышанганнар, тик синагогадан айырмасыннар диб, фарисейляр сяятлей, ышанганнарын билгертмягянняр;

43 Алар Алладан данналыудан бигеряк кешедян данналыуны артык сӧйгянняр шул.

44 Іисусъ тагы кычкырыб айткян: Минга ышаныучы Мине Жибяреӳчегя ышана, ӓммя Минга тӧгӧл.

45 Мине кюреӳче дя Мине Жибяреӳчене кюря.

46 Мин жакты, Минга ышаныучыларнын берсе дя карангыда калмасын диб, Мин дӧньягя килдем.

47 Кем дя кем Минем сюзляремне эшетеб тя ышанмаса, Мин аны айыбламыйым; Мин дӧньяне айыбларга диб килмядем, ӓммя дӧньяне коткарырга диб килдем шул.

48 Мине кабыл алмаганнын, сюземне тыннамаганнын айыблаучысы бар: Мин айткян сюз, аны калдык кӧннӧ айыблар,

49 Мин Ӳземнян сӧйлямядем шул; ӓммя Мине жибяргян Атам Ӳзе Минга ней айтергя, ней сӧйляргя бойорок бирде.

50 Мин белямен: Анын бойорого мянге тормош. Шулай итеб, Мин ней гня сӧйлясям дя, Минга Ата айткянчя сӧйлӧйӧм, дигян.

13-нчӧ бюлем.

Зач. 44.

1 Пасха бяйряме алдыннан, Іисусъ бу дӧньядян Атасына кючяр сагате житкянне белеб, дӧньядяге Ӳзенекелярне сӧйӧб, аларны ӳлярлек булыб сӧйгянен кюрсяткян.

2 Кич ашы ашаган чагында, Симонъ улы Іуда Искаріотнын кюнеленя Іисусны тотоб бирергя шайтан уй салгач,

3 Іисусъ барын да Ата Анын кулына табшырганны, аннары Ӳзенен Алла жаныннан чыгыб, тагы Алла жанына китясесен белеб,

4 Аштан торган да ӧст кейемен салыб, сӧлгӧ алыб, биленя чолгаган.

5 Аннары комганга сыу салыб, ӧйрянеӳчеляренен аякларын жыуыб, Ӳзеня чолгаган сӧлгӧ белян сӧртя башлаган.

6 Симонъ дигян Петрга килеб житкяч, Петръ Анар айткян: эй Ходай, минем аякларымны Син жыуарсын меней? дигян.

7 Іисусъ анар жауаб биреб айткян: Мин ней кылганны син ӓле белмейсен, ӓммя сунгыннан аннарсын, дигян.

8 Петръ Анар айткян: гумергя мин Сина аякларымны жыудырмам, дигян. Іисусъ анар жауаб биргян: ӓгяр Мин сине жыумасам, Минем белян ӧлӧшӧн булмас, дигян.

9 Симонъ Петръ Анар айткян: эй Ходай, айса аякларымны гна тӧгӧл, кулларымны да, башымны да (жыу), дигян.

10 Іисусъ анар айткян: жыуылганнын аякларын гна жыуарга киряк, ул бӧтӧнняй таза шул; сез дя таза, тик барыгыз да тӧгӧл, дигян.

11 Ул Ӱзен тотоб биреӱчене белгян, шунар кюря айткян: сез таза, тик барыгыз да тӧгӧл, дигян.

Зач. 45.

12 Аннары аларнын аякларын жыугач, ӧст кейемен кейеб, тагы утыргач, аларга айткян: Мин сезгя ней кылганны белясез ме?

13 Сез Мине Ӧйрятеӱче диб, Ходай диб айтясез, алай диб айтеӱегез дӧрӧс, Мин шул шу.

14 Айса Мин Ӧйрятеӱче кӧйӧ, Ходай кӧйӧ, сезнен аякларыгызны жыугач, сез дя бер берегезнен аякларын жыуарга тейеш;

15 Мин сезгя кючергеч бирдем шул, Мин сезгя кылганны, сез дя кылсын диб.

16 Чын, чын сезгя айтямен: кол ӱз эясеннян оло тӧгӧл, жибярелгян дя аны жибяреӱчедян оло тӧгӧл.

17 Мыны белсягез, мыны кылсагыз, сез бахетле.

18 Минем айтеӱем барыгыз турысында да тӧгӧл, Мин сайлаганнарымны белямен; ӓммя жазылганнын: Минем белян икмяк ашаучы Мина ӱкчясен кютярде дигяне буласы.

19 Ул булмастан элеке, казерюк Мин сезгя аны айтямен, ул булгач, Мин Христосъ икянгя сез ышансын диб.

20 Чын, чын сезгя айтямен: Мин жибяргянне кабыл алыучы Мине кабыл ала; ӓммя Мине кабыл алыучы Мине Жибяреӱчене кабыл ала, дигян.

21 Мыны айткяч, Іисуснын жан тынычы беткян, шунда таныклаб айткян: чын, чын сезгя айтямен: сезнен арадан беряӱ Мине тотоб бирер, дигян.

22 Шул чакта ӧйрянеӱчеляре, Ул кем турысында айткянне белмейчен, бер берсеня таба карашканнар.

23 Ӧйрянеӱчеляре арасыннан берсе, Іисусъ сӧя торганы, Іисуснын кюкерягеня сыйыныб утырган.

24 Симонъ Петръ анар бу кемне айтя икян диб сорарга билге кылган.

25 Іисуснын кюкерягеня сыйыныб утырыучы Анар айткян: эй Ходай, ул кем? дигян.

26 Іисусъ жауаб биргян: Мин кемгя бер сынык икмяк маныб бирем, шул ўзе дигян дя сыныкны маныб, Симонъ улы Искаріоть Іудага биргян.

27 Шул сыныктан суӊ Іудага шайтан кергян. Шунда Іисусъ аӊар айткян: кыла торганыӊны тизеряк кыл, дигян.

28 Ул мыны аӊар нейгя айткянне утырыучыларнын берсе дя аӊнамаган.

29 Тартма Іудада булганга кюря, кайсылары Іисусъ аӊар: безгя бяйрямгя киряклене сатыб алырга айтя диб, жя сораныучыларга бер-бер нястя бирергя айтя диб уйлаганнар.

30 Сыныкны алгач та Іуда чыгыб киткян; ул чакта тӧн икян.

31 Ул чыккач, Іисусъ айткян:

Зач 46.

32 Казер Äдям Улы данналды, Анда Алла да данналды. Анда Алла данналгач, инде Алла да Ўзендя Аны данналдырыр, Аны тизюк данналдырыр.

33 Эй балалар! Миӊа инде сезнен белян торорга кюб калмады; Мине эзлярсез, тик Мин Іудейляргя ничек: Мин барасы тӧшкя сез бара алмассыз диб айттем, сезгя дя инде шулай айтямен.

34 Сезгя жаӊа бойорок бирямен, сез бер берегезне сӧйсягез эйе. Мин сезне сӧйгян кюк, сез дя шулай бер берегезне сӧйсягез эйе.

35 Äгяр сезнен арагызда бер берегезне сӧйӧўлек булса, сез Минем ӧйрянеўчелярем икянне барысы да шуннан белерляр, дигян.

36 Симонъ Петръ Аӊар айткян: эй Ходай, Син кая барасын? дигян. Іисусъ аӊар жауаб биргян: Мин барасы тӧшкя син äле Минем артымнан бара алмассын, äммя суӊыннан артымнан барырсын, дигян.

37 Петръ Аӊар айткян: эй Ходай, казер мин Синеӊ артыӊнан ничек бара алмам икян? мин Синеӊ ӧчӧн жанымны бирермен, дигян.

38 Іисусъ аӊар жауаб биргян: Минем ӧчӧн жаныӊны бирерсен ме? чын, чын сиӊа айтямен: äтяч кычкыргынчы, син Мине ӧч табкыр таӊарсын, дигян.

## 14-нче бюлем.

Зач. 47.

1 Кюӊелегез шиклянмясен; Аллага ышаныгыз, Миӊа да ышаныгыз.

2 Атамнын ӧйӧндя торор урын кюб, алай булмаса, Мин сезгя айтер эйем: Мин сезнен ӧчӧн урын äзерляргя барам диб.

3 Барыб, сезгя урын äзерлягяч тагы килермен дя сезне Ўз катыма алырмын, сез дя Мин торган тӧштя булсын диб.

4 Мин барасы тӧшнӧ сез белясез, жулын да белясез, дигян.

5 Өома Аӈар айткян: эй Ходай! кая барасыӈны белмейбез, жулын да ничек беля алырбыз? дигян.

6 Іисусъ аӈар айткян: Мин Ўзем жул, чынных, терелек; Минем арткылы килмяся, Атага беряў дя киля алмый.

7 Сез Мине белсягез, Атамны да белер эйегез. Инде мыннан ары сез Аны белясез дя, кюрдегез дя, дигян.

8 Филиппъ Аӈар айткян: эй Ходай! безгя Атаны кюрсят, безгя шул житяр, дигян.

9 Іисусъ аӈар айткян: сезнен белян шул катле багыт торам, син Мине белмейсен ме Филиппъ?

10 Мине кюргян Атаны кюрде; син суӈ ничек безгя Атаны кюрсят диб айтясен? Мин Атада, Ата Миндя икянгя син ӓлля ышанмыйсын мы? дигян.

Зач. 48.

Мин сезгя айтя торган сюзлярне Ўземнян айтмеймен; Миндя тора торган Ата эшлярне Ўзе кыла.

11 Мин Атада, Ата Миндя дигянемя Миӈа ышаныгыз; алай дигянемя ышанмасагыз, шул эшляр буйынча Миӈа ышаныгыз.

12 Чын,чын сезгя айтямен: Мин кыла торган эшлярне Миӈа ышаныучы да кылар, алардан да артык кылар; Мин Атама барамын шул.

13 Минем исемемя Атадан ней сорасагыз да Мин аны булдырырмын; Ата Улында данналсын диб.

14 Сез Минем исемемя ней сорасагыз да Мин булдырырмын.

15 Мине сӧйсягез, бойорокларымны кылыгыз,

16 Мин дя Атага инялермен, Ул сезгя, сезнен белян гумергя торорга, бютян Тынычландырыучы бирер.

17 Чынных Тынын (бирер), дӧнья Аны кабыл ала алмас, Аны кюрмей дя, белмей дя шул, ӓммя сез Аны белясез, Ул сезнен белян тора шул, сездя булыр да.

18 Сезне ўгей калдырмам: сезгя килермен;

19 Инде кюб калмады, дӧнья Мине кюрмяс, ӓммя сез Мине кюрерсез; Мин тере торам шул, сез дя тере торорсоз.

20 Мин Атамда, сез Миндя, Мин сездя икянне шул кӧннӧ белерсез.

21 Минем бойорокларымны тотоб, аларны кылыб торган кеше Мине сӧя; Мине сӧйӧб торган кешене Атам да сӧяр, аны Мин дя сӧярмен, аӈар Ўземне кюрсятермен, дигян.

22 Искаріотъ Іуда тӧгӧл, ӓммя бютян Іуда Аӈар айткян: эй Ходай, Ўзеӈне дӧньягя кюрсятмейче, безгя кюрсятясе килеўеӈ нейлектян? дигян.

23 Іисусъ аңар жауаб биреб әйткян: кем дя кем Мине сөйся, ул Минем сюземне кылар; аны Атам да сөяр, Без аңар килербез, анда торор урын жасарбыз.

24 Мине сөймөй торган кеше сюзляремне кылмый; сез эшетя торган сюз Минеке төгөл, Мине жибяреўче Атаныкы.

25 Мин мыны сезгя, сезнен белян торган чагымда, әйттем.

26 Ата Минем исемемя жибярясе Тынычландырыучы, Святый Тын, сезне әр-нейгя өйрятер, Мин сезгя сөйлягянне барын да исегезгя төшөрөр.

27 Сезгя тынычлык калдырамын, сезгя Ўз тынычлыгымны бирямен; сезгя тынычлыкны биреўем, дөнья биргянчя төгөл, дигян.

Зач. 49.

28 Кюңелегез шиклянмясен, курыкмасын да. Сезнен каттан китямен, аннары сезгя тагы килермен дигянемне сез эшеттегез; сез Мине сөйсягез, Мин Атага барамын дигянемя сөйөнөрсөз, Атам Миннян олорак шул.

29 Мына шушы әйткянем булырдан элеке Мин сезгя әйттем, ул булгачтын сез ышансын диб.

30 Инде Миңа сезнен белян сөйляшергя кюб калмады, инде бу дөньянен князе киля, анын Миндя ич нейе жук.

31 Әммя Мин Атаны сөйгянне, Ата Миңа кушканча кылганны дөнья белсен: торогоз, мыннан китейек, дигян.

15-нче бюлем.

Зач. 50.

1 Мин жөзөм агачынын чыны, Атам бакчачы.

2 Жимеш китермей торган Миндяге әр-бер ботакны Ул кисеб ала, әммя жимеш китеря торган әр-бер ботакны әрчей, жимешне кюберяк китерсен диб.

3 Сезгя сөйлягян сюзем арткылы сез инде әрчелеўле.

4 Миндя торогоз, Мин дя сездя (торормын). Жөзөм агачында булмаган ботак ўз алдына ўзе жимеш китеря алмаган кюк, сез дя Миндя булмасагыз, шулай (жимеш китеря алмассыз).

5 Мин жөзөм агачы, әммя сез ботаклар; кем дя кем Миндя торса, Мин дя анда торсам, ул кюб жимеш китеря, Миннян башка бер эш тя кыла алмассыз шул.

6 Кем дя кем Миндя тормаса, тышка, ботак кюк ташланылыр, короб бетяр, аннары шундый ботакларны жыйыб, утка ташлыйлар,шунда алар жаныб бетяляр.

7 Миндя торсагыз, Минем сюзлярем сездя торса, телягянегезне сорагыз, сезгя булыр.

8 Кюб жимеш китерсягез, ӧйрянеӳчелярем булсагыз, шунын белян Атам данналыр, дигян.

Зач. 51.

9 Мине Ата сӧйгян кюк, Мин дя сезне сӧйдӧм;сӧйӧӳлегемдя торогоз.

10 Ӓгяр бойорокларымны тотсагыз, сӧйӧӳлегемдя торорсоз; Мин дя Атамнын бойорокларын тотканыма кюря, Атам сӧйӧӳлегендя торамын.

11 Мыны Мин сезгя, Минем сӧйӧнӧчӧм сездя булсын диб, сезнен сӧйӧнӧчӧгӧз тулы булсын диб айттем.

12 Минем бойорогом шушы: Мин сезне сӧйгян кюк, сез дя шулай бер берегезне сӧйӧгӧз.

13 Кем дя кем ӳз дуслары ӧчӧн ӳз жанын бирся, шул сӧйӧӳлектян артык сӧйӧӳлек жук.

14 Мин сезгя кушканны кылсагыз, сез Минем дусларым.

15 Мин инде сезне коллар диб атамыйым, эясе ней кылганны кол белмей шул; ӓммя Атамнан эшеткянне барын да сезгя айткянемя кюря, Мин сезне дусларым диб атадым.

16 Мине сез сайламадыгыз, ӓммя сезне Мин сайлаб куйдым, барыгыз, жимеш булдырыгыз, жимешегез уңыб торсон диб; сез Минем исемемя Атадан ней гня сорасагыз да Ул сезгя бирсен эйе, дигян.

Зач. 52.

17 Сезгя кушамын: бер берегезне сӧйӧгӧз.

18 Ӓгяр дӧнья сезне кюрялмаса, белегез, ул Мине сездян элгяреряк кюрялмады.

19 Сез дӧньядян булсагыз, дӧнья ӳзенекен сӧяр эйе; ӓммя сез дӧньядян булмаганга кюря, Мин сезне дӧньядян сайлаганга кюря, дӧнья сезне кюрялмый.

20 Сезгя кол эясеннян оло тӧгӧл дигян сюземне исегездя тотогоз; Мине кыугач, сезне дя кыуарлар; Минем сюземне кылган булсалар, сезнекен дя кыларлар;

21 Ӓммя шунын барысын да сезгя Минем исемем ӧчӧн кыларлар, Мине Жибяреӳчене белмейляр шул.

22 Ӓгяр Мин килеб, аларга сӧйлямягян булсам, аларга жазык булмас ыйы, ӓммя казер жазыклары ӧчӧн айыбсыз булыр халляре жук.

23 Мине кюрялмаган кеше Атамны кюрялмый;

24 Ӓгяр Мин алар арасында ич-бер кеше кыла алмаслык эшляр кылмаган булсам, аларга жазык булмас ыйы, ӓммя казер алар кюрделяр, алайда Мине дя, Атамны да кюрялмас булдылар;

25 Тик аларнын законында: мине бушка кюрялмадылар диб жазылган сюз жиреня килсен.

26 Мин сезгя Атадан жибярясе Тынычландырыучы,чынннык Тыны, Атадан чыга торган Тын килгяч, Ул Мине таныклар;

27 Сез дя шулай таныкларсыз, сез элгяртенюк Минем белян эйегез шул, дигян.

16-нчы бюлем.

Зач. 53.

1 Мыны Мин сезгя, сез шиклянмясен диб ййттем:

2 Сезне синагогалардан айырырлар. Шундый багыт житяр, äр-кем сезне ӳтереӳче ӳтергяне белян Аллага жараулы эш кыламын диб уйлар;

3 Атаны да, Мине дя белмягяннекляреннян шулай кыларлар.

4 Äммя Мин мыны сезгя äйттем, ул багыт житкяч, Мин ул турда сезгя сöйлягянне искя тöшöрсöнняр диб; Ӳзем сезнен белян булганга кюря, башта Мин сезгя аны äйтмягян эйем.

5 Казер инде Жибяреӳчемя китямен; алайда кая барасын диб Миннян берегез дя сорамый.

6 Тик Мин сезгя мыны äйткяннян кюнелегез кöйöк белян тулды.

7 Äммя Мин сезгя чынны äйтямен: Минем барыуым сезнен öчöн жакшырак, Мин бармасам, сезгя Тынычландырыучы килмяс шул; äгяр барсам, Аны сезгя жибярермен.

8 Ул килеб, дöньягя жазыкны, дöрöслöкнö, хокöмнö дя кюрсятер:

9 Жазык дигяне Минга ышанмаганнык;

10 Дöрöслöк дигяне Мин Атама китеӳ; шунныктан сез Мине кюрмяссез;

11 Хокöм дигяне бу дöньянен князе айыбланыу.

12 Тагы сезгя кюбне äйтясем бар, тик сез казер сыйыштыра алмассыз;

13 Äммя чыннык Тыны килгяч, Ул сезне äр-бер чынныкка öйрятер: Ул Ӳзеннян сöйлямяс, äммя эшеткянен сöйляр, буласыны сезгя белдерер;

14 Ул Мине данналдырыр, Минекеннян алыб, сезгя белдерер шул, дигян.

Зач. 54.

15 Атамнын нейе бар, барыда Минеке, шунар кюря Минекеннян алыб, сезгя белдерер диб äйттем дя.

16 Бер аздан Мине кюрмяссез, аннары тагы бер аздан Мине кюрересез, Мин Атага барамын шул, дигян.

17 Шунда Анын öйрянеӳчеляренен кайсылары бер берсеня äйткянняр: бу ней äйтя Ул безгя: бер аздан Мине кюрмяссез, аннары тагы бер аздан Мине кюрерсез дей, аннары Атага барамын? дей.

18 Алар шулай бер аздан диб нейне айтя Ул? нейне айткянен белмейбез, дигянняр.

19 Іисусъ Ӱзеннян аларнын сорасылары килгянен белеб, аларга айткян: Мин бер аздан Мине кюрмяссез, аннары тагы бер аздан Мине кюрерсез диб айткянемне бер берегездян сорашасыз мы?

20 Чын, чын сезгя айтямен: сез сулкылдаб жыларсыз, äммя дӧнья кыуаныр; сез кайгылы булырсыз, тик сезнен кайгыгыз сӧйӧнӧчкя алмашыр.

21 Катын кеше (бала) тыудырыр чакта кайгырыб тора, анын сагате житкян шул; äммя бала тыудыргач, дӧньягя тыуган кешегя сӧйӧнӧӱеннян кайгысын онота.

22 Сез дя казер шулай кайгылы; тик Мин сезне тагы кюрермен, сезнен кюӈелегез сӧйӧнӧр, сезнен сӧйӧнӧчӧгӧзне сездян беряӳ дя ала алмас.

23 Шул кӧннӧ сез Миннян бер турда да сорамассыз, дигян.

Зач. 55.

Чын, чын сезгя айтямен: Атадан Минем исемемя ней сорасагыз да, сезгя бирер.

24 Мыӈар чаклы сез Минем исемемя бер нястя дя сорамадыгыз; сорагыз, алырсыз, сӧйӧнӧчӧгӧз тулы булсын.

25 Мыӈар чаклы Мин сезгя мясялляр китереб сӧйлядем, инде багыт житя, ул чакта Мин сезгя мясялляр китереб сӧйлямям, äммя Ата турысында сезгя туры белдерем.

26 Шул кӧннӧ сез Минем исемемя сорарсыз; Атадан сезнен турыда телярмен диб айтмейем,

27 Сез Мине сӧйгянгя кюря, Атадан чыкканыма ышанганыгызга кюря, Ата Ӳзе сезне сӧядер шул.

28 Мин Атадан чыгыб, дӧньягя килдем; тагы дӧньяне калдырыб, Атага китямен, дигян.

29 Ӧйрянеӳчеляре Аӈар айткянняр: мына Син инде туры сӧйлӧйсӧн, бер-тӧрлӧ мясял дя сӧйлямейсен;

30 Син барын да белгянне дя, Синнян беряӳ-беряӳ сорауны киряксенмягяненгне дя инде без кюрябез; шуӈар кюря Син Алладан чыкканга ышанабыз.

31 Іисусъ аларга айткян: инде ышанасыз?

32 Мына сагат житя, инде житте дя, сез жак жакка таралышырсыз, Мине жангыз калдырырсыз; äммя Мин жангыз тӧгӧл, Ата Минем белян шул.

33 Мин мыны сезгя, Миндя тынычлансыннар диб айттем; дӧньядя кайгырырсыз, алай да нык торогоз: Мин дӧньяне жиӈдем, дигян.

17-нче бюлем.

Зач. 56.

1 Іисусъ бу сюзлярне áйткяч, кюзлярен кюккя таба кютяреб áйткян: эй Атей! сагат житте: Улыҥны данналдыр, Улыҥ да Сине данналдырсын;

2 Син Анын кулына äр-бер тянне бирдеҥ, Син Аҥар биргяннен барчасына Ул мянге терелек бирсен диб;

3 Äммя мянге терелек бу: Син бер гня чын Алланы, тагы Син жибяргян Іисусъ Христосны белеўлек.

4 Мин Сине жирдя данналдырдым, Син Миҥа кыларга табшырган эшне кылдым.

5 Син Мине казер данналдыр, эй Атей, Синеҥ Ўзеҥдяге дан белян, дöнья булырдан элеке Синдяге даным белян (данналдыр).

6 Син Миҥа дöньдян биргян кешеляргя Мин Синеҥ исемеҥне белдерттем; алар Синеке эйе, Син аларны Миҥа бирдеҥ, алар сюзеҥне тоттолар.

7 Миҥа биргянеҥ барысы да Синнян икянне алар инде аҥнадылар,

8 Син Миҥа биргян сюзлярне Мин аларга áйтеб бирдем шул; алар кабыл алдылар, Мин Синнян чыкканны чыннаб аҥнадылар, Мине Син жибяргянгя ышандылар.

9 Мин алар турысында инялямен, бöтöн дöнья турысында тöгöл, тик шушы Син Миҥа биргянняр турысында гна инялямен, алар Синеке шул.

10 Минеке барда Синеке, Синеке барда Минеке; Мин аларда данналдым.

11 Мин инде дöньядя тöгöл, äммя алар äле дöньядя; Мин Сиҥа барамын. Эй арыу Атей! шушы Син Миҥа биргяннярне Ўз исемеҥ какына сакла, ничек Без бер, алар да шулай бер булсыннар ыйы.

12 Мин алар белян дöньядя чагымда, аларны Синеҥ исемеҥ какына саклаб тордом; шушы Син Миҥа биргяннярне Мин сакладым; алар арасыннан жугалыу улыннан башкасы, беряў дя жугалмады; Жазыудагы шулай жиреня килер.

13 Äммя Мин инде Сиҥа барамын; мыны дöньядя чагымда áйтямен, аларда Минем сöйöнöчöм тулы булсын диб.

14 Мин аларга Синеҥ сюзеҥне áйтеб бирдем; дöнья аларны кюрялмас булды, Мин ничек дöньядян тöгöл, шулай алар да дöньядян тöгöл шул.

15 Аларны дöньядян ал диб инялмеймен, тик аларны жаманнан сакла диб (инялямен).

16 Мин ничек дöньядян тöгöл, шулай алар да дöньядян тöгöл.

17 Ўз чының белян аларны арыуландыр, Синең сюзең чыннык, дигян.

Зач. 57.

18 Син Мине дёньягя жибяргян кюк, Мин дя аларны дёньягя жибярдем;

19 Алар öчöн Мин Ўземне Ўзем арыуландырам алар да чыннык белян арыулансыннар диб.

20 Алар турысында гна инялмеймен, äммя аларнын сюзе буйынча, Миңа ышаныучылар турысында да инялямен:

21 Барда бер булсыннар ыйы, эй Äтёй, Син Миндя кюк, Мин Синдя кюк, алар да Бездя бер булсыннар ыйы; Мине Син жибяргянгя дёнья ышансын ыйы.

22 Син Миңа биргян данны Мин аларга бирдем: Без бер кюк, алар да бер булсыннар ыйы.

23 Мин аларда, Син Миндя; алар гел бер булыб житсенняр; Син Мине жибяргянне дя, Син Мине сöйгян кюк, аларны да сöйгяненне дёнья белсен эйе.

24 Эй Äтей! Син Миңа биргянняр Мин булган тöштя Минем белян бергя булсыннар ыйы диб телеймен, Син Миңа биргян данымны алар да кюрсенняр эйе, дёнья булдырыудан элеке Син Мине сöйдöң шул.

25 Эй гадел Äтей! дёнья Сине белмяде, äммя Мин Сине белдем, былар да Мине Син жибяргянне белделяр.

26 Мин аларга Синең исемеңне белдердем, тагы да белдерем, Син Мине сöйгян сöйöўлек аларда булсын ыйы. Мин дя аларда (булсам ыйы), дигян.

18-нче бюлем.

Зач. 58.

1 Мыны äйткяч, Іисусъ öйрянеўчеляре белян Кедронъ чишмясенен ары жагына чыккан; анда агач бакчасы бар икян; шунда Ул Ўзе дя, öйрянеўчеляре дя кергянняр.

2 Бу урынны Аны тотоб биреўче Іуда да беля икян, Іисусь öйрянеўчелярен жыйыб, шунда онгай баргалый икян шул.

3 Шуннызктан Іуда архіерейлярдян, фарисейлярдян бер ауык салдатлар, кызмятчеляр алыб, панарлар, жактырткычлар, кораллар алыб, шунда килгян.

4 Äммя Іисусъ, Ўзеня ней буласыны барын да белеб, аларга чыгыб äйткян: кемне эзлейсез? дигян.

5 Аңар жауаб биргянняр: Назорей Іисусны, дигянняр. Іисусь аларга äйткян: ул Мин, дигян. Тотоб биреўче Іуда да алар белян бергя тора икян.

6 Іисусъ аларга: ул Мин диб айткяч, алар кире чигеб, жиргя жыгылганнар.

7 (Іисусъ) алардан тагы сораган: кемне эзлейсез? дигян.

8 Алар: Назорей Іисусны, дигянняр. Іисусъ жауаб биргян: ул Мин диб Мин сезгя айттем. Ӓгяр Мине эзлясягез, инде быларга теймягез, алар китсенняр, дигян.

9 Шулай итеб, Ул айткян сюз: Син Миңа биргяннярнен берсен дя Мин жугалтмадым дигяне жиреня килясе булган.

10 Симонъ Петръ жанындагы кылычын сыуырыб алыб, архіерей колонон уң колагын чабыб ӧзгян; кол Малхъ исемне икян.

11 Ӓммя Іисусъ Петрга айткян: кылычыңны кынысына тык; Миңа Ата биргян сауытны Мин эчмей калырым меней? дигян.

12 Шул чакта салдатлар, мең кеше башлыгы, Іудей кызмятчеляре Іисусны алыб, Аны бяйлягянняр дя Аны элеке Аннага алыб килгянняр.

13 Анна Каіафа катынынын атасы икян,ӓммя Каіафа шул жылны архіерей булыб тора икян.

14 Калык ӧчӧн бер гня кешенен ӱлгяне жакшырак диб Іудейляргя киңяш биргян Каіафа шушы булган.

15 Іисусъ артыннан Симонъ Петръ белян тагы бер ӧйрянеӱче барганнар; бу ӧйрянеӱче архіерейгя белеш икян, ул Іисусъ белян бергя архіерейнен ишек алдына кергян.

16 Ӓммя Петръ кабка артында тышта торган. Аннары архіерейгя белеш икенче ӧйрянеӱче чыккан да кабка саклаучы катынга айтеб, Петрны керткян.

17 Шунда кабка саклаучы кызмятче катын Петрга айткян: син дя бу кешенен ӧйрянеӱчеляренен берсе тӧгӧл ме? дигян. Ул: жук дигян.

18 Сыуык булганга кюря, коллар белян кызмятчеляр ут жагыб, жылыныб торганнар; Петръ да алар белян жылыныб торган.

19 Архіерей Іисустан Анын ӧйрянеӱчеляре турысында, ӧйрятеӱе турысында сораган.

20 Іисусъ аңар жауаб биргян: Мин дӧньягя айырмачык сӧйлядем, Мин жалан синагогада, чиркяӱдя, Іудейляр онгай жыйылыша торган урыннарда ӧйряттем, жяшерен бер нястя дя сӧйлямядем;

21 Ник Миннян соройсоң? эшеткян кешеляргя ней айткянемне ӱзляреннян сора, мына алар Мин ней айткянне беляляр, дигян.

22 Ул мыны айткяч, жакын тора торган кызмятчелярнен берсе, Іисуснын жаңагына сугыб, айткян: архіерейгя Син шулай жауаб бирясен ме? дигян.

23 Іисусъ аӊар жауаб биргян: Мин жаман айткян булсам, жаманныгын кюрсят, ӓгяр дя жакшы (айткян) булсам, Миӊа ник сугасын? дигян.

24 Шуннан суӊ Анна Аны бяйлягян кӧйӧ Каіафа архіерейгя жибяргян.

25 Симонъ Петръ жылыныб торган. Шунда аӊар айткянняр: син дя Анын ӧйрянеўчеляренен берсе тӧгӧл ме? дигянняр. Ул, жук диб, танган.

26 Архіерей кызмятчеляренен берсе, Петръ колагын чабыб ӧзгян кешенен карендяше айткян: бакчада мин сине Анын жанында кюрдем тӧгӧл ме? дигян.

27 Петръ тагы танган, шул сяттюк ӓтяч кычкырган.

Зач. 59.

28 (Іудейляр) Каіафадан Іисусны преторія дигян урынга алыб барганнар. Бу иртя белян булган. Алар шакшыланмыйык диб, пасха ашарга жараулы кӧйӧ торойок диб, преторія эченя кермягянняр.

29 Пилатъ алар катына чыгыб айткян: бу Кешене ней белян айыблыйсыз? дигян.

30 Алар аӊар жауаб биреб айткянняр: Ул усал булмаса, без Аны сиӊа тотоб бирмяс эйек, дигянняр.

31 Пилатъ аларга айткян: Аны ўзегез алыгыз, Аӊар ўз законыгызча хокӧм итегез, дигян. Іудейляр аӊар айткянняр: безгя беряўне дя ўтерергя ирек жук, дигянняр.

32 Шулай итеб, Іисусъ Ўзенен ничек ўлем белян ўлясесен аӊнатыб айткян сюзе жиреня килергя тейеш булган.

33 Аннары Пилатъ тагы преторіяга кереб, Іисусны чакыртыб, Аӊар айткян. Син Іудей Падшасы мы? дигян.

34 Іисусъ аӊар жауаб биргян: син мыны ўзеӊнян айтясеӊ ме, ӓлля сиӊа Минем турыда бютянняр айттеляр ме? дигян.

35 Пилатъ жауаб биргян: мин Іудей меней? Сине миӊа Ўз калкыӊ белян архіерейляр тотоб бирделяр; Син ней кылдыӊ? дигян.

36 Іисусъ айткян: Минем падшалыгым бу дӧньядян тӧгӧл; падшалыгым бу дӧньядян булса, кызмятчелярем Минем ӧчӧн, Мине іудейляр кулына бирдермяскя тырышырлар ыйы; ӓммя казер Минем падшалыгым мыннан тӧгӧл, дигян.

37 Пилатъ Аӊар айткян: айса Син Падша? дигян. Іисусъ жауаб биргян: Падша икянемне син (дӧрӧс) айтясен. Мин чынныкны таныкларга диб дӧньягя тыудым да, килдем дя; чыннан булган ӓр-кем ауазымны тыӊный, дигян.

38 Пилатъ Аҥар айткян: чыннык ней? дигян; шулай дигяч тя тагы іудейляр катына чыгыб, аларга айткян: мин Анын бер айыбын да табмыймын.

39 Сезнен жолагызча Пасха бяйряменя беряўне мин сезгя иркенгя жибярергя тейеш; мин сезгя Іудей Падшасын иркенгя жибярейем ме, телейсез ме? дигян.

40 Шунда барысы да тагы кычкыра башлаганнар: Аны тӧгӧл, Варавваны жибяр, дигянняр. Варавва талаучы икян.

19-нчы бюлем.

1 Шуннан суҥ Пилатъ Іисусны алыб, Аны кыйнарга кушкан.

2 Салдатлар чянечкеле агач чыбыкларыннан ўрмя ўреб, Анын башына кейгезгянняр, ӧстӧня кызыл кейем кейгезгянняр дя

3 Эй Іудей Падшасы, сӧйӧн! диб айтеб, Анын жаҥакларына сукканнар.

4 Пилатъ тагы чыгыб,аларга айткян: мына мин Аны сезгя чыгарамын, Анын бер айыбын да табмаганымны сез белсен диб, дигян.

5 Шунда Іисусъ чянечкеле ўрмя кейгян кӧйӧ, кызыл кейем кейгян кӧйӧ чыккан. Пилатъ калыкка айткян: мына ул Кеше! дигян.

6 Архіерейляр белян кызмятчеляр Іисусны кюргяч, былай диб кычкырганнар:

Зач.60.

Кадаклат Аны,кадаклат! дигянняр. Пилатъ аларга айткян: ўзегез Аны алыгыз да кадаклагыз, мин Анын айыбын табмыймын, дигян.

7 Іудейляр аҥар жауаб биргянняр: безнен законъ бар, безнен законъ буйынча, Ул ўтерелергя тейеш, Ул Ўзен Ўзе Алла Улы итте шул, дигянняр.

8 Пилатъ, бу сюзне эшетеб, бигеряк тя курыккан.

9 Тагы преторіяга кереб, Іисуска айткян: Син кайдан? дигян; ӓммя Іисусъ аҥар жауаб бирмягян.

10 Пилатъ Аҥар айткян: миҥа да жауаб бирмейсен меней? ӓлля минем Сине кадаклатырга да, (иркенгя) жибярергя дя кыуатым барны белмейсен ме? дигян.

11 Іисусъ жауаб биргян: синҥа жугартын бирелмяся, Миҥа синеҥ ич тя кыуатыҥ булмас ыйы, дигян; шуҥар кюря Мине синҥа тотоб биреўчегя жазык кюберяк булыр, дигян.

12 Шуннан ары Пилатъ Іисусны (иркенгя) жибярергя тырышкан. Ӓммя Іудейляр кычкырганнар: Аны жибярсяҥ, син кесаргя дус тӧгӧл; ўзен ўзе падша итеўче ӓр-кем кесаргя карышы киля диб.

13 Пилатъ бу сюзне эшеткяч, Іисусны тышка чыгарыб, лиѳостротонъ дигян урынга, хокӧм урнына утырган; ул урын Еврейчя Гавваѳа дейелгян.

14 Бу кӧн Пасха алдындагы пятница кӧн икян, алтынчы сагат тирясе икян. Шунда Пилатъ іудейляргя ййткян: мына сезнен Падшагыз! дигян.

15 Ӓммя алар: ал, ал, Аны кадаклат! диб кычкырганнар. Пилатъ аларга ййткян: сезнен Падшагызны кадаклатыйым меней? дигян. Архіерейляр жауаб биргянняр: безнен кесардян бютян падшабыз жук, дигянняр.

16 Аннары калдыгында Пилатъ Аны аларга кадакларга биргян. Алар Іисусны алыб киткянняр.

17 Іисусъ Ӱз качын кютяргян кӧйӧ, Еврейчя Голгоѳа дигян мангай урны дигян жиргя чыккан.

18 Шунда Аны кадаклаганнар; Анын белян тагы ике кешене, берсен бер жагына, берсен икенче жагына, уртага Іисусны кадаклаганнар.

19 Пилатъ качка жазыу жазыб куйган. Жазыуын: Назорей Іисусъ, Іудей Падшасы диб жазган.

20 Бу жазыуны іудейлярнен кюбесе укыганнар; Іисусны кадаклаган тӧш каладан жырак тӧгӧл икян; жазыуы Еврейчя, Грекчя, Римчя жазылган.

21 Іудейлярнен архіерейляре Пилатка ййткянняр: Іудей Падшасы диб жазма, ӓммя Ул Ӱзе: Мин Іудей Падшасы диб ййтте диб (жаз), дигянняр.

22 Пилатъ жауаб биргян: бер жазгач жаздым инде, дигян.

23 Салдатлар, Іисусны кадаклагач, Анын кейемнярен алыб, дюрткя бюлеб, салдат сайын беряр кисяк айырганнар; хитонъ дигян кейемен дя (алганнар); ул хитонъ тегелмягян икян, ӓммя бӧтӧнняй суккан икян.

24 Шуҥар кюря алар бер берсеня ййткяннар: мыны жыртмыйык, ӓммя жирябя салыйык, кемгя теяр; шулай итеб, Жазыуда: кейемняремне ӱзляреня айырдылар, ӧст кейемемя жирябя салдылар дигян сюз жиреня килергя тейеш булган. Салдатлар шулай кылганнар.

Зач. 61.

25 Іисуснын качы тӧбӧндя анасы, анасынын сеҥнесе Клеопа Маріясе, аннары Марія Магдалина торганнар.

26 Іисусъ, Ӱз анасын, тагы шунда торган сӧйӧклӧ ӧйрянеӱчесен кюреб, анасына ййткян: эй ӓней! мына бу синеҥ улыҥ, дигян.

27 Аннары ӧйрянеӱчесеня ййткян: мына бу синеҥ анаҥ, дигян. Шул кӧннян суҥ ул ӧйрянеӱче аны алыб ӱзендя тоткан.

28 Шуннан суҥ Іисусъ, инде барыда булыб беткянне белеб, Жазыудагы жиреня килсен диб, эчясем киля дигян.

29 Шунда бер сауыт тулы серкя бар икян. Салдатлар болотка серкя сеӊдереб, камышка элеб, Анын ауызы катына китергянняр.

30 Іисусъ серкяне татыб карагач, булыб беттеляр дигян дя, башын салындырыб, тынын биргян.

31 Ул кӧн пятница кӧн икян; анын артындагы суббота бик зур кӧн булганга кюря, тянняр суббота кӧннӧ качларында калмасыннар диб, іудейляр Пилаттан, аларнын сыйыракларын ыуатыб, ӱзлярен (качларыннан) алырга сораганнар.

32 Шунныктан салдатлар барыб, Іисусъ белян бергя кадакланганнарнын элекегесенен дя, икенчесенен дя сыйыракларын ыуатканнар.

33 Ӓммя Іисусъ катына килгяч, Анын ӱлеб беткянен кюреб, сыйыракларын ыуатмаганнар.

34 Тик салдатларнын берсе Анын кабыргалары арасына сӧнгӧ белян чянечкян, шул сяттюк кан белян сыу аккан.

35 Мыны ӱзе кюргян кеше таныклады, анын таныклауы чын; ул чынны айткянен белядер, сез ышансын диб (айтя).

36 Бу эш Жазыудагынын: Анын сӧяге ыуалмас дигяне жиреня килер ӧчӧн булган.

37 Тагы шулай Жазыунын бютян тӧшӧндя айтеля: сӧнгӧ белян чянечкянгя жалыныб караб торорлар, диб.

Зач. 62.

38 Шуннан суӊ Аримаѳеянен Іосифъ Пилаттан Іисуснын тянен качтан алырга сораган; бу Іосифъ Іудейлярдян куркыб, Іисустан жяшерен ӧйрянгян икян. Пилатъ аӊар бойорган. Ул барыб, Іисуснын тянен (качтан) алган.

39 Тагы шулай элгяре Іисусъ катына тӧння килеӱче Никодимъ да килгян; ул смирна белян алойдан жасаган жӧз литра чамасы эйесле май алыб килгян.

40 Алар Іисуснын тянен алыб, эйесле май сӧрткян кипенняргя тӧргянняр, гел іудейлярнен кюмеӱе жоласынча кылганнар.

41 Іисусны кадаклаган тӧштя агач бакчасы бар икян; бакчада беряӱ дя куйылмаган жаӊа кабер булган.

42 Шул кабер жакын булгач, іудейлярнен пятницасы сяятлей, Іисусны шунда куйганнар.

## 20-нче бюлем.

Зач. 63.

1 Атнанын элекенче кӧнӧндя карангы белян, иртюк, Марія Магдалина кабер жанына килгян,килгяч, кабер ауызындагы таш аударылыб жатканны кюргян.

2 Шундук жӧгӧрӧб кайтыб, Симонъ Петрга да, Іисуснын бютян сӧйгян ӧйрянеўчесеня дя килеб, аларга айткян: Ходайны кабердян алыб киткянняр, Аны кая куйганнарын белмейбез, дигян.

3 Шул сяттюк Петръ да, бютян ӧйрянеўче дя чыгыб, кабер жанына киткянняр.

4 Алар икесе дя бергя жӧгӧря башлаганнар, тик бютян ӧйрянеўче Петрдан жятряк жӧгӧргян, ул кабергя алдан килеб житкян.

5 Эйелеб карагач, анда жаткан кипеннярне гня кюргян, äммя кабер эченя кермягян.

6 Анын артыннанук Симонъ Петръ килеб житкян; ул кабер эченя кереб, анда жаткан кипеннярне гня кюргян, тагы шулай

7 Іисуснын башына чырмаган жаулыгы кипенняр белян бергя тӧгӧл, äммя тӧрӧлгян кӧйӧ бютян тӧштя ўз алдына жатканын (кюргян).

8 Аннары кабер жанына алдан килгян бютян ӧйрянеўче дя кергян; ул кюреўе белян ышанган.

9 Іисусъ ўлгян жиреннян терелеб торасыны алар Жазыудан äле аҥнамыйлар икян.

10 Шуннан суҥ ӧйрянеўчеляр ўзляреня кайтыб киткянняр.

Зач. 64.

11 Äммя Марія кабер жанында жылаб торган. Жылый торган кӧйӧ ул кабер эченя эйелгян икян,

12 Анда ак кейемне ике пяриштя утырганны кюргян, берсе Іисусъ тяне жаткан урыннын баш очонда, икенчесе аягы очонда икян.

13 Алар аҥар айткянняр: эй катын, син ник жылыйсын? дигянняр. Ул аларга айткян: Ходайымны алыб киткянняр, Аны кая куйганнарын белмеймен, дигян.

14 Шуны айтеў белян артка боролган икян, шунда торган Іисусны кюргян, тик Іисусъ икянне танымаган.

15 Іисусъ аҥар айткян: эй катын, син ник жылыйсын? кемне эзлейсен? дигян. Марія бу бакчачыдыр диб уйлаб, аҥар айткян: эй кадерле! Аны син чыгарыб куйган булсаҥ, Аны кая куйганыҥны миҥа айтсяня, мин Аны алыб китяр эйем, дигян.

16 Іисусъ аҥар: эй Марія! дигян. Марія боролоб, Аҥар айткян: эй Раввуни! дигян. Раввуни дигяне ӧйрятеўче дейеў.

17 Іисусъ аҥар айткян: Миҥа тейенмя, Мин äле Атама менмядем шул; äммя син Минем ага-энеляремя кайтыб, аларга айт: Мин Ўз Атама, сезнен Атагызга, Ўз Аллама, сезнен Аллагызга меням, дигян.

18 Марія Магдалина кайтыб, Ходайны кюргянен дя, Ул аҥар мыны айткянне дя ӧйрянеўчеляргя белдергян.

Зач. 65.

19 Атнанын шул элекеге кӧнӧндюк, кич белян, Іисуснын ӧйрянеӳчеляре бер ӧйдя жыйылышыб, Іудейлярдян куркыб, ишеклярен бикляб утырган чакта, Іисусъ килеб, уртада тороб, аларга айткян: тынычлык сезгя! дигян.

20 Шуны айткяч, Ул аларга кулларын, аякларын, кабыргаларын кюрсяткян. Ӧйрянеӳчеляр Ходайны кюргяч, сӧйӧнӧшкянняр.

21 Іисусъ аларга икенче табкыр тагы айткян: тынычлык сезгя! Мине Ата жибяргян кюк, Мин дя сезне жибярямен, дигян.

22 Шуны айткяч, ӧрӧб, аларга айткян: Святый Тынны алыгыз:

23 Сез кемгя жазыкларын кичерсягез, шуңар кичерелер, кемгя кичермей калдырсагыз, шуңар кичермей калдырылыр, дигян.

24 Ун икенен берсе, игез дигян Ѳома, Іисусъ килгян чагында, анда жук икян.

25 Бютян ӧйрянеӳчеляр аңар: без Ходайны кюрдек, дигянняр. Ӓммя ул аларга айткян: мин Анын кулында кадак жараларын кюрмясям, кадак жараларына бармагымны тейереб, кабыргаларына кулымны тейереб карамасам, ышанмам, дигян.

26 Шуннан сигез кӧн суң, ӧйрянеӳчелар тагы бер ӧйдя икян, Ѳома да алар белян бергя булган. Ишек бикле кӧйӧ, Іисусъ килеб, урталарында тороб, тынычлык сезгя! дигян.

27 Аннары Ѳомага айткян: бармагыңны мында китереб, кулларымны караб кара; кулыңны китереб, кабыргаларыма тейереб кара, инде ышанмый торма, ӓммя ышаныб тор, дигян.

28 Ѳома Аңар жауаб биреб айткян: Ходайым, Аллам! дигян.

29 Іисусъ аңар айткян: син Мине кюргяненя кюря ышандың, кюрмягян кӧйӧ ышаныучылар бахетле, дигян.

30 Іисусъ Ӳз ӧйрянеӳчеляре алдында тагы бютян кодрятляр дя кюб кылган, алары бу княгягя жазылмаган.

31 Ӓммя былары сез Іисуснын Алла Улы Христосъ икяненя ышансын диб, ышаныб, Анын исеме какына терелек алсыннар диб жазылган.

## 21-нче бюлем.

Зач. 66.

1 Терелеб торганнан суң, Іисусъ тагы Ӳз ӧйрянеӳчелареня Тиверіада дингезе жанында кюренгян; кюренеӳе былай булган:

2 Симонъ Петръ, аннары игез дигян Ѳома, тагы Галилеянын Кана каласынын Наѳанаилъ, Зеведей уллары, тагы бютян ике ӧйрянеӳчесе бергя булганнар.

3 Симонъ Петръ аларга айткян: мин балык тотарга барам, дигян. Алар аңар: без дя синең белян барабыз дигянняр. Барыу белян кайыкка кергянняр, ул тöннö бер дя тотмаганнар.

4 Иртя белян Іисусъ жар öстöндя тора икян; öйрянеўчеляре Анын Іисусъ икянен танымаганнар.

5 Іисусъ аларга айткян: эй балалар! сезнен бер-бер ашамныгыгыз жук мы? дигян.

6 Алар Аңар: жук, дигянняр. Ул аларга айткян: ауыгызны кайыкнын уң жагыннан салыгыз, тотарсыз, дигян. Алар салганнар, балык кюблектян ауны тартыб чыгара алмаганнар.

7 Іисуснын сöйгян öйрянеўчесе шул чакта Петрга айткян: бу Ходай! дигян. Симонъ Петръ бу Ходай дигянне эшеткяч, ўзе жалангачка кюря, кейемен биленя чырмаб, дингезгя сикергян.

8 Бютян öйрянеўчеляр балыклы ауны тартыб, жарга кайык белян килеб туктаганнар. Алар жардан жырак тöгöл икян, ике жöз терсяк буйы чамасы гна икян.

9 Жир öстöня чыккач, жаккан утны, ут öстöндя пешеб жаткан балыкны, аннары икмяк кюргянняр.

10 Іисусъ аларга айткян: äле тоткан балыгыгызны китерегез, дигян.

11 Симонъ Петръ барыб, зур балыклар тулган ауны жиргя öстöряб чыгарган; балык ней бары жöз илле öч булган; шул катле кюб булса да ау жыртылмаган.

12 Іисусь аларга айткян: килегез, ашагыз, дигян. Öйрянеўчелярнен берсе дя, бу Ходай икянне белгянгя кюря, Аннан: Син кем? диб сорарга кыймаганнар.

13 Іисусъ жакын килеб, икмяк белян балыкны алыб, аларга биргян.

14 Бу инде Іисуснын ўлгяненнян терелеб торгач, öйрянеўчелярeня öчöнчö табкыр кюренеўе.

Зач. 67.

15 Алар ашаганда, Іисусъ Симонъ Петрга айткян: эй Іона улы Симонъ! син Мине былар сöйгяннян артык сöясен ме? дигян. Петръ Аңар айткян: эйе, эй Ходай, мин Сине сöйгянне Син белясен, дигян. Іисусъ аңар айткян: бярянняремне кöт, дигян.

16 (Іисусъ) аңар тагы икенче табкыр айткян: эй Іона улы Симонъ! син Мине сöясен ме? дигян. Петръ Аңар айткян: эйе, эй Ходай, мин Сине сöйгянне Син белясен, дигян. Іисусъ аңар айткян: сарыкларымны кöт, дигян.

17 Тагы öчöнчö табкыр аңар айткян: эй Іона улы Симонъ! син Мине сöясен ме? дигян. Öчöнчö табкыр, син Мине сöясен ме диб сораганыннан кöйöнöб, Петръ Аңар айткян: эй Ходай! Син барын да

белясен, мин Сине сӧйгянне дя белясен, дигян. Іисусъ аҥар айткян: сарыкларымны кӧт, дигян.

18 Чын, чын сиҥа айтямен:син жяш чагында эзяреҥне ўзеҥ бяйляб, телягян жиреҥя жӧрдӧҥ; картайгач, кулларыҥны сузыб торорсон, сине бютян кеше бяйляр дя телямягян жиреҥя алыб барыр, дигян.

19 Мыны айтеб, Ул Петрнын ничек ўлем белян ўлеб, Алланы данналдырасын билгерткян. Мыны айткяч, аҥар: Минем артымнан кил, дигян.

20 Петръ боролоб караган икян, шунда Іисуснын сӧйгян ӧйрянеўчесе, кичке ашта Анын кюкерягеня сыйыныб, эй Ходай! Сине кем тотоб бирер диб сораган ӧйрянеўченен ўз артыннан килгянен кюргян.

21 Аны кюргяч, Іисуска айткян: эй Ходай, мыҥар ней булыр? дигян.

22 Іисусъ Петрга айткян: Мин аны Ўзем килгенче тотасы итсям, анда ней эшеҥ бар? син Минем артымнан кил, дигян.

23 Шуннан туганнар арасында бу ӧйрянеўче ўлмяс диб сюз жяйелгян. Тик Іисусъ аҥар ул ўлмяс диб айтмягян, äммя Мин аны Ўзем килгенче тотасы итсям, синеҥ анда ней эшеҥ бар? дигян.

24 Мыны шул ӧйрянеўче ўзе таныклаб жазды; анын таныклауы чын икянне белябез.

25 Іисуснын тагы бютян кылган эшляре дя бик кюб, тик алары турысында айырым-айырым жазылган булса, жазган князялярне бӧтӧн дӧнья сыйдыра алмас ыйы диб уйлыймын. Аминь.